Безнең МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

5

май 2021

ISSN:2500-011X

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

Чирмешән төбәгендә ачлык

25 бит

«Җырлаганда... җылата иде»

102 бит

ГАБДЕРӘШИТ ИБРАҺИМОВ

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең МИРАС

12 +

5
(329)
май 2021

Фәнни-популяр, әдәби-нәфис
һәм документаль журнал

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

14

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин (Фирдәвес Зариф)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә

Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Айрат Зарипов
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Айдар Сәлимгәрәев
(«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия

Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Хатыйп Миңнегулов
Ким Миңнуллин
Рүзәл Мөхәммәтшин
Григорий Родионов (Гәрәй Рәхим)
Данил Салихов
Индус Таһиров
Данис Шакиров
Ирек Шәрипов
Илдар Шәфыйков

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
Алмаз Фәйзуллин
(843) 222-09-83 (17-92)

Мөхәррир
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-91)

Сайт мөхәррире һәм корректор
Энҗе Хөсәенова
(843) 222-09-83 (17-93)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта: **yanamiras@mail.ru**
Сайт: **beznenmiras.ru**

«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал
(на татарском и русском языках)

Эчтәлек

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Гамил Афзал

ТАРИХИ МИРАС

4 Тимербәкнең ил-йортына сәяхәт (1404-1406) көндәлеге. *Руи Гонсалес де Клавихо*
9 Садри Максудов янында. *Б.Шәрәф*
14 Сөңгеле яуга тимер калканың әзер булсын... *Л.Гобәйдуллин*
16 И авылым, яшең күпме?.. *Р.Мәрданов, И.Һадиев*
20 «Ямьнәр өстенә мәрҗәннәр тамды...». *М.Фәйзи*
25 Чирмешән төбәгендә ачлык. *Ф.Ислаев*

ТАТАР ГАМЕ

30 Ике халыкның мирасы. *Р.Харис*
32 Очыгыз, тулпарларым! *Б.Ваһабзадә*
37 «Безнең мирас» котлый!

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны һәм фотоларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, җиде томлык «Татар тарихы»ннан алынган фотосурәтләр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

ДИНИ МИРАС

38 Ислам дөньясы. *Габдерәшит Ибраһимов*

44 Үтәмеш: беренче мәхәллә тарихы. *Н.Исхаков, Р.Исхакова*

ӘДӘБИ МИРАС

50 «Игү аты»н калдырган инсан «үлемсез». *Х.Миңнегулов*

56 Дөррәт әл-фахирә яки Ахирәтнамә. *Г.Утыз-Имәни*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

62 Мөслим бабай варислары. *Р.Хәбибуллина*

68 Нәселдәнлек. *Р.Батулла*

74 Фаил блокноты, Ишморат хаты… *Э.Шәрифуллина*

76 Адәм баласы ниләр күрми. *С.Сәубанова*

80 Кара тәкъдир. *Р.Батулла*

82 Истә, һаман да истә!

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

84 Матбугат һәм туган тел. *Р.Юсупов*

СӘНГАТИ МИРАС

90 Алмания безне алкышлады. *К.Саттаров*

95 Аллаһ колының варисы. *Ә.Зарипов*

102 «Жырлаганда… жылата иде». *Ф.Арслан*

108 Татар жырчылары. Кадерле мизгелләр. *З.Гыйльметдинова*

110 «Ком бураны» жыры

ШАЯН МИРАС

112 Көлке куа килә…

БАЛАЧАК МИРАСЫ

114 Без барыбыз да – балачактан

116 «Безнең мирас» хәбәрләре

118 Мирасворд

119 «Безнең мирас» елъязмасы. *Май*

Заказ №Е-1288. Тираж – 2638 данә. Формат 70х100 1/16
Басарга кул куелды: 23.04.2021. Чыгу көне: 28.04.2021.
Айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Тышлыкның беренче битендә:
татар сәясәтчесе, дин әһеле Габдерәшит Ибраһимов.

Телем барда үргә омтылырмын,
Күз өстендә торган каш кебек.
Телем бетсә, мин дә онтылырмын,
Күл төбенә төшкән таш кебек.

Гамил Афзал

Гамил Афзал. Магнитогорск, 1948 ел

ГАМИЛ АФЗАЛ
(23.05.1921-20.08.2003)

АНА ТЕЛЕ

Муса Җәлилгә

Һәркемгә дә иң газиз тел – ана теле,
Анда гына сабый чакның раушан гөле –
Кышкы кичтә әбиләрнең әкиятләре,
Әниләрнең биләү җыры, бәллү көе.

Ана телем, сине өзелеп яратканга,
Очам дисәк, безгә булдың канатлар да;
Дошман белән көрәшкәндә – үткен кылыч,
Балдай татлы – дуслар белән сайрашканда.

Күңелләрдән күңелләргә юл саласың,
Сусаганда эссе чүлдә су табасың;
Алышларда арысланга тиңдәш итеп,
Тоткынлыкта тимер булып таш ярасың.

Җырларның да иң татлысы синдә генә,
Уйларның да иң яктысы синдә генә.
Туган илнең, туган телнең матурлыгы
Якты илһам бирми икән кемгә генә!

Кайчагында адашкандай булам ла мин,
Уңны-сулны шәйләмичә егылам, димен,
Туган телем балкыта да барыр юлны,
Күз алдымда ярылып ята кыйблам минем.

*Текстны журналга **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Тимербәкнең ил-йортына сәяхәт (1403-1406) көндәлеге

Руи Гонсалес де Клавихо

Дәвамы. Башы журналның 2 нче (2021) санында.

Илчеләрне түгәрәк гөмбәзле итеп эшләнгән капкадан алып керделәр. Урамнан барган кебек, әмма ефәк диварлар, ефәк гөмбәз сине дөньядан аера, аратирә тәрәзәләр күренә, гаҗәеп матур чигеп эшләнгән ишекләрдән әле бер тирмәгә, әле икенче тирмәгә керә аласың. Иң уртадагысында Тимербәк үзе – табын түрендә. Бу тирмәләрнең гаҗәеп эшләнешен, андагы искиткеч байлыкны сүз белән сурәтләп бетерү мөмкин түгел, аны фәкать үз күзең белән күрергә кирәк.

Тирмәдән алып чыгып, илчеләргә шушы ук сарыпәрдә эчендәге мәһабәт агач бинаны күрсәттеләр. Аңа биек баскычлардан менеп кердек. Бу Тимербәк гыйбадәт кыла торган мәчет икән. Эче ачык зәңгәр төстәге бизәкләрне алтын белән каймалап эшләнгән. Мәчет бинасын бик тиз генә сүтеп-җыеп була торган итеп корганнар; Тимербәк аны үзе белән яу сәфәренә алып йөртә икән.

Илчеләргә тагын бер тирмәне күрсәттеләр: яшел бау белән тарттырылган, тышы – соры тиен мехыннан, эче – ак мехтан. Эчтә, гадәттәгечә, ике җирдә келәмле, мендәрле калку урын.

Моннан чыккач, янәшәдәге тирмәгә алып килделәр. Баулар белән тарттырылмыйча гына корылган әлеге тирмәнең тышкы ягы кызыл җирлеккә төрле төстәге ефәк тукымалар таслап эшләнгән иде. Эчтән исә урта бер җирдән алып итәгенә кадәр дөньядагы иң кыйммәтле мех – кеш тиресе белән сипләнгән. Кеш дигән җәнлек гәүдәгә сусар зурлыгында, әмма бик кыйммәт бәяләнә. Әйбәт эшкәртелгән бер кеш тиресе бу илдә ундүрт-унбиш дукат тора, бүтән җирләрдә ул тагын да бәһалерәк. Тирмәнең гөмбәзенә таба кеш тиресе тәмамланган урыннан башлап соры тиен тиресе китә. Тирмә ишеге турысында да соры тиен тиресеннән күтәрмә куелган. Мондый патшави тирмәләр шундый итеп корылган ки, кышын да, җәен дә кояш нурлары үтеп керерлек түгел. Мондагы байлык-зиннәт, бизәлеше, рәвеше ягыннан бер-берсен һич тә кабатламаган сарыпәрдә һәм тирмәләр иле очсыз-кырыйсыз иде.

Тимербәкнең бу урдасында, искиткеч манзара хасил итеп, җәмгысе кырык-илле мең тирмә тезелеп тора. Ә читтә – болын-кырларда, су буйларында, шәһәр читендә, бакчаларда тагын күпме тирмәләр корылган!

Бүгенге бәйрәмгә Тимербәк түрәләрне, яраннарын, бөтен Сәмәрканд мәмләкәтенең аксөяк байларын җыйган. Болар арасында тавыннан якут табыла торган Бадаһшан иленең бәге үзенең якыннары белән килгән. Ул Бадаһшан эргәсендәге тау токымын чокып якут эзләүләрен, тапкач инде, өтерге белән сак кына чистарта-чистарта, якут ташны ничек шомартып эшкәртүләрен сөйләде. Якут чыгара торган тауларны Тимербәкнең ясауллары саклый икән. Бадаһшан иленә Кече Һиндстан ягына таба Сәмәркандтан ун көнлек юл, диделәр.

Акиви каласыннан да Тимербәкнең ышанычлы бәге килгән иде. Андагы кыяларда зәңгәр таш һәм зәңгәр якут чыгаралар икән. Акиви каласы шулай ук Кече Һиндстан ягында, Бадаһшаннан астарак, Сәмәркандтан ун көнлек юл ераклыгында, ди.

Пәнҗешәмбе көнне, 3 октябрьдә, бәк үзенең урдасында илчеләр катнашында олы бәйрәм үткәрде. Зур тирмәгә бик күп кеше җыелган иде, шәраб агып кына торды. Биредә шәраб эчкән мәҗлес кенә мәртәбәле санала. Бәйрәмгә Тимербәкнең купшы киенгән хатыннары да килгән иде, рәхәтләнеп күңел ачу, төрле тамаша күрсәтү төн уртасына кадәр сузылды.

Пәнҗешәмбе көнне, 30 октябрьдә, Тимербәк, урдадан шәһәргә китеп, үзенең яраткан оныгы хөрмәтенә төзеткән мәчетле сарайга тукталды. Оныгы

Мөхәммәд Солтан Төркия сугышында Баязидның үзен әсирлеккә төшергән булган, шунда кинәт авырып китеп үлгән. Тимербәк бик яраткан оныгы хөрмәтенә сарай, мәчет һәм төрбә төзеткән.

Оныгын искә алу мәҗлесенә илчеләр дә чакырылды. Аның җәсәде куелган зиннәтле кабер-төрбәне илчеләргә күрсәттеләр. Төрбә дүртпочмаклы, бик биек итеп, аксыл-зәңгәр төсләр белән, алтынланган бизәкләр чокып эшләнгән. Тимербәк Төркиядән оныгының җәсәден Сәмәркандка озаткан чакта шәһәр идарәсенә шушы мәчет һәм төрбә бинасын төзетергә әмер биргән. Күпмедер вакыттан соң үзе кайтып төшкәч, төрбә бинасының тәбәнәк килеп чыкканлыгын әйтеп, ризасызлыгын белдергән. Сүтеп, яңадан салырга өлгермәсәләр, җәза кулланачагын әйтеп, ун көн вакыт биргән. Төзүче осталар шулкадәр каударланып тотынганнар ки, көне-төне эш тынмаган. Тимербәк шул вакыт эчендә үзе ике мәртәбә килеп карап киткән. Ул инде атка атланып йөри алмаган, аны махсус җайланмага утыртып, кулга күтәреп йөрткәннәр. Гаҗәпкә калырлык, шушындый зур төзелеш, нәкъ ул әмер биргәнчә, ун көндә тәмам кылынган.

Оныгы Мөхәммәд Солтанны искә алу мәҗлесенә бик күп кеше чакырылган иде. Табынга ит арты ит ризыгы чыгарылды. Мәҗлес соңында бәкнең иң якын яраннарыннан берсе – Шаһ Малик – илчеләрне алып чыгып китте. Һәммәсенә камка күлмәк кигезде, иңгә ике сусар тиресеннән яка куелган, эче мехтан астарланган, ефәк белән тышланган тун салды. Мондый киемне алар салкында кияләр икән. Илчеләргә ул тагын мең ярым көмеш тәңкә салынган янчык бүләк итте. Боларның бер тәңкәсе ике көмеш реалга тора.

Шуннан соң илчеләр, яңадан Тимербәк катына кереп, алар гадәтенчә баш иделәр. Бәк аларга иртәгә үз катына килергә кушты. Соңгы сүзе итеп улы Кастилия короленең илчеләрен хәерле сәгатьтә озатып калачагын әйтте.

Тимербәк Сәмәркандның даны турында һәрдаим кайгыртып тора. Бер төзелеш бетүгә, икенчесен башлата. Сәмәркандта ел саен олы ярминкәләр үткәрелә. Кытайдан, һиндстаннан, Тарталиядән – үзләренең бай өлкәләреннән һәм тагын башка илләрдән дә төрле тауар агылып килә. Сату-алу урыны тар булу сәбәпле, Тимербәк, каланы икегә ярып, зур урам төзетергә боера. Шул урамның як-ягына сәүдә чатырлары куярга тиеш булалар.

Бу урам каланың бер ягыннан икенче ягына кадәр уртадан салына башлый. Тимербәк, көн-төн эшләмәсәгез, башыгыз белән җавап бирәчәксез, дип, бу эш белән идарә итүгә ике түрәне билгели.

Теге түрәләр бәк әйткән турыга эләккән бөтен йортларны, хуҗасы кем булуга карамастан, сүттерә, җимертә башлыйлар. Йорт хуҗалары, кирәк-яракларын алып, тизрәк күчеп китәләр. Берәүләр җимереп-сүтеп бара, арттан төзеп тә киләләр. Киң урам төзелеп беткәч, як-ягына яктылык өстән төшеп торган гөмбәз тәрәзәле йөзләрчә чатыр коралар. Һәр чатырга ак таш плитәләрдән ләүкәләр куела. Урамның кайсыбер төшенә ял итү урыны, фонтаннар ясала. Бу төзелештә эшләүчеләргә хезмәт хакы шәһәр казнасыннан түләнә. Көндезге эшчеләрне төнгеләр алыштыра тора, берәүләр сүтә, икенчеләре кора, казый, күтәрә – әнә шулай көн-төн шау-шу, хәрәкәт, «шайтан туе» бара.

Егерме көнгә якын вакыт эчендә шушы кадәрле эшне башкарып чыгу акылга сыймаслык.

Әлбәттә, өе сүтелгәннәр арасында ризасызлык туа, әмма алар бу хакта бәккә белдерергә җөрьәт итмиләр. Шулай да кайберләре, җыелышып, бәккә якын торган түрәләр катына килеп, зарын белдерә. Бу түрәләр Мөхәммәд (с.г.в.)

пәйгамбәр нәселеннән булып чыга. Вакытын туры китереп, бәк белән шахмат уйнаган чакта, әлеге түрәләрнең берсе: «Йортларны җимертергә әмер бирдегез дә, аларның хуҗасына килгән зыянны капларга да әмер бирсәгез иде», – дигән теләген белдергән. Сөйләүләренә караганда, бу мәлдә Тимербәк бик ярсыган: «Бу минем калам, мин аны үз акчама сатып алдым, минем бу хакта ярлыгым бар, иртәгә күрсәтермен үзегезгә. Хаклы булып чыксагыз, сез әйткәнне түләрмен!» – дигән.

Түрәләр ник сүз кузгатканга үкенгән, ничек ул безне җәзага тартмады, ничек исән калдык, дип, бик гаҗәпләнгәннәр. Бәкнең һәр кылган эше мактауга лаек, аның һәр боерыгы сүзсез үтәлергә тиеш, бүтән юл юк.

Тимербәк әмере белән Биби ханымның әнисе хөрмәтенә салдырылган мәчет каланың иң күркәм бинасы санала. Ул бина төзелеп беткәч, бәк үзе килеп караган, алгы дивары тәбәнәк булган, дип, киредән сүтәргә боерган. Шулай итеп, алгы яктан нигезгә төшү өчен зур-зур чокырлар казыганнар. Кем алданрак башкарып чыкканын ачыклар өчен, Тимербәк үзе диварның бер башында торып, ике яранына икенче баштан күзәтергә боерган.

Тимербәк инде бу вакытта картаеп, хәлсезләнгән иде, ни атта, ни җәяү йөри алмый, аны фәкать күтәреп кенә йөртәләр. Һәр көнне аны төзелеш мәйданына алып киләләр, күпмедер вакыт ул эшне күзәтә, ашыктыра. Тимербәк кайчакта чокыр төбендә эшләүчеләргә пешкән ит күсәбәләрен үз кулы белән ыргыта. Төзүчеләргә ул вакыт-вакыт көмеш тәңкәләр бирергә куша. Шулай итеп көнетөне эш кайный иде. Бу төзелеш кар ява башлагач кына тукталды.

Җомга көнне, 1 ноябрьдә, илчеләр бүген инде кайтарып җибәрерләр дигән өмет белән, чакыру буенча бәк катына килделәр. Ул төзелеш барган әлеге мәчет мәйданында иде. Илчеләр иртәдән алып төшкә кадәр бәкнең тирмәдән чыгуын көттеләр. Ниһаять, Тимербәкне алып чыгып, мәйданның калку җиренә китерделәр. Табынга мул итеп ит ризыгы, җиләк-җимеш тезелде. Аштан соң илчеләргә бәкнең шундый сүзләрен җиткерделәр: «Илчеләр хәзер үз ирегендә, кичерсеннәр, мин бүген алар белән әңгәмә кора алмыйм, оныгым – Һиндстан солтаны Пир Мөхәммәдне үз биләмәсенә озатасым бар», – дигән ул. Әлеге көнне бәк оныгына да, аның яраннарына да атлар көтүе, корал, затлы киемсалымнарны мулдан бүләк итеп җибәргән.

Икенче көнне, шимбәдә, әйтелгән буенча илчеләр тагын Тимербәк катына дип килделәр. Әмма ул, хәле бик шәптән булмау сәбәпле, тирмәсеннән чыгып күренмәде. Илчеләр аны мәйданда төшкә кадәр көттеләр; бервакыт яраны чыгып, бүгенгә китеп торыгыз, бәкне күрергә ярамый, дигәч, илчеләр торган җирләренә кайтып киттеләр.

Якшәмбедә илчеләр безне өйләребезгә кайтарып җибәрер дигән өмет белән тагын әлеге мәйданга килделәр. Бик озак көтеп утырдылар. Бәкнең иң якын яраннарыннан өчәү килеп, сезне кем чакырткан иде, бүгенгә китеп торыгыз, бәк белән күрешү мөмкин түгел, диделәр. Аннары илчеләрнең иминлеген саклаучы егетне табып китерттеләр. Ни өчен рөхсәтсез алып килдең, борыныңны тиштереп тарттырабыз моның өчен, дигәч, әлеге егет, мин чакыртмадым аларны, бүген мин илчеләрне, гомумән, күрмәдем, дип, җәзадан акланып калды, ләкин барыбер сыртына шактый таяк алды. Бу яраннарның ярсуы табигый, чөнки бәкнең инде отыры хәле китеп бара, аның бөтен йорты, хатыннары, яраннары хәвефтә иде. Тимербәктән узып берәү дә илчеләрне үз иленә кайтарып җибәрә алмый иде, шуңа күрә тагын көтәргә куштылар.

Шулай итеп, илчеләр бәк тә чакыртмый, үзләре дә барырга җөрьәт итми торган халәттә яшәп ятканда, болар янына бер чыгытай егете килде. Югарыдан әмер бирелүе, иртәгә таңнан юлга кузгалырга кирәклеген әйтте. Бабил солтанын, испан һәм төрек илчеләрен ул үзе Тәбризгә кадәр озата барачагын, һәркайда – авылдамы, шәһәрдәме – атлар белән дә, азык-төлек белән дә тәэмин итүне кайгыртачагын әйтте. Тәбриздән соң бәкнең онығы Гомәр илчеләрнең һәркайсын үз иленә аерып җибәрәчәген белдерде. Тимербәк үзе китәргә боермады, корольгә җавап хаты язып бирмәде, дип, илчеләр ризасызлык белдерделәр. Чыгытай егете, түрәләр шулай хәл итте – бүтән илчеләр кебек үк юлга җыенырга кирәк, диде.

Шуннан соң испан илчеләре, бәк сараена барып, түрәләргә мөрәҗәгать иттеләр. Узган атнада, пәнҗешәмбе көнне, бәк үзе килергә кушты, туган илегезгә кайтарып җибәрер алдыннан әйтәсе сүзем бар, диде, ә бүген бер кешегез, килеп, аның исеменнән иртәгә юлга чыгарга тиешлегебезне әйтте, дигәч, түрәләр башта аптырап калдылар.

Бераздан соң Тимербәк белән күрешү мөмкин түгел, әйтелгәнчә, сезгә юлга кузгалырга кирәк, шулай хәл ителгән, диделәр. Моны белгән кешеләрдән, бәк каты авырый башлаган, телдән язган, үлем катында ята, имеш, дип ишеттек. Үлеп-нитеп китсә, бу хәбәрне бүтән җирләргә тараттырмас өчен, бәлки, илчеләрне шулай ашыктыралардыр. Корольгә бәктән җавап алмыйча китү мөмкин түгеллеген илчеләр никадәр раслап карасалар да, барыбер китәргә дигән карар чыгарылган, озатырга кеше билгеләнгән иде инде.

Шәһәр читендәге бакча эчендә урнашкан йортта, төрек илчесен көтеп, сакчылар, юл күрсәтүчеләр белән бергә, испан илчеләре берничә көн тордылар. Җомгада, 21 ноябрь көнне, бөтен илчеләр бергә Сәмәркандтан юлга кузгалдылар.

Хәзер мин Сәмәрканд каласы, аның җир-сулары хакында, Тимербәкнең бу каланы ничек күтәрүе турында сөйләп китәм.

Сәмәрканд каласы тигез урынны биләп тора, ул өеп ясалган вал, тирән канау белән уратып алынган. Шәһәр дивары эчендәгесе дә Севилья каласыннан зуррак, ә кала тирәли бик күп йортлар тезелеп китә. Сәмәрканд күз күреме җирләргә сузылган гөлбакчалар, йөзем кырлары уртасында урнашкан. Бакчалар, урамнар, мәйданнар белән кискәләнгән, анда бик күп халык яши; ипи, камыр ризыклары, ит, җиләк-җимеш сатыла. Шәһәрнең эчендәгегә караганда тышында халык тыгызрак яши. Шәһәр читендәге бакчаларда затлы сарайлар, күркәм биналар шактый еш күренә. Тимербәкнең үзенең дә сарайлары, төп баглары шунда салынган.

Аксөяк затларның йортлары да шул бакчалар эчендә. Шәһәрнең үзендә дә, тышында да арыклар бихисап. Кырларда мамык игәләр, кавын һәм карбыз үстерәләр. Бу җирләрнең кавыны шулкадәр тәмле, телеңне йотарлык.

Раштуага кадәрге айларда шулкадәр күп күләмдә кавын, йөзем җыеп алалар; базарларга кавын төялгән дөяләр кәрван-кәрван агылып тора, шунысы гаҗәп: бу кадәрлене ничекләр сатып, ничекләр ашап бетерергә мөмкиндер... Авылларда кавынны инҗир кебек киптерәләр: аркылыга зур итеп кискәлиләр дә, кабыгыннан арындырып, кояшка киптерергә куялар. Әзер булгач, капчыкларга тутырып еллар буе саклыйлар.

Шәһәр читендәге бакчалардан соң тигез иңкү кырларда зур-зур авыллар күренә, бәк монда үзе яулаган илләрдән кешеләр күчереп утырткан.

Урысчадан ***Марсель Галиев*** *тәрҗемәсе* ■

Садри Максудов янында

Борһан Шәрәф

*Оренбургта чыккан «Вакыт» газетасының 1909 елгы 10 (№518) һәм 12 сентябрь (№519) саннарында журналист **Борһан Шәрәф**нең Дәүләт Думасы депутаты **Садри Максудов** белән мосахәбәсе (әңгәмәсе) басылган. Анда күтәрелгән мәсьәләләр шул чордагы татар халкы, аның эшмәкәрлек, мәгариф һәм дин тарихын өйрәнү өчен кызыклы чыганак булып тора. Әлеге әңгәмәне сезнең игътибарга да тәкъдим итәбез.*

Редакция

Мин сәлам биргән вакытта Садри әфәнде бик борчылган хәлендә иде. Панаевский бакчасында ачык сцена алдында тулган кешеләр шундагы кинематограф аппаратында чыккан янгын илә урыннарыннан кузгалганнар, оялары туздырылган кырмыскалар шикелле, кая барырга белмичә торганга охшыйлар иде. Садри әфәнде бу янгынның җәелүенә каршы чараларга кереште. Миңа сәлам кайтаргач та:

– *Бу халык гаҗәеп инде. Тәртипне бигрәк тә сакларга кирәк урында тәртип саклый белмиләр. Кинематограф аппаратының бүлмәсе яна башлагач та, халык бер-берсен этеп тыгызлашты. Чыгып та китә алмыйлар, сүндерергә керешүчесе дә юк. Аппаратны будкасы белән бакча ягына аудару илә генә утның бөтен каралтыга җәелүен туктатырга мөмкин булды,* – дип, вакыйганы хикәя кылды.

Соңрак минем «Вакыт» мөхбире *(хәбәрчесе)* сыйфатым илә мосахәбәгә *(әңгәмәгә)* бераз форсат аеруын үтенгәч, Садри әфәнде моны мәмнүният *(канәгатьләнү)* илә кабул итте. Бер сәгать артык дәвам иткән мосахәбәбезнең кыскачасы ошбудан гыйбарәттер.

Садри Максудов (1878-1957) – Казан өязенең Ташсу авылында туган. Россия һәм Төркия сәясәтчесе, хокукчысы, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе. 1901-1906 нчы елларда Сорбонна университетының юридик факультетында укый. 1906 елда Казанга кайтып, «Иттифак әл-Мөслимин» фиркасенә керә, Думаның мөселман фракциясе җитәкчесе була. 1918 елның 5 гыйнварында Русиянең Аурупа өлеше һәм Себер төрки-татар мөселманнарының милли-мәдәни мохтарияте органы – Милли Идарә рәисе булып сайлана. Соңрак тормышы Финляндия, Швеция, Алмания һәм Төркиядә уза. Тел, тарих һәм хокук мәсьәләләренә караган күпсанлы китаплар авторы.

***

Садри әфәнде:

– Сезгә очрау форсатыннан файдаланып, мин Государственная Думада мөселман фракциясенең гәзитәләребездән мәмнүн (канәгать) булганын белдерәм. Сезнең «Вакыт» һәм Казан гәзитәләре мөселман фракциясен һаман яклап яздылар. Бу хосуста аларга тәшәккер итеп (рәхмәт йөзеннән), фракция мәҗлесендә дә мөзакәрә (киңәшмә) узды.

Мин, бу сүзләрдән шатланып:

– Җомга көн кибет ябу мәсьәләсендә сез бүген (27 август) губернаторга кергәнсез икән. Ул ни җавап бирде? – дип сорадым.

Садри әфәнде:

– Хәзер губернатор өйдә юкка күрә, аның эшләрен вице-губернатор башкара. Мин аңа кердем. Олуг урынга яңарак утырганга булса кирәк, ул миңа шактый хөрмәт илә мөгамәлә итте. Телендә бераз либеральлек күрсәтүдән дә тартынмады, ләкин мөселманнарга якшәмбе көн кибет яптыру мәсьәләсендә бик нык тора. Үзенең дәлилләрен шулай сөйләде: «Карагыз әле! Мөселманнар якшәмбе һәм башка рус праздникларында кибет ачуны сорау илә үзләренең дини хокукларын химая итеп кенә калмыйлар, бәлки, үзләренә рус сәүдәгәрләренә бирелгәннән артык имтияз (өстенлек) таләп итәләр: җомга көн, руслар кибете ачык булганда, алучылар башка гадәти көндәге чаклы гына була. Әмма якшәмбе вә башка праздник көннәрендә алучылар җомга көнгә күрә күбрәк буш булалар. Эшче вә эшле халык, әгәр ачык кибетләр булса, һәммәсе шул көннәрне алалар. Бу руслар сәүдәсенә зарар булып төшәдер. Аннан соң мөселман сәүдәгәрләре, җомга көн һәм башка бәйрәмнәрендә кибет ябуны өсләренә алсалар да, бик точно башкарып бетермиләр. Полиция аларны мөселман бәйрәмнәрен бәйрәм итәргә көчли алмый. Бу эш рус сәүдәгәрләренең ризасызлыкларына сәбәп була. Якшәмбе һәм башка праздникларда кибет ябу күптән закон булып чыккан, аны бозарга минем хәлемнән килми». Бу мәсьәләнең, Государственная Думада каралып, яңа закон чыкканчы, мондагы гадәтнең (мөселманнарга җомга көн ябу) дәвам иттерелүен һәм якшәмбе көн кибет япмаган өчен мөселман сәүдәгәрләре өстеннән ясалган протоколларның эшкә ашырылмавын үтендем. Губерна башлыгы моңарга бик ачык вәгъдә бирмәде. Алай булса да, бу протокол буенча җәза бирелүнең ашыктырылмаска мөмкин булуын аңлатты.

«Мәктәп мәсьәләсендә иң мөһим җәһәт, әлбәттә, укыту теле мәсьәләседер.

Садри әфәнде бу мәсьәләнең Государственная Дума комиссиясендәге хәлен сөйләгәндә болай диде:

– Мәсьәлә дини генә булса, бәлки, җиңелрәк булыр иде. Бу комиссиядә либеральный (хөр) фикердәге кешеләр аз түгел. Ләкин мәсьәләнең икътисади җәһәте бар. Руслар, никадәрле хөр фикерле булсалар да, рус сәүдәгәрләренең мөселманнар өчен зарар итүен яклый алмыйлар. Рус сәүдәгәрләре шул ук икътисади җәһәттән якшәмбе сәүдә итүгә протест ясыйлар.

Комиссиянең рәисе Тизенгаузен инородецлар күп булган шәһәрләрдә бәйрәм көннәрен үзләренчә тәгаен итәргә рөхсәт бирү фикерендә. Гучков (Октябристлар башлыгы), беләсез, сәүдәгәр Милюков (кадетлар башлыгы) бу мәсьәләдә русларны ачуландырырга бер дә теләми.

Борһан Шәрәф (1883-1942) – Тәтеш өязенең Аксу авылында туган. Җәмәгать эшлеклесе, язучы, нашир, педагог. «Мөхәммәдия» (1899-1905) һәм «Хөсәения» (1909-1918) мәдрәсәләрендә мөгаллим. 1905-1917 нче елларда «Казан мөхбире», «Әхбар», «Вакыт» гәҗитләре, «Шура» журналы хезмәткәре. 1917 елда Ырынбур мөселманнар бюросы рәисе. 1919-1923 нче елларда Ырынбурда Халык мәгарифе институтында укыта. 1930 елдан Урта Азиядә (Ташкент, Алматы) наширлек хезмәтендә. Гани Хөсәеновка багышланган «Гани бай» (1914), «Иран мәктүпләре» (1909) һ.б. хезмәтләр авторы.

Бу урынга җиткәч, Садри әфәнде сөйләшүне гомумиләштереп мондый фикер әйтте:

– *Милюков, кадет булса, мөселман мәсьәләсендә Гучковтан бик күпкә уңда.*

– Без моны Балкан мәсьәләсендәге нотыкларына карап шулай уйлый ала идек. Милюков – болгарларның мөгаллиме, София профессоры булганга күрә, төрекләрне яратмый, әмма Гучков, Кара диңгездә пароход йөрткәнлектән, үз сәүдәсен химая *(яклау)* өчен Төркия илә дуслыкны сакларга тели торгандыр дип, Төркия мәсьәләсендәге фикерләрен бик шәхси җәһәтләренә генә йөкләп калдырырга мөмкин дип таба идек.

Моңа каршы Садри әфәнде:

– *Хәер, алай гына түгел. Гучков бөтен жаны-күңеле илә сәүдәгәр кеше. Ул һәрбер нәрсәгә күнә. Әмма Милюков рус милләтчеседер. Ул һәрбер мәсьәләгә рус вә славян милләтенең мәнфәгате җәһәтеннән генә карый вә шул мәнфәгатьне күрше милләтләрнең русларга һәр җәһәттән, дикъкать итегез, һәр җәһәттән буйсынуында, руслыкның һәрнәрсәдән өстен булуында күрә. Кадетларның шулайраклары күп. Ләкин, үз максатларына ирешер өчен, ул фикерне бик сөйләмиләр.*

Мин:

– Государственная Думаның бу кышкы җыелышыннан ниләр көтәсез?

Садри әфәнде:

– *Бу кыш мөселманнар өчен бик мөһим мәсьәләләр караласы: сәүдә вә һөнәрханәләрдә ял итү һәм мәктәп, народный образование мәсьәләсе. Мәктәп мәсьәләсендә иң мөһим җәһәт, әлбәттә, укыту теле мәсьәләседер. Көнбатыш Аурупада инородецлы дәүләт фәкать Германия илә Австро-Венгриядер. Германиянең полякларга ничек мөгаләмә кылганы үзегезгә мәгълүм: полякларга үз диннәрен, үз телләрендә укырга рөхсәт итмиләр, дин дәресләре дә немецча укытылырга мәҗбүридер. Бездә руслар, әлбәттә, немецлар шикелле була алмыйлар. Ләкин хөкүмәт безнең өчен бөтенләй үз телебездә мәктәп тәрбия итеп торыр дип өметләнергә дә бик күп садәдиллек (беркатлылык) кирәк.*

Октябристлар хөкүмәт, шәһәр вә земстволар тарафыннан салыначак вә каралачак ибтидаи (башлангыч) мәктәпләрдә ике ел ана телендә укытырга уйлыйлар. Әгәр без дә бу программаны кабул итмәкче булып сатулашсак, бәлки, өч елга да күнәрләр. Иске мәктәпләребезне – мәхәллә мәктәпләрен шул көе калдырырга, бәлки, мөмкин булыр.

Шулай булгач, әгәр шул программаны кабул итсәк, электә булган мәктәпләребез янына хөкүмәт, шәһәр вә земстволар акчасыннан безнең өчен яңа мәктәпләр арттырылган була. Монда безнең кулыбыздан бернәрсә дә чыкмый. Шушы яңа мәктәпләребездән балаларыбыз файдаланса, анысы файда гына була.

Әгәр дә октябристлар кабул итәрлек карарларны без кабул итмәсәк, бөтенләй буш калабыз. Башта әйткәнебезчә, алардан бөтенләй мөселманча гына мәктәп өмет итү, мәшһүр тәгъбирчә (бу урында депутат әфәнде бераз көлемсерәп), «кәфердән иман өмет итмәк булыр». Яңа форма мәктәпләр ачылып карасын. Халык аларны яратып кабул итсә, күбәерләр. Яңа мәктәпләрнең мәхәллә мәктәпләрен бетерүенә юл куярга ярамый. Казанда ничә елдан бирле татарлар өчен русча мәктәп дәвам итә. Әмма мәхәллә мәктәпләренә һич тә тәэсир иткәннәре беленми.

«

– Казанлылар бөтен Сибирия вә Төркестан шәһәрләрен һәм кыргыз (казакъ) сахраларын тоттылар. Һәр җирдә үзләренең китапларын, мәдәниятләрен вә гадәтләрен тараттылар. Кая барсаң, башкалар арасында аларның тәэсире күренә.

Мин:

– Англиягә сәяхәтегездән мәмнүнсезме?

Садри әфәнде:

– Инглизләр Русия депутатларына гадәттән тыш хөрмәт күрсәттеләр. Кунакка чакыручылар хосусый кешеләр булса да, чакыруның хөкүмәт теләве белән булганы һәр төштә күренеп тора. Король Эдвардның күрсәткән игътибары гадәттән тыш булды. Мәгълүм ки, инглизләр бер дә бушка эшләргә яратмыйлар. Шуңа күрә безгә хөрмәт күрсәтүләрендә дә үз файдаларын карый торганнардыр.

*Моны эзләп табарга, әлбәттә, кыен түгел: инглизләр немецларга каршы Русияне үз якларында калдырырга тырышалар. Инглизләр, Русиядә миллият вәкаләтен ныгытып, аларны үзләренә дус итеп, максатларына ирешергә телиләрдер. Сарай (Сараево – Босния һәм Герцеговина башкаласы. – **Ред.**) даирәләре немецлар илә кардәшлек мөнәсәбендә булганлыктан, инглизләр рус милләтен, Русия халкын үзләренә багындырмакчы булалар.*

Мин:

– Үткән ел Берлинга сәяхәтегезнең нәтиҗәсе безнең матбугатка керми калды. Ул хосуста да бераз мәгълүмат бирмисезме?

Садри әфәнде:

– Берлинга барыш Англиягә сәяхәттән бөтенләй башка. Максат башка һәм безнең Русия депутатларының анда торган урыннары да башка булды. Анда немецлар үзләренең миллият фанатлары икәнлекләрен бик ачык күрсәттеләр. Мин нотык сөйләргә хәзерләнгән идем, ләкин көтмәгән бер эш булды. Нотыкны сөйләргә рөхсәт итмәделәр. Милюков миңа: «Садри әфәнде, Сез үзегезнең

Русиядән килгән икәнегезне онытмагыз! Мондый бәйнәлмиләл (интернациональ) мәсьәлә кузгатырга ничек куәт табасыз? Сез Истанбулдан йә Тәһраннан килмәдегез бит!» – кеби сүзләр сөйләде. Минем нотык шулай сөйләнми калды.

Мин:

– Гомумән, Русиянең киләчәге турында уегыз ничек? Русия халкының тиздән хокуклы вә хөрриятле булулары өметлеме?

Садри әфәнде бу турыда үз башында булган фикерләрне әйтүдә бераз каршылык күрсәтте, соңыннан бераз өметсез йөз белән:

– Тиздән зур инкыйлаблар күтәргә дәлилләр җитешми. Халык үзе тәрәккый (алга китмичә) итмичә, аның законнары тәрәккый итми, диләр. Мәгариф вә мәдәният юлында эшләүчеләр күбәйсә, халыкның фикере ачылса, эшләр башка булыр иде. Менә Государственная Думаның бу җыелышында шәһәр вә земство идарәләре хосусында яңа законнар каралачак. Бәлки, шушыннан соң җирле идарәләр халык файдасына күп хезмәт итәрләр. Мөселманнар да моңа катышыр дип өмет итәм. Хәер, Русиядә законның чыгуы илә гамәлгә ашуы арасында янә бик ерак ара калырга мөмкин. Русиядә тагын инкыйлаб ясауны фараз итеп булмый. Азеф, Гартингларның чын сыйфатлары мәйданга чыгу илә бездәге ихтилалчы (бунт, фетнә ясаучы) партияләрнең нидән гыйбарәт булдыклары да аңлашылды. Казанда социалист-революционерлар партиясен оештыручы Азеф үзе булган, имеш. Шәһәрдән-шәһәргә шулай оештырып йөргән. Шуның кулы илә эшләнгән партияләрдән ни өмет итмәк кирәк?

Соңрак сүзебез Русия мөселманнарының киләчәгенә күчте. Садри әфәнде, кыргызларның (казакъларның) вә Төркестан мөселманнарының әлегәчә үзләрен күрсәтмәүләрен сәбәп итеп, алар турында җавап бирергә тартынганнан соң, Казан мөселманнарының соңгы еллардагы гайрәтләрен бик истихсан итеп *(мактап)* сөйләде:

– Казанлылар бөтен Сибирия вә Төркестан шәһәрләрен һәм кыргыз (казакъ) сахраларын тоттылар. Һәр җирдә үзләренең китапларын, мәдәниятләрен вә гадәтләрен тараттылар. Кая барсаң, башкалар арасында аларның тәэсире күренә. Бу эш аларда гайрәт вә энергия барлыгын күрсәтә. Бу куәтнең тиз заманда үз мәдәниятләрен арттырырга сарыф ителәчәге ихтимал. Хәзер бар мәдәниятне булдыруга киткән көч вә гайрәт ул мәдәниятне алга җибәрүне дә тәэмин итәдер.

Садри әфәнде татарларның киләчәген бик өметле күрә. Бик аз хәзерлекле кешеләрнең күп эш башкаруларына мөхәррирләр, мөгаллимнәр һәм сәүдәгәрләребездән мисаллар алып исбат итте. Безнең бу кешеләребезнең хезмәтләре башка милләтләрнең бик озак заманда гына җитештерелгән кешеләренең хезмәтләренә тиң торганлыгын бәян итте.

Әңгәмәбезнең хатимәсе итеп, Садри әфәнде шулай диде:

– Беләсез бит: иҗтиһад вә гайрәт һәрвакыт көткәннән артык нәтиҗәләр бирә. Үткән биш-ун елда мәйданга килгән нәрсәләр электә көтелгәннән артык булды. Моннан соңгы 5-10 елда ник шулай булмас икән?

Яшь нәселебезнең иң алга чыккан егетләреннән Садри әфәнденең бу өметле сүзләре миңа да күркәм тәэсир итеп, мәмнүн вә шат булып, депутат әфәнденең кулын кысып, тәшәккер итә-итә аерылдым.

Текстны басмага ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

Безнең мирас №5 май 2021

Сөңгеле яуга тимер калканың әзер булсын…

(Борынгы бабаларыбызның сугыш киемнәре)

Яугир кулына калкан тоткан. Радзивилл елъязмасыннан миниатюра. XII гасыр

Яугирне җәрәхәтләнүдән яки яраланып һәлак булудан саклый торган хәрби киемнәр дәүләттә һөнәрчелек һәм хәрби сәнәгатьнең үсеш дәрәҗәсен күрсәтә.

Көбә кием (русча – кольчуга) – вак металл боҗралардан кыска җиңле күлмәк сыман итеп «тегелгән» борынгы сугыш киеме.

Ибне Руста (X гасыр), болгарлар атка атланып йөриләр, көбә кием кияләр һәм баштанаяк коралланганнар, дип язып калдырган. Әл-Мөкаддәси (X гасыр азагы) Болгар дәүләтендә ясалган көбә киемнәрнең ислам илләренә экспортка чыгарылуы турында әйтә.

Көбә күлмәкне «тегәр» өчен 600 м тимер чыбыкны ваклап кисәргә һәм алардан 20 мең данә боҗра ясап, бер-берсенә киертеп, эретеп ябыштырырга кирәк булган.

Көбә киемнең турыпочмак формасындагы тимер яки калын күн кабырчыкларны тезеп эшләнгән төре (русча – панцирь) – **кирәүкә** борынгырак һәм ешрак кулланылган. «Идегәй» дастанында «Тугыз күзле кирәүкә» дип күкрәктәге тимер кабырчыкларның саны әйтеләдер. Гадәттә, ул, яугирнең гәүдә зурлыгына карап, төрле санда булган.

Кабырчыкларны беркетүнең берничә ысулы бар. Элегрәк моның өчен юка каеш яки күннән ясалган нык бау кулланылган, XIV гасырда исә тимер чыбык белән беркетелгән. Ваграк кабырчыклар күн яки нык тукыма нигезгә заклепкалар ярдәмендә тезелгән, ә үзара күн каеш белән «тегелгән».

Иңбашын саклау өчен – **җилкә өлгесе**ннән (капламадан), тез имгәнмәсен өчен **тез каплавыч**лардан файдаланганнар.

Калкан – VII-IX гасырларда тиредән, агачтан яки чыбыктан үреп эшләнгән. Бу чорда аның металл элементы булмаган. Соңрак, X гасырда, ул ярымшар сыман маталл умбоннан ясалган, киҗе-мамык тукыма яки тире белән тышланган. Диаметры 0,5-1 м тәшкил иткән. Алгы ягы, түгәрәк каймасы төрле орнамент, тотем кош рәсемнәре белән бизәлгән.

Сугыш вакытында яугир калканны сул кулына алган. Ул дошманның ату, сугу-бәрү, ору-чабуларын, гәүдәгә тидермичә, җитез генә калкан белән тотарга, шулай итеп үзен имгәнүдән яки үлемнән сакларга тиеш булган. Яуга барганда исә, гадәттә, ат өстендә калканны сул як җилкәсенә киез бау белән аскан.

Очлым, тулга, алпак, тимер түбәтәй, шлем яки аның бакырдан ясалган төре – **бакрач** хәрбинең башын саклаган. Гадәттә, ул корыч, бакыр яки тимердән очлы итеп эшләнгән. Аңа, муенны саклар өчен, озын, иңбашына кадәр төшә торган көбә челтәр беркетелгән. Җитез хәрәкәт вакытында баштан ул, төшеп китмәсен өчен, күн **сакалдыры** белән ияктән бәйләнгән. Шлемның алгы өлеше (козырегы) – **саравыч**, очлы түбәсе **семәк** дип аталган.

Дошман алгы яктан яки яннан яугирнең башына сөңге, ук, кылыч белән һөҗүм итсә, бәрелгән корал шлемның түбәсенә таба таеп китеп, тәэсир юнәлешен үзгәрткән. Нәтиҗәдә, бәрелү көче кимегән, гаскәри ат өстеннән егылмыйча һәм имгәнмичә калган.

Йөзне саклау өчен шлемга металл **битлек** беркетелгән. (Шундый битлекләрнең берсе ТР Милли музеендагы А.Ф.Лихачев коллекциясендә саклана).

*Журналга **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

Безнең мирас №5 май 2021

И авылым, яшең күпме?..

Раиф Мәрданов, Ирек Һадиев

Төбәк һәм авыл тарихлары белән кызыксынган һәм моны өйрәнергә ниятләгән һәркем, иң беренче гамәле итеп, «Татар энциклопедиясе»нә мөрәҗәгать итә. Әмма әлеге абруйлы басма һәр очракта да өметләрне аклап җиткерәме, төгәл һәм дөрес мәгълүмат бирәме соң? Юк, дип әйтергә мәҗбүрбез. Татар тарихи чыганаклары белән эш итүчеләр буларак, сүзебезне раслый торган берничә мисалга тукталыйк.

Татар авылларының барлыкка килгән чорын билгеләүдә ышанычлы дәлил булган борынгы кабер ташларына «Татар энциклопедиясе» мәкаләләрендә тиешенчә әһәмият бирелмәгән. Мәсәлән, республикабызның Биектау районындагы Ямаширмә авылы зиратында борынгы ташъязма (эпиграфик) истәлекләрнең иң әүвәлгесе 1382 елгы, тагын сигезе XVI гасырның беренче яртысына – Казан ханлыгы чорына карый[1]. Иң мөһиме шул: әлеге зират хәзерге көндә дә файдаланууда. Бер үк зират эчендә сакланган төрле чор истәлекләре XIV гасырдан хәзергәчә дәвам иткән өзлексез тарихны исбатлый. Татар энциклопедиясе сүзлегендә Ямаширмә авылының Казан ханлыгы дәвереннән мәгълүм икәнлеге, ә энциклопедиянең 6 нчы томында 1565-1567 нче еллардан билгеле булуы әйтелгән[2]. Билгеле, бу очракта рус тарихи чыганакларының нигез итеп алынуы, шуларга өстенлек бирелүе күренеп тора. Әмма Ямаширмә авылының үзендә гасырлар буе сакланып килгән һәм, галимнәр тарафыннан моңарчы өйрәнелеп, китапларда басылган[3] үзебезнең татар чыганагы санга сугылмау – тарихи фальсификациянең ачык мисалы.

Биектау районының Чуаш Иле авылы «Татар энциклопедиясе»ндә 1602-1603 нче еллардан билгеле дип күрсәтелгән булса да, бу авыл зиратында Казан ханлыгы чорыннан калган дүрт кабер ташы (шул исәптән 1543 елгы эпитафия) бар, 1542 елгы тагын бер ташъязма шул ук зираттан Казандагы музейга китерелгән.

2019 елның көзендә Биектау районы авылларында үткәрелгән фәнни-эпиграфик экспедициябез вакытында Мәмдәл авылы зиратында да булдык. «Татар энциклопедиясе» әлеге авыл турында язганда аның да 1602-1603 нче еллардан мәгълүм икәнлеген белдерә[4]. Ә зиратта 1539 ел белән даталанган кабер ташы саклана. Аның текстын тәкъдим итәбез.

[1] Мәрданов Р., Һадиев И. Ямаширмә зиратында – Алтын Урда һәм Казан ханлыгы истәлекләре // Безнең мирас. – 2018. – №10. – Б.16-21.
[2] Татар энциклопедия сүзлеге. – Казан: ТР ФА Татар энциклопедиясе институты, 2002. – Б.803; Татарская энциклопедия: Т.6: У-Я. – Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2014. – С.516.
[3] Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М., Л.: изд-во АН СССР, 1960. – С.21, 25, табл. 44; Казаков Е.П., Старостин П.Н., Халиков А.Х. Археологические памятники Татарской АССР. – Казань: Татар. кн.изд-во, 1987. – С.117; Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. – Казань: изд-во «Мастер-Лайн», 1999. – С.33, 86.
[4] Татар энциклопедиясе: Т.4: М-П. – Казан: Татар энциклопедиясе институты, 2014. – Б.91.

«

Моңарчы чыккан кайбер китапларда Мәмдәл зиратындагы бу ядкяр XVI гасырның беренче яртысы һәм 1540 елгы дигән даталар белән ике кабер ташы буларак телгә алынган. Дөреслектә, ул ике өлешкә сынган бер таш.

Мәмдәл авылы зиратындагы 1539 елгы ташъязма истәлек

Ташъязманың арткы ягы

Шаһиҗаббар Нургали улына куелган таш. 1539 ел

Алгы ягында (күпертмә язулы):
1) калә Аллаһу [Тәгалә вә ма тәдри]
2) нәфсүн би-әййи ардин тәмүтү вә калә Сөбханәһә
3) вә Тәгалә көллү нәфсин заикател-мәүт
4) калә ән-нәби галәйһиссәлам әд-дөнья [мәзрагатүл-ахирәти]
5) тарих тукуз йөз кырык алтыда
6) ирдекем Нургали угылы Шаһиҗаббар
7) ... даре фәнадин рихләт кыйлды

Арткы ягында (күпертмә язулы):
1) бу ләүхәне анасы Дәүлә-
2) -солтан бина кыйлды

Уң ягында (күпертмә язулы):
1) калә ән-нәби галәйһиссәлам...

Сул ягында (күпертмә язулы):
1) калә ән-нәби галәйһиссәлам [әд-дөнья] җифәт вә талябиһа киляб

Үлчәмнәре: 207х52х25 см.

Моңарчы чыккан кайбер китапларда Мәмдәл зиратындагы бу ядкяр XVI гасырның беренче яртысы һәм 1540 елгы дигән даталар белән ике кабер ташы буларак телгә алынган. Дөреслектә, ул ике өлешкә сынган бер таш. Тексты, мәрхүмнең исеме һәм төгәлләштерелгән башка мәгълүматлары биредә беренче тапкыр басыла.

Әйтелгәннәргә охшаш тагын берничә мисалга тукталыйк. Питрәч районындагы Тау Иле авылының хәзер дә гамәлдәге зиратында 1488, 1492, 1497, 1518, 1550 һ.б. елларга караган борынгы ташъязмалар саклануга карамастан, «Татар энциклопедиясе»нең 6 нчы томында бу авылның 1602-1603 нче еллардан гына билгеле икәнлеге күрсәтелгән. Шушы ук томда Әтнә районының Төрекләр авылы 1646 елгы рус чыганакларында телгә алынган дип әйтелгән, ә авыл зираты уртасында 1544 елгы ташъязма истәлек басып торуы исәпкә алынмаган. Шундый ук очрак Югары Ослан районының Татар Мәмәтхуҗасы авылы белән дә бәйле: аның борынгы зиратында 1548 елгы кабер ташы һәм шул ук чорда куелган тагын бер эпиграфик истәлек бар, ә энциклопедиянең 5 нче томында бу авыл 1614 елдан мәгълүм дип язылган.

Югарыда телгә алынган һәм башка борынгы татар ташъязмалары турында Гали Рәхим һәм Һарун Йосыпов, тагын кайбер тарихчы һәм археолог галимнәр, шул исәптән безнең тарафтан да язып бастырылган хезмәтләр, мәкаләләр аз түгел.

Энциклопедияне төзүчеләр һәм басмага әзерләүчеләр ташка язылган үз тарихыбызга ник битараф? «Татар энциклопедиясе» ни өчен татар чыганакларына нигезләнмәгән? Әллә татар язма чыганаклары фән өчен ышанычлы дип саналмыймы? «Татар энциклопедиясе»нең икенче басмасында мондый тупас кимчелекләр төзәтелерме?

Менә бу сораулар безне, татар чыганакларын өйрәнүче белгечләрне дә, татар халкы һәм төбәкләр тарихын өйрәнүче фидакяр затларны да бик борчый.

Сүзлекчә:

әд-дөнья мәзрагатүл-ахирәти – дөнья – ахирәтнең иген кыры;
әд-дөнья җифәт вә талябиһа киляб – дөнья – үләксә, аңа этләр мохтаҗ
бина кыйлды – куйдырды;
вә ма тәдри нәфсүн би-әййи ардин тәмүтү *(Коръән, «Локман» сүрәсе, 34 нче аять)* – кайсы җирдә үләчәген һичбер кеше белми;
даре фәнадин – фани (вакытлы) дөньядан;
ирдекем – иде;
калә Аллаһу Тәгалә – бөек Аллаһ әйтте;
калә ән-нәби галәйһиссәлам – Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның сәламнәре булсын) әйтте;
калә Сөбханәһә вә Тәгалә – олуг һәм бөек [Аллаһ] әйтте;
көллү нәфсин заикател-мәүт – һәр җан үлем ачысын татыр;
ләүхә – таш;
рихләт кыйлды – күчте;
тукуз йөз кырык алтыда – һиҗри 946 ел милади исәп белән 1539 (1540) елга туры килә. ■

«Ямьнәр өстенә мәрҗәннәр тамды...»*

Мирхәйдәр Фәйзи

1923, июнь-июль

5есендә җиңги белән Сәедгәрәй абый Балтачка кунакка киттеләр. Мине дә бик ныклап чакырганнар иде. Голәмә мәҗлесенә барасым килмәде. Һашим белән чакырсалар, ул вакытта барыр идем. Иртә чәйне Гыйззенисалар белән бик күңелле итеп эчтек.

Икрам белән шөрәкә уйнадым. Икрамнан алда чыктым. Икрам бик күңелле малай ул. Көлке сүзләр табарга да оста.

Бүген аулак өй бездә. Егетләр дә килә, кызлар да. Көне буе уйнап, шаярып йөрдек. Габдулла, Хафиз, Ламига, Гыйльмебану, Нәгыймә, Гыйззениса, Һашим һәм Гайшәләр белән берәм-берәм кызыклы хатирәләр калды.

Шода кызлары матур, күңелләрне кузгатыр;
Бәхетең алда сайрап тора, үзең генә бул батыр!

Кич мин, Һашим, Габдулла урамга чыктык. Хаҗилар янында утырдык. Кайтышлый, кыз янына килгән бер егетне тота яздык, куркытып кычкырдык. Хәлил *(«Галиябану» герое. – Ред.)* кебек танып калдык.

6сында. Кояш баегач, Закир килде, Габдулла килде, Гыйльми килде, Хафиз килде; матур кыз Гыйльмебану килде, тагы әллә нинди кызлар килде. Мәктәптә уйнап утырдык. Егетләр бичара кызларны кычкыртып бетерделәр. Икрам да бәләкәй генә башы белән кызлар белән шаяра. Һашим гармун уйный.

> **Ямьле, күңелле. Җаннар ямьнәргә манылды. Ямьнәр өстенә мәрҗәннәр тамды. Мәрҗәннәр кызарып җанды, тормышлар нурланды...**

Егетләр белән урам буйлап киттек. Гыйльми, гармун уйный башларга иртә дип, кызлар янына алып китте. Бер өем кызлар янына бардык. Мин дә сөйләштем. Егетләр бик тозлы кинаяләр сибәләр, әллә нинди оят булмавы шөбһәле булган сүзләр тезәләр. Кызлар һәммәсенә түзәләр. Түзәләр генә түгел, суганлап сүгендерәләр.

Гыйльми, ай-ваема карамый, үземне генә тагы бер җиргә алып барды. Ике кыз янында байтак вакыт үткәрдек.

Аннан гармун алып урамга чыктык. Аргы якка чыгып, Өре, Кантур урамнарыннан урап кайттык. Закир чукындырып җырлый. Ямьле, күңелле. Җаннар ямьнәргә манылды. Ямьнәр өстенә мәрҗәннәр тамды. Мәрҗәннәр кызарып җанды, тормышлар нурланды...

---

* Көндәлекләрдән кыскартып бирелә. – **Ред.**

Мирхәйдәр Фәйзинең абыйсы Сәедгәрәйнең Шодадагы йорты

7сендә. Күкрәк авыртуларым бетте диярлек. Азрак тазардым да. Үземне рухлы, көчле хис иттем. Өметләрем артты.

Табигать матур. Ишегаллары яшел чирәм, тирәкләр хуш исләр белән тулы. Тән азыгы – сөт, май, катык, күкәйләр. Җан азыгы – Гыйльмикәйләр дә бар, шөкер!

9ында. Киләсе җомгага Шодада җыен башлана. Бер айдан бирле якын-тирәдә сәяхәт итеп йөргән бу җоланы халык хәзерлек белән көтеп тора. Ул, бер атна берничә авылга, аннары тагын бер атна берничә авылга махсус булып, менә киләсе атна Шода, Кунерлар чираты инде. Мин дә шул җыенны көтеп, китми ятам. Насыйп булса, җитә инде.

Һашим, әтисенең йоклаганын көтеп йөреп: «Әти йоклады, әйдә, гармунга», – дип, яныма килде. Мәктәпкә кереп, гармун уйнадык. Мескен гармун пич эчендә ята.

Закир да килде. Өчәү папирос тарттык. Башка җегетләр дә җыелдылар. Мәгъмүрәнең энесе Шәрәфетдин дә килде. Аны мин беренче күрәм. Егет сымак малай. Аннан чит авылдан килгән кунак кызлары бар йортка бардык. Капка төбендә торалар иде. Без килгәч, су буена киттеләр. Артларыннан бардык. Киртә буенда бергә булдык. Бу җирдәге кунак кызы белән авыл җегетләренең кыланышлары, хәрәкәтләре минем өчен бик кызыклы булды. Кунак кыз битен яшерде. Егетләр шуның өчен аны хурладылар, көлделәр, шаярдылар. Кыз әче-әче җаваплар бирде: «Кирәк булса, урысча да сөйләшермен», – ди. Хаҗи: «Шулай ирмеш, атаң чирмеш, бабаң ар...» – дип, әллә нәрсәләр тезеп китте. Ул мондый төрләрдә дә беренче каһарман икән, һичбер аптырамый. Көлә-көлә хәл бетте. Шулай йөреп бүген, әтәчләр торды, без яттык.

11ендә кантур ягына чыгып, яр өстеннән су буе манзарасын тамаша итеп, таңга кадәр утырдым. Яныма шул якның егетләре Галләм, Ибраһим, Шәрәфиләр килде. Үзләре белән дуслашып, бергә-бергә күңелле итеп утырдык. Кызык сүзләр сөйләделәр, көлделәр, яшьнәделәр. Мәгъмүрәнең энесе Шәрәфине бая: «Качкалак!» – дип сүгеп киттем, хәзер дусландым. Ул тартынган булган. Үземнең «әллә кем» түгел икәнемне тиз аңлаттым. Мин аның кебек җанлы, ямьле җегетләрне, теге битен күрсәтми, күзе белән тирбәтми торган кызлардан артыграк күрәм. Каршымда гел яшьлек, матурлык, җанлылык кына күреп торырга теләүче булганым өчен, аны гәүдәләндерүче кыз булса да, җегет булса да –

«
Каршымда гел яшьлек, матурлык, җанлылык кына күреп торырга теләүче булганым өчен, аны гәүдәләндерүче кыз булса да, җегет булса да – бертигез. Иркәлим.

бертигез. Иркәлим. Хәтта кайсы чакта капризлары, кыланулары белән кызлар икенче пландарак торып калгалыйлар.

13ендә. Кич кызларның киндер тукмаклауларын җырактан тыңлап тордым. Авыл өстендә музыка тавышы кебек шыңгырдап хөкем сөргән бу нәфис тавыш җанымны ямьләде.

15ендә. Җыенга киләчәк кунакларның атларына азык хәзерләп, бер тугайны чабачак булганнар иде. Бүген шул манзараны карарга болынга төштем. Кечерәк кенә болын. Бөтен авыл халкы шунда җыелган. Чүп-чуар булып печән чабалар. Бик кызык, бик күңелле. Бичара халык, имана башына тигән ашъяулык кадәр генә җирләрен чабып йөргән булалар. Бер яктан караганда, көлке тоела. Биш-алты иманага тигән печәнне төясәң, бер ящик арба тулмый. Шуны карап, галәмәт килеп чабып йөргән булалар. Үзебезнең яктагы печән җирләрен сөйләсәм, хикәят кебек кызыксынып тыңлыйлар. Ә бусы миңа хикәя кебек күренә.

Бүген җәяүле кунаклар килә башлады. Һәммә капкалар ачык, һәркем кунак көтә. Кич урамга чыктым. Көндез чапкан болында гармуннар, җырлар, биюләр булды. Закир белән кунак кызлар янына бардык. Кызлар арасына кертеп утыртып куйдылар, малай. Сөйләшеп аңлаштым. Маһитап, Рәхимә исемле кунак кызлары бик матур икән. Берсе – Хаҗиның, берсе Закирның тәсәллытында *(ягъни бу егетләрнең күз атып йөргән кызлары. –* ***Ред.****)* күренделәр. Шулай ук, алар урамда бераз йөргәч тә, яннарында кунарга элдерделәр. Тыныч төн чыгыгыз!

Болынга чыгар алдыннан Закир мине, Габдулланы бакчаларына алып кереп көмешкә белән сыйлады. Җыенның «бисмилла»сын укытты. Ламига бик матурлап табын әзерләде, закускалар китерде. Ике бутылканы ялтыратып, җегетләнеп, кызлар янына бардык.

16сында иртә тордым. Кырындым, җуындым, киендем. Нәкъ бәйрәм кебек. Бүген иртүк атлы кунаклар агылды. Бөтен капкалар ачык. Урамнар, капка төпләре чуар киенгән хатын-кызлар, киенгән, матурланган егетләр-ирләр белән тулган. Җиккән атлар узып китә. Аннан да, моннан да уен тавышлары, җырлаулар ишетелә. Арбаларга җегетләр, кызлар бергә төялеп уйнап узып китәләр. Чабаталы, алама күренеп йөргән егетләр күбесе итек кигәннәр. Тоташ чиккән күлмәкләр, ап-ак алъяпкычлар, кәнительле кәләпүшләр белән киенеп, сокланырлык рәвешкә кергәннәр. Кунак кызлары, кунак җегетләренең исәбе-саны юк. Гаҗәп бер җанлылык, ямьлелек, күңеллелек.

> **«Минем өчен гади крестьян кызлары ни арыга, ни бирегә ярарлык булмаган бәндәләрдән кадерлерәк булганны аңламыйлар, кемнәр тирәсендәрәк чуалганымны сизмиләр.**

Безгә кунак булып кодагый, Мәдинә ханым, Үзбәк, Нургаян, Рокыя ханым Ибраһимова килделәр. Сәедгәрәй абый, җиңги, кунаклары дөбер-шатыр килеп кунакка йөрергә тотындылар.

Җыен көннәрендә Ламига белән минем туем була икән дип ишетеп, җиңгигә справкага килүчеләр булган. Кырык төрле хәбәр чыкты инде. Алар мине үзләренчә образованный саналган Ламигалар, Мәгъмүрәләр белән буташтырып йөртәләр.

Белмиләр бу күңелемдә ниләр тирбәлгәнне. Минем өчен гади крестьян кызлары ни арыга, ни бирегә ярарлык булмаган бәндәләрдән кадерлерәк булганны аңламыйлар, кемнәр тирәсендәрәк чуалганымны сизмиләр.

Бүген төнне Гыйззениса янына бер егет кергән дә, берәүнең тышка чыкканын белгәч, куркып качкан. Ашыгычлык белән калушын калдырган. Иртә белән җиңги табып, калушны арестовать иткән. Менә бәла!

Гыйльмулла эчке мәҗлесенә чакырган иде, бармадым. Эчү миңа куркыныч. Эчмәгәч, кызык итеп яшәп булмый шул. Эчмәсәң, дөньяның күп кызыгыннан мәхрүм каласың. Менә бәхетсезлек!

Габдулла белән Закирларга бардык, Закир белән Габдуллаларга килдек. Кунак егетләрен, кунак кызларын күрдем.

Урамнарга асыл гөлләр үскән бүген,
Өсләренә сөенеп куна минем күзләр,
Гөлләр алар, ил бизәге, җанлы гөлләр –
Гөлләр кебек матур егет, матур кызлар...

Җыен манзараларын күбрәк күрер өчен, ашау-эчүне дә, өйдәге кунакларны да онытып, урамнарда йөрим. Үземне, күземне, күңелемне бәйрәм иттерәм.

Җәяүләп болынга – чишмә янына уенга төштек. Низамга кепканы биреп, үзем аның кәнительле кызыл кәләпүшен киеп алдым. Болын шундый бер чуарлык белән бизәлгән, шундый бер яшьлек белән балкыган ки, каршында сәҗдә итмәү мөмкин түгел.

Чишмә яны яшел чирәм өсләренә
Җилбезәкләр, гөлбизәкләр сибелгәннәр;
Гөлдәй җанып, җилбезәкләрдәй нурланып,
Яшь җилкенчәк киенгәннәр, сөенгәннәр...

Болында элек җегетләр генә тора. Гармун уйныйлар, җырлыйлар, бииләр. Кызлар бәләкәй-бәләкәй тау түпләрендә тезелешеп утыралар, шунда җыелалар. Җегетләр янына үзләре килеп ваксынмыйлар. Уен башланыр алдыннан җегетләр, кызлар янына барып, үз теләгәнен җитәкләп алып төшә. Безнең кебек кунакларга хөрмәт өчен ике кулына икене дә тотып төшкәлиләр. Болын тагы ямьләнә. Матур-матур парлар болын тутырып йөриләр. Кулга-кул ялгап түгәрәкләнеп йөреп торалар. Круг эчендә бер гармунчы вә ике-өч җырчы, кочакланышып, агымга каршы әйттереп киләләр. Тагы бер кыз алмаштыра торган уеннары бар. Һичбер качу, тартыну, курку юк. Тәмам хөр рәвештә рәхәтләнеп уйныйлар.

Ак алъяпкыч матурлыйдыр җегет билен,
Кәнительле кәләпүштә нурлар җана,
Җегетләре кызга карап җылмайганда,
Кызларның керпекеннән гөлләр тама...

Җегетләрнең көчле кулларында назланып, салланып, нурланып йөргән кызларга карасаң, күзләрең сеңеп кала. Киемнәре, кыланышлары, уеннары үзләренә бөтенләй килешеп, күңелләрне каршыларында җөгендереп торалар.

Тал чыбыктай зифа, нәзек билләренә
Матур кызлар, алъяпкыч бәйләгәннәр,
Күкрәкләрен күперткәннәр, селкеткәннәр –
Җегетләргә «күз кәгъбәсе» әйләнәләр...

Кайсыбер кызлар җегетнең кулыннан ычкынып качып китә. Җегете куып тотып, кысып, кочып алып килә. Кайберсе җегетенә карамый, сыргаланып маташа. Җегет аңа да әмәл таба. Кайсылары җегетенә бөтенләй сыенып йөри, җегетнең кулы да



Шодада Сәедгәрәй абзыйлар йортының планы. Планнан күрше йортын, күршеләр белән уртак капка, кое, алма һәм җиләк бакчасын; дамба кебек биекләтеп, таш сибеп, читенә агач тезелгән юлны; келәт, утын сарае, тавык оясы кебек нәрсәләрне, аш өен; бүлмә, әбрәкәй, йокы бүлмәсе, эчке өйалды, хатыннар өе алды, кечкенә өй, ирләр өе алды, өлкән өй, бакчаны; кызлар мәдрәсәсен, арт ишегалдын, иген келәтен, лапас, ындыр, ишегалды, сарай, мәчет һәм ирләр мәдрәсәсе ягын күрергә мөмкин.

кулдан тоту белән генә канәгатьләнми, билләргә таба «сәфәр» иткәли. Йөз-йөзләргә, авыз-авызларга җитә язып, «хәвеф күмер» була язып калгалый…

Җырлый-җырлый киң тугайны түгәрәкләп,
Егет-кызлар җитәкләшеп әйләнәләр;
Бер уйлыйсың, «нурга нурлар ялганган», дип,
Бер карасаң, гөлгә гөлләр бәйләнәләр...

Без, килешли үк, кызлар төркеменә бардык. Хаҗи разведка ясап йөрде дә, азмаз сөйләштереп торды да, берсен, кулыннан сөйрәп торгызып, минем кулыма тоттырды, берне үзе җитәкләде. Бүтәннәр дә берәр кыз алдылар. Пар-пар булып киттек болынга. Аннан да, моннан да җегетләр кыз җитәкләп төшә башладылар. Мин күп уйнамадым, төрле җирләрдән карабрак йөрүне ихтыяр иттем.

Читтән караучылар белән дөнья тулган. Бер якта әле җиткән егет, җиткән кыз булып, өлгерә алмаган үсмер малай-кызлар автономный эш күрәләр, өлкәннәргә тәкълид итәләр *(ияләр),* киләчәккә әзерләнәләр. Аларның да кызлары тау башында утыра. Карышкан кызларны ике малай ике кулыннан тотып сөйриләр дә, алып төшәләр. Бер кызны җылата-җылата сөйрәп төшергәннәрен дә күрдем. Кызык!

Уен кояш баеганчы дәвам итте. Кайткан чакта урамнардан дәрьялар ташып акты.

Текстны басмага ***Рәйсә Шәрәфиева*** *әзерләде.* ■

КОТОЧКЫЧ АЧЛЫК

СӘХИФӘ ИДЕЛ БУЕНДАГЫ 1921-1922 НЧЕ ЕЛГЫ АЧЛЫКНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА ҺӘМ АЧЫГЫП ВАФАТ БУЛГАН МӘРХҮМНӘР ИСТӘЛЕГЕНӘ БАГЫШЛАНА.

Чирмешән төбәгендә ачлык

Фәйзелхак Ислаев, тарих фәннәре докторы

Тарих дәреслекләренә 1921 елгы ачлык дип кергән бу тетрәндергеч еллар халык хәтерендә хәзер инде онытылып бара. Ә ачлыкны 1921 ел белән генә күрсәтү дөреслеккә туры килми. Шуңа күрә хәтерне Чирмешән төбәге мисалында яңартырга булдык. 1920 елда авыл халкы җирне үзе өчен генә эшкәрткәнлектән, чәчү җирләре шактый кими, уңыш та бик яхшы булмый. Архив материалларына караганда, шул елның ахырында ук Чирмешән төбәгендәге шактый авылларда ачлык башлана. Бөгелмә кантонының төрле вулысларыннан кантон үзәгенә, киләсе елны уңыш булмаячак, көзен чәчелгән арыштан бернәрсә дә көтеп булмый, дип язалар. Чирмешән вулысыннан да: *«Озимые хлеба находятся в очень плохом состоянии»,* – дип хәбәр итәләр. 1921 елның башында ук кайбер авылларда мал-туар саны сизелерлек кими башлый. Сәбәпләре – малга ашатырга җитәрлек печән юк дәрәҗәсендә, салам хәзерләнмәгән. Хайваннарга азык җитмәгәнлектән, алар арасында төрле авырулар көчәя.

1921 елда, 1920 ел белән чагыштырганда, Бөгелмә кантонында чәчелгән җир мәйданы 40 процентка кими. Кимүенең сәбәбен чәчү өчен орлык җитмәү, шактый хуҗалыкларның аты булмау белән аңлаталар. Шул ук вакытта күмәк хуҗалыкларда чәчү мәйданы күпкә арта, тик алар бөтен кантонга күп түгел, нибары унау гына. Алары да әле эшен җайлап җибәрә алмый интегә. Хайваннар саны 30 процентка кими, авылларда атларны күпләп сату һәм суеп ашау башлана.

1921 елның башында ук шәһәрдә азык-төлек җитмәгәнлеге сизелә. Хәер, мондый хәл Гражданнар сугышы еллары өчен табигый. Авылларда хәер сорашып йөрүчеләр арта. Теләнчеләр икмәкне, тормышта кирәк булган төрле кирәк-яракка алмашып, башка төбәкләргә алып киткән очраклар да күзәтелә. Икмәкне чит төбәкләргә чыгаруны тыялар, аны тикшереп тору өчен махсус комитет төзелә. Хакимият органнары, продразверстка планнарын үтәү өчен, азык-төлекне крестьян хуҗалыкларыннан көчләп җыюны дәвам итә.

Әйтерсең, табигать тә халыкны ныграк сынарга уйлый: 1921 елның язы катлаулы килә. Утырткан кызыл торма, кабак, кыяр һәм кәбестәне, май аенда ук көчле кырау төшеп, салкын өшетә, кишерне, корт ашап, үстерми. Бу елның язы һәм җәе бик эссе килә. Чәчкән орлыклар, дым булмаганлыктан, шытып чыкмый, кырларны чүп үләннәре баса, аларны да тиз арада кояш көйдереп, киптереп бетерә. Көзгә таба кайбер кешеләр алабутаны урып, ындырга ташып

өя. Аның орлыгын суктырып, кул тегермәнендә тартып, кара он ясый һәм шуны ашка салып ашый яки күмәч пешерә.

Бөгелмә кантонында 1921 елның беренче яртысында 4210 кеше ачлыктан үлә. Татарстан кантоннары арасында бу – иң зур күрсәткеч. Димәк, ул якларны ачлыкны иң авыр кичергән төбәк дип атарга була. Шулай булуга да карамастан, җирле хакимият органнары ачлыктан интеккән кешеләргә ярдәм кулы сузарга ашыкмый. Тик 1921 елның 4 августында гына, ачлыктан коткаруны оештыру өчен, кантон башкарма комитеты җитәкчелегендәге комиссия төзелә. Ачлык – фронт, дип игълан ителүгә дә карамастан, үзәктән реаль ярдәм тиз генә килеп җитми, аннан 57 мең пот (1 пот – 16 кг) бәрәңге җибәрү белән генә чикләнәләр.

1921 елның 21 октябрендә генә Бөгелмә станциясенә Петроградтан ачлыктан интеккән балаларны тукландыру поезды килә, анда 2 мең баланы төшке аш белән сыйлый башлыйлар. Алдан хәбәр итмичә килгән поезд үз эшен 4-5 көннән соң гына оештырып җибәрә ала. Ач балаларга исән калыр өчен һәр сәгать кадерле булган вакытта шулай эшләнә бит бу! 1921 елның декабрендә ике атна эчендә базарда азык-төлеккә, бигрәк тә икмәккә, бәя 3 мәртәбәгә арта. Бер пот ашлыкның бәясе 750 мең сумга кадәр күтәрелә.

Бөгелмә кантоны буенча 1922 елның 22 гыйнварында 240 310 кеше ачлыктан интеккән. 10 ашау урыны, мәктәпләрдә 123 ашханә, Бөгелмәдә 2 АРА ашханәсе, авылларда Помголның 129 ашханәсе эшли. 2188 өлкән яшьтәге кеше, 1334 бала-чага эвакуцияләнеп, аларның кайберләре Украинага, Полтавага озатыла. 1921 елның 1 декабреннән 1922 елның 22 гыйнварына кадәр Бөгелмә кантонында 1266 кеше – ачлыктан, 101 кеше тифтан үлгән, 3063 кеше тиф белән авырган.

Чирмешән ягындагы авылларда хәлләрнең бик начар булуын әлеге телеграмма күрсәтә: *«Татцик. В Черемшанской волости Бугульминского кантона положение населения ужасное. Ежедневная смертность на почве голода 50 человек. Трупы валяются. Умерших хоронить некому. Скот, собаки и кошки съедены. Установлен факт: родители съели трупы двух своих детей. Шлите продовольственную помощь для спасения населения.*

Предволисполкома Фролов»

Ачлыктан интегүчеләрнең кешелек сыйфатларын югалткан очраклары да булган. Бу хакта Урманасты Үтәмеш авылына караган документлар сөйли: *«Февр. 1922 г. Из телеграммы народного следователя 2 участка: В Подлесном Утямышеве гражданин зарезал своего брата 8 лет. Несколько частей зарезанного съели, остальные отправлены в Кувакскую больницу.*

Фев. 1922 г. Сообщение в кантисполком: в д. Подлесный Утямыш гражданка съела своего умершего трехлетнего ребенка. Питания нет, семья из 5 человек питается кошками, собаками, скотина съедена. Уполномоченный Зубарев»[1].

«Хәтта үз балаларын үзләре ашаган кешеләрне күрдек... Куйбышевта базарда адәм ите саталар иде пешереп һәм [андый сатучыларны] тота торалар иде. Татариядәге шикелле майлы балчык ашадылар. Гали авылында үземезнекеләр алабутаны киптереп тарталар да, юкә яфрагын киптерәләр дә төяләр. Шуны ашыйлар да, тәрәт итә алмыйча, үләләр.

Ачлык елларының авырлыгы турында кайбер истәлекләр сакланган, шуларның берсен китерәбез: *«Халыклар ачка беткәннәр... Бер чокырга унар кешене күмәләр иде. Юлда – үлгән, артта, чокырда да – үлгән бәндәләр. Хәтта үз балаларын үзләре ашаган кешеләрне күрдек... Куйбышевта базарда адәм ите саталар иде пешереп һәм [андый сатучыларны] тота торалар иде. Татариядәге шикелле майлы балчык ашадылар. Гали авылында үземезнекеләр алабутаны киптереп тарталар да, юкә яфрагын киптерәләр дә төяләр. Шуны ашыйлар да, тәрәт итә алмыйча, үләләр. Менә заман сезгә, балалар! Ат, сыер бик аз калды... Мин үзем, армиядән кайткач, бу хәлне белдем дә, беркөнне шундин үләннәр берлән ашадым да, эч күбеп, тәрәт итә алмыйча дүрт көн йөрдем»*[2].

Чирмешән төбәгендәге авылларда мондый хәлләр еш булып торган. Бөгелмә кантонының ачлыктан интеккән халыкка ярдәм итү комиссиясенең 1922 елның 30 гыйнварындагы утырышында комиссия җитәкчесе Гордеев мондый сүзләр

[1] Фролов Н. Трагедия народа. – Казань, 1999. – С.28, 31.
[2] Гали авылы тарихы. – Казан, 2014. – 73 б.

әйтә: *«Положение населения кантона становится безвыходным. С мест начинают поступать сообщения о поедании на почве голода трупов детей. Читает телеграмму из Черемшана от уполномоченного по перевыборам т. Зубарева о бедственном положении деревень Верхней и Нижней Чегодайка. В последнем установлен факт поедания трупов детей. В Подлесном Утямыше женщина съела свою (так в тексте. – Автор) умершего трехлетнего ребенка»*[3].

Түбән Чагадай авылында булган хәлләр хакында архивта башка документ та сакланган. 1922 елның 9 апрелендә төзелгән документ буенча бер ир кеше «людоед» дип теркәлгән, аның гаиләсендәге кешеләр барысы да ачлыктан үлгән.

Бу авылларда АРА ашханәсе булуга карамастан, шундый фаҗига күзәтелә, чөнки кешедә ашар өчен азык юк, ә ашханәләрдә 14 яшькә кадәр булган балаларны гына тукландыралар. Тиз арада Югары Чагадай һәм Түбән Чагадай авылларына 81 данә паек һәм бу аяныч хәлләрне ачыклау өчен уполномоченный җибәрелә. Әлбәттә, бу чаралар гына авыл халкын ачлыктан коткара алмый. Ул вакытта паек күләме – һәр кешегә 1 фунт (400 грамм чамасы) он итеп тарттыртылмаган кукуруз бирелгән. Кызганыч, ачлыктан интеккән кешеләргә таратырга он яисә ашлык җитмәү сәбәпле, норма 1922 елның февраль аенда 50 процентка киметелә. Комиссия утырышында: *«За февраль и первую половину 1922 года количество голодающих ежедневно увеличивается. Овсяной хлеб недоброкачественный, сырой; картофель мерзлый»*, – дип теркәп куелган.

Кукуруз, кыш көне Мәскәүдән вагоннарга, җәй көне Сембердә Иделдәге баржадан станциядә вагоннарга күчереп төяп, Шынтала, Бөгелмә, Ютазы станцияләренә кадәр алып кайтылган, аннан, ат арбаларына салып, авылларга ташылган. Вагон бушатучы грузчикларга һәр вагон өчен 1 пот 10 фунт кукуруз бирелгән. 1922 елның июнь аенда Бөгелмәгә кукуруз белән 70 вагон килүе билгеле.

Кукуруз орлыгын Шынтала станциясеннән Чирмешәнгә алып кайтканнар һәм шуннан соң гына авылларга өләшкәннәр. 1922 елның кыш айларында Югары Чагадайга 360 паек бирелү турында мәгълүмат сакланган. Шул ук вакытта Түбән Чагадай – 400, Иске Үтәмеш 545 паек алган, ә вулыста барлыгы 4500 паек таратылган. 1922 елның 15 июнендә Чирмешән вулысына 250 паек урынына 500 паек бирелә[4].

Кырларда иген өлгерү белән, 1922 елның 1 августыннан паекларны таратуны туктату турында карар кабул ителә. Ашлык уңышы бик начар, үскәнен дә җыеп алырга һәркемнең хәленнән килми, хуҗалыкта булган шактый атлар суеп ашала, кырда эшли алырлык кешеләр юк дәрәҗәсендә. Шуңа күрә, авылларда ачлык дәвам итүне исәпкә алып, халыкка паек тарату дәвам итә. 1922 елның 3 сентябрендә Чирмешән вулысына 250 пот (4000 кг. – ***Автор***) бодай оны бүленеп бирелә[5].

1922 елның җәендә җир җиләге бик уңа. Шәмгун кызы Фәхирә ачлыктан аяксыз калган Фәхразый һәм Шәйхразый исемле ике баласын, каяндыр көч табып, урманга күтәреп бара. Өйгә балалар үз аяклары белән кайталар һәм исән-сау калалар.

[3] ГАРТ. Ф. Р-1336. Оп.1, Д.62, Л.2-3.
[4] ГАРТ. Ф. Р-1336. Оп.1, Д.62, Л.174.
[5] ГАРТ. Ф. Р-1336. Оп.1, Д.62, Л.146.

Ачлык елларында Югары Чагадайда, башка авыллардагы шикелле, ваба чире (тиф) хөкем сөрә башлый. Ваба белән авырып та, аннан үлмәгән кеше эштән чыгып, чирләп кала. Күп кеше маляриядән иза чигә. Авылда тормыш тәмам таркала, актык ат, сарык, кәҗә, әтәч, чебеш суеп ашала, көненә ике калак он белән торган халык кешелек сыйфатларын югалта. Авылда әтәч тавышы ишетелми, эт өрми – алар ашала. Йортларның яртысына якыны бөтенләй юкка чыга. Күбесе очсызга сатыла, иясез калганнары әле үлеп бетмәгәннәр тарафыннан сүтелә һәм утын итеп файдаланыла. Мунча ягучы юк, кычыткан капчыгыннан тегелгән күлмәктә бетләр үрмәли. Тирә-яктагы һәр авылда коточкыч ачлык хөкем сөрә[6].

Бөгелмә кантоны ачлыктан вафат булган кешеләр саны буенча Татарстанда өченче урында: беренче урында – Тәтеш, икенчедә – Чистай. Статистика Татарстан буенча барлыгы 400 мең кеше ачлыктан үлгән дип саный, ә аның төгәл саны күпме булганлыгын берәү дә белми, чөнки ул төгәл исәпкә алынмаган, Авыл Советларында моны санарлык кеше дә калмаган.

Югары Чагадай – Чирмешән төбәгендә ачлыктан иң күп газап чиккән авыл. Ачлык елларында авыл халкының күпләп үлгәнлеге турында әлеге саннар әйтеп тора: 1920 елның гыйнварында авылда 1206 кеше исәпләнсә, 1922 елны 466 кешегә кимеп, 740 кеше генә кала. Димәк, авыл халкының 38,6 проценты вафат була, бу күрсәткеч – Чирмешән вулысы буенча иң югарысы. Югары Кармалка дип аталган рус авылы гына моннан бераз калыша, анда 475 кеше үлгән. Ә ул барлык халыкның 38,5 проценты. Болар бит авыр елларның ахыргы саны түгел, алга таба да авылларда ачлыктан үлүчеләр булган.

1926 елда булып узган халык санын исәпкә алуда авылда бары тик 697 кеше генә теркәлгән. Димәк, авылда яшәүчеләр саны, 1920 ел белән чагыштырганда, 793 кешегә кимегән. Бу – ачлык фаҗигасенең масштабын күрсәтүче коточкыч зур сан. Ә бит 1922-1926 нчы елларда авылда шактый бала да туган. Шундый ук фаҗига Идел буендагы башка татар авылларында да күзәтелгән. Татар авыллары тарихында хәтта сугышлар чорында да кешеләр моның кадәр масштабта үтерелмәгән! Менә бу 1917 елгы Бөек революциянең һәм Гражданнар сугышының иң төп нәтиҗәсе. ■

---

[6] Гафуров-Чагътай. Г.Галинең алтмыш еллык истәлеге. – Казан, 2017.

Безнең мирас №5 май 2021

Ике халыкның мирасы

Бәхтияр Ваһабзадә

Кешенең үткәне – архивта. Бәлки, киләчәге дә шундадыр. Язучының киләчәге – аның яңа идеяләрендә, яңа омтылышларында. Мин, үземнең архивыма «тыгылган» саен, ниндидер бер иҗади этәргечкә юлыгам, ә ул мине алга, киләчәккә өнди... Ә алтмыш ел җыелган кәгазьләр арасында ни генә юк?!. Кайберләрен, бәлки, күрсәтергә дә иртәрәктер...

«Безнең мирас» журналының исеменә туры килердәй берәр документ, әсәр сорап мөрәҗәгать иткәч тә шулай булды – утыз-кырык елдан артык кояш нуры күрми боегып яткан кулъязмага тап булдым. Ул Муса Җәлилгә багышланган «Очыгыз, тулпарларым!» дигән поэма булып чыкты. Аны 1966 елда, каһарман шагыйребезнең 60 еллыгына туры китереп,

Азәрбайҗанның халык шагыйре, академик Бәхтияр Ваһабзадә язган, ә мин аны тәрҗемә иткәнмен. Бу поэманың татар телендә газета-журналларда басылганын хәтерләмим, ул минем китапларыма да керми калган, хәтта 7 томлык сайланма әсәрләремә дә. Кызганыч ки, тәрҗемәнең датасын вакытында беркетмәгәнмен, шуңа күрә поэманың минем кулга кайчан һәм ничек килеп кергәнлеген төгәл генә билгеләү авыр.

Мин 1981 елда «Азәрбайҗан» дигән әдәби журналның 50 еллыгына Бакыга бардым. Бик зурлап бәйрәм иттеләр – СССРның барлык союздаш республикаларыннан, алар белән янәшә Татарстаннан, Башкортстаннан әдәби журналларның баш редакторлары җыелган иде. Күрәсең, ул елларда ук безнең халыкларга кардәш азәрбайҗан җәмәгатьчелегенең аерым – туганнарча якын мөнәсәбәте булган. Хәер, ул якынлык әле дә исән – Тукай бәйрәмнәренә Казанга Бакыдан саллы кунаклар килә, безнең язучылар да шундый чараларда катнаша. Мин үзем, Бакыга барган саен, данлыклы шәхесләр җирләнгән аллеяда булам һәм истәлекләрне яңартам. Ул данлыклы аллеяда ятаткан шагыйрьләрем Расул Рза, Сәмәд Вургун, дустым Мәмәд Араз, яхшы танышым Бәхтияр Ваһабзадәләр белән җаным сөйләшә. Истәлек тә бит үзенә күрә кыйммәтле архив! Истәлекләр дә мирас!

Хәтерем ялгышмаса, Камал театрының Бакыга гастрольләре вакытында, 1980 елның көзендә булса кирәк, мәшһүр азәрбайҗан шагыйре, күренекле галим, академик Бәхтияр Ваһабзадә мине үзләренә кунакка алып китте. Без затлы чәй табыны янында сөйләшеп утырдык. Ул татар әдәбияты, язучылары, театрлар турында сорашты, азәрбайҗан әдәбияты сәхифәләренә алып керде. Татар Габдулла Кариев труппасы белән азәри Хөсәен Араблинский труппаларының берләшеп эшләгән чакларын искә төшердек. Әле дә исемдә – ул Мәмәд Кули-заденең «Үлекләр» дигән комедиясенең эчтәлеген сөйләде. Бер хәйләкәр шарлатан, мәетләрне терелтә алам, дип, байгуралардан бик күп акча җыя. Ләкин, көне-сәгате җиткәч, барысы да үзләренең кадерле туганнарын, якыннарын яңадан терелтүдән баш тарталар, чөнки барысының да мәрхүмнәр алдында кичереп булмаслык гаепләре-гөнаһлары бар икән... Мин бу пьесаны Марсель Сәлимҗановка тәкъдим итеп карадым. Ул башта бик кызыксынды, ләкин сәхнәгә менгермәде.

«Очыгыз, тулпарларым»ның минем кулыма килеп керүе, бәлки, шул очрашуда булгандыр. (Аһ, тарих өчен даталарның төгәл булуы никадәр мөһим!) Башка вакытта булуы да ихтимал, әйтик, 1989 елның 14 мартында да без Бакыда очрашканбыз, ул миңа «...старому другу по перу...» дип «Достоинство» дигән китабын бүләк иткән булган. Иң мөһиме шул – мин Бәхтияр ага Ваһабзадәнең герой-шагыйрь Муса Җәлилгә багышланган поэмасын тәрҗемә иткәнмен, бу хезмәт сакланган һәм ул ике халыкның да мирасы булып саналырга хаклы.

Ренат Харис,
Татарстанның халык шагыйре ■

ОЧЫГЫЗ, ТУЛПАРЛАРЫМ!

Бәхтияр Ваһабзадә[1]

Әй, Физули, газапларны бер чикмичә
Мөмкинме соң чын шатлыклар тәмен тату –
Язгы тамчы ак энҗегә әверелә
Кабырчык караңгысында бикле ятып.

М.Физули

Муса Җәлил



Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәре»

Алдымда «Моабит дәфтәре» –
зинданда боекмый, бөеккә
әйләнгән шагыйрьнең көннәре.
Һәр көне – бер шигырь, бер энҗе,
газапны җиңүче сөенеч...
Һәр шигырь – үлемсез бер адым...
Һәм соңгы адымы соңында
шагыйрьнең Үлемне үтергән
үлемсез йөрәген күралдым...

Калкансыз ачылган бу йөрәк
корычтан түземрәк –
ул хәтта газаптан көч алган,
тапталган килеш тә очалган,
газапның үзеннән үч алган...
Шагыйрьнең газабы минем дә

[1] Азәрбайҗанның халык шагыйре, СССР дәүләт премиясе лауреаты

йөрәктә илһамга әйләнде,
Мусаның йөрәге утыннан
минем дә җаныма ут капты,
һәм минем җаным да ут атты.
Ут мине каядыр әйдәде…
Җанымны әйдәде…
Каләмне әйдәде…

I

Тын өйләрдә,
рәхәтлектә йөзә-йөзә,
язабыз без дә…
Гәрчә йөрәк айлар буе янмый тибә…
Баш өстендә ныклы түбә…

Шигырьләребездә
бер төсле үк бертөслелек –
дулкынсыз аккан көннәребез кебек.

Ага тора борчылусыз көннәр.
Күңелләр дә,
әйтерсең лә, тынсыз өйләр.
Өебезгә керми искән җилләр.
Өйдә җылы,
тәндә – ялкын,
җанда – салкын.

Еш язабыз бары тик язар өчен –
үз күңелебезне үзебез назлар өчен.
«Әй кайгысыз чаклар, – дибез, –
кайгысыз чаклар!..»
Өстәл өстебезгә иеләбез.
Карасак –
җансыз кәгазьләр
җанны чәнчи,
әйтерсең лә, пычаклар…

Ә без язабыз. Хәреф саен каләм абына,
кәгазьне тырный…
Шигырь картая тумас борын.

Көчәнә-көчәнә язган шигырь,
кычкырсак та аны биек тауга менеп,
ерак китмәс,
колакка җитмәс,
йөрәккә үтмәс.

Бернәрсәгә дә әверелмәс
утта кызмаган тимер.
Беркемне дә җылыта алмас
ялкынсыз йөрәктән чыккан шигырь.

Шигырь тусын өчен лампа яктысы түгел,
рух балкышы кирәк,
ялкынлы күңел!
Җан утын сүндерә алмас хәтта төрмә:
кабындымы – суда да дөрләр.

Елаган – елата,
кабынган – кабыза.
Җирдән рөхсәт сорыймыни туасы таң?
Орлыгы өлгергәч,
әнә, үлән ташны тишеп чыккан…
Һәм күңел дә,
тулса әгәр,
яңгыр болыты белән бәрабәр –
барыбер түгелә,
кыш дип тормый, җәй дип тормый.
Аңа мөмкин түгел башкача!
Күз яше яралгандай йөрәк утыннан,
иң гүзәл сүз энҗеләре
кара зинданнарда ярала кайчак.

II

Әсирлектә калды Җәлил, ә сынмады,
югалтмады горурлыгын, буйсынмады.
Кол ителде иреккә дан җырлаучылар –
Маркс, Һейне хатирәсе ничек чыдар?!.

Карар чыкты – аның гомере соңгы чиктә.
Үлемне үтерүчене үлем көтә.
Аны дошман таш зинданга кертеп япты,
ә ул вакытның үзен тотып туктатты.

Ул элек тә, канлы көннәргә чаклы да,
язды шигырь…Ул шигырьләрдә чаткылар
чатный иде. Ләкин фашист балтасына
башны куйгач, язганнары ялкын сыман
дөрләп китте… киләчәк таңга тоташты.
Җыры белән шагыйрь мәңгелеккә ашты.

Үз дуслары аткан туплар тавышында
үз җырларын ишетте ул көненә мең.
Һәрбер яңа җыры аша гасырларга
бирә барды мизгелләрнең гомерләрен.

Үлем килеп бугазына үрелгәч тә,
төшенкелек баткагына батмады ул,
зинданнарда соңгы сәгатен көткәндә,
өметсезлек ләхетенә ятмады ул.

– Яшәү – ирек, – дип әйтте ул Үлемгә дә, –
ә ирегем дошман табаны астында.
Шуның өчен аермалык күрмим һич тә
Үлем белән болай Яшәү арасында.

Вәгъдә итеп маташтылар аңа ирек...
– Юк, – диде ул, баш тартты ул чын ир булып, –
ил хакына шәһит китү – олы бәхет,
бүләк бәхет – үзең теләп алган коллык.

III

Зинданнарда туган шигырьләрдә
юк үкенү эзе, боегу,
төрмә сакчысының аяк тавышы
кушылса да җырга көй булып.
«Ни сөйләнә тоткын үз-үзенә?..» –
Аңлый алмый төрмә сакчысы.
....
Хәзер Җирнең кайсыдыр төшендә
шул ук сакчы, бәлки, чак посып,
Җәлил шигырьләрен укыйдыр да
искә төшерәдер үткәнен...
Тик белмидер утлы шигырьләрне
үз тоткыны иҗат иткәнне...

Җәлил качмасын, дип, ишеккә ул
автоматтай торган эленеп,
тик белмәгән сакчы Уйлаучының
уен чикләү мөмкин түгелен.
Тик белмәгән: аның эше – зая.
Ул саклаган бары тавышны.
Төрмәләрдән чыгып, Җәлил үзе
мәңгелеге белән кавышты.

Җәлил үзен һич тә кайгыртмады,
кайгыртты ул җырын-канатын:
«Төрмә ишекләрен ватса җырым,
мин Җыр булып илгә кайтамын!..
Сез очыгыз, минем тулпарларым!
Сез җилләрне канат итегез,
утлы, канлы киртәләрне үтеп,
Ватаныма кайтып җитегез!»

«Сездә минем бөтен тойгыларым[2],
сездә минем керсез яшьләрем.
Сез үлсәгез, мин дә онтылырмын,
яшәсәгез, мин дә яшәрмен...»

Урадылар җырлар бар дөньяны,
барлык киртәләрне үттеләр,
йолдыз кәрваннары булып илгә
тезелешеп кайтып җиттеләр.

Йолдызлардан кабыналар таңнар –
шундый көчле алар чаткысы!
Көннәребез балкышында безнең
Җәлил йолдызлары яктысы.

1966 ел

Ренат Харис

Редакциядән: *Танылган каләмдәшебез, Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Ренат Мәгъсүм улы Харисовның (Ренат Харисның) 6 майда гомер бәйрәме. Әдипне юбилее белән ихластан котлап, сәламәтлек, иминлек һәм иҗат уңышлары теләп калабыз!* ■

[2] Бу строфа Муса Җәлилнең «Җырларым» шигыреннән.

«Безнең мирас» котлый!

Танылган шәхесләребез – язучылар һәм сәнгать әһелләре май аенда үзләренең гомер бәйрәмнәрен билгеләп үтә. Менә алар:

1 май – язучы, публицист Мирсәй Гарифка (Марсель Мөхәммәтша улы Гарипов, 1946) 75 яшь

6 май – Татарстанның халык артисты Хафиз Хәниф улы Хәмматуллинга (1961) 60 яшь

9 май – танылган журналист Миңназыйм Мәүлет улы Сәфәровка (1961) 60 яшь

10 май – ТРның атказанган артисткасы, Д.Сираҗиев исемендәге премия лауреаты Рәмзия Зирәк кызы Закирҗановага (1961) 60 яшь

16 май – ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре, язучы Роза Муллануровага (Роза Габденур кызы Камалетдинова, 1946) 75 яшь

20 май – язучы, 2000 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Сәмига Әһлетдин кызы Сәүбановага (1946) 75 яшь

Күренекле шәхесләребезнең барысын да юбилейлары белән ихластан котлыйбыз һәм аларга саулык-сәламәтлек, иминлек, иҗат уңышлары теләп калабыз! ■

Ислам дөньясы

Габдерәшит Ибраһимов

– Сез Япониядә булдыгызмы?

– Булдым, күрдем, ләкин бары көньягында гына булдым. Камакура тирәләрен, Нагасакига кадәрге җирләрне беләм. Японнарның да хәлләре үз мәмләкәтләрендә бик ул кадәрле кызыгырлык түгел: фәкыйрьләре күп, эш юк, бер яктан ачлык та һөҗүм итә. Бик күп кешеләр, түзә алмыйча, үзенә кул сала. Сез игътибар иттегезме: Япониядә үз-үзен үтерүчеләр бик күп. Газеталарны игътибар белән укып барсаң, күренә: бу хәл һәр көн булып тора, кайбер көннәрне берничә дә була.

– Әйе, шулай, ләкин чагыштырмача бу берни дә түгел, хәзерге вакытта Япониядә кеше саны һәр ел биш йөз меңгә арта бара. Шуның белән чагыштырсак, үзенә кул салучыларның саны бик әһәмиятсез булып кала. Газеталарда бу күренми. Бүген Япония кечкенә бер материк кебек, кеше саны күп, тормыш һәр яктан җиңеләйтелгән, телеграф, телефон бар, мәмләкәттә булган вакыйгалар сәгате-минуты белән үзәккә барып ирешә. Үзәктәге газеталар шунда ук хәбәр бастырып чыгаралар. Безнең Русиядә Төркестан, Бохара, Себер, Кавказ якларында булган вакыйгаларның хәбәрләре мәркәзгә килеп җиткәнче искерәләр. Айлар үтеп китә, барыбер бастырып чыгара алмыйлар. Бу җәһәттән [ягъни хәбәрнең тиз таралуы сәбәпле] үз-үзен үтерүчеләр күп кебек тоела. Югыйсә, илле миллион япон халкы арасында биш йөз кеше үзенә кул салса да, бу искитәрлек сан түгел. Мин менә Сездән шул хакта сорарга теләгән идем: японнар ничек букадәр тиз алга киткәннәр, алга китүләренең сәбәбе нәрсәдә, ни өчен Кореяны басып алганнар? Япониядә булганда менә шуларга игътибар иттегезме? Әгәр Сез бу җәһәтләргә игътибар иткән булсагыз, улвакыт Сез дә шундый ук юл белән алга китүнең чарасын эзләр идегез. Японнар милли әхлакларын ни дәрәҗәдә саклаганнар? Сез игътибар итәргә тиешле нәрсәләр менә шулар иде.

– Әлбәттә, ул җәһәтләр турында уйлый алган булсак, без бу хәлгә төшмәс тә идек. Без бүген төнге сәгать 11 тирәсендә Шинкиҗу станциясенә барып җитәчәкбез. Анда бер елга бар. Елганың бу ягы – безнеке, Кореяныкы, икенче ягы – японнарныкы. Японнар ике якта да бар, әйе. Тик бу як электән калган, ә теге якны яңа гына төзекләндерделәр. Бу якка Шинкиҗу диләр, теге як Антоки дип атала. Японнарның ничек алга киткәннәрен менә шунда баргач күрерсез. Без японнарның кем икәнен шунда аңладык.

– Елганың ул ягы сезнеке түгел лә, кытайларныкы.

– Мин дә шуны әйтәсе идем. Японнар бу юл белән Пусаннан Шинкиҗуга кадәр Кореяны икегә бүлделәр. Без бер айда барып кайта торган юлны бер көндә үтәләр. Ләкин күрәсез бит: гаскәри часовой өчен бер генә җирдә дә будка-фәлән куелмаган. Әмма Антокига килгән көнне үк гаскәриләр казармасын, гаскәриләр бүлеген төзеп куйды. Алгарак үткән саен, һәр торак җирендә бер гаскәри бүлеге урнаштырды. Бөтен Кореяда (бары Сеулда гына юк) аларның

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

гаскәре тора. Әмма Кытайда, торак җирләрендә берәр солдаты гына бар. Безнең белән кытайлар арасындагы аерманы килгән көнне үк күрдек. Кытайларга бөтен җәһәттән бик сак мөгамәлә итәләр. Безгә карата исә, әллә бар без, әллә юк – мөгамәлә шундый. Безнең үле милләт булуыбызны килеп урнашканчы ук аңлаганнардыр, мөгаен.

Шул рәвешле, кореялы юлдашым белән рәхәтләнеп сөйләшә-сөйләшә, кичке сәгать 11дә Шинкиҗуга килеп җиттек. Монда туктап та тормыйча, көймәгә утырып, Антокига чыктык. Төнлә шунда бер япон өендә куна калдык.

Антоки

Бу җир – вакытлыча дип төзелгән кечерәк кенә бер авыл. Шактый төзек, ару урамнарындагы күтәртмә юллар бу торак җиренә нәкъ шәһәр кыяфәте биреп тора. Биредә әле моннан өч кенә ел элек бер йорт та булмаган.

Без урнашкан кунакханәнең ике бүлмәсе бар. Берсе – япон кешеләре өчен, икенчесе – Аурупа кешеләре өчен. Икесе дә искиткеч ару. Безнең шәһәрләребездә мондый кунакханәләр бик сирәк очрый.

Антокида яшәүче кешеләрнең күбесе кытай милләтеннән, тик идарә һәм мәнфәгать японнарныкы. Шул ук вакытта кытайлар арасында да бай сәүдәгәрләр, матур кибетләр очрый. Хезмәткәрләр, түрәләр дә бар. «Бу җирләрдә безнең хакыбыз да бар!» – дигәннәр. Бөтенләй калдырып чыгып китмәгәннәр. Кай яктан гына карасаң да, кытайларда тормышның башкачарак булуы сизелә.

Мин инде менә бүген Кытай чигенә аяк бастым, ләкин бу җирләр Япониянең Маньчжурия өлкәсе булып санала. Рус-япон сугышына кадәр әлеге җирләр Русиянең бер өлкәсе иде.

Антокидан Мукденга кадәр тагын ике көнлек юл бар. Ләкин бу җирләрдә поезд юллары да вакытлыча дип салынган, тар, тизлек тә күбесенчә сәгатенә 8 километр гына, кызулаганда да, сәгатенә 12 километрдан артмый, ди.

Июль аеның 24е Антокидан Хотин-Мукденга китәргә дип юлга чыктык. Биредә вагоннар Себернең хайван ташый торган арбаларыннан да начаррак, кичкә кадәр шулай бардык, бик газаплы булды. Юл зур сугыш вакытында вакытлыча дип кенә салынган, дидем. Хәзерге вакытта бик яхшы юл да салынып ята. Тик ул юл әзер булганчы, әле тагын бер-ике ел, чарасыз, бу юлга канәгать булып торачаклар.

Бу юл да японнарның эшчәнлеген һәм, һәрвакыттагыча, аздан башлау кагыйдәсенә тугрылыклы булуларын күрсәтә. Ул – ихтыяҗга бәйле мөгамәлә, ихтыяҗ арткан саен, эшне дә арттыру. Шул ук вакытта, бик зур эшләр баш-

«

– Рус-япон сугышында японнар бирегә кадәр бик авырлык белән килделәр. Гаскәрләре, кораллары һәм көчләре күп булганда, Йало елгасына кадәр килеп җиттеләр, елганы кичкәч, бертуктамый Мукденга кадәр бардылар, руслар инде бу хәлләрдән соң берни эшли алмадылар. Без боларны үз күзләребез белән күрдек. Япон гаскәре елганы сикереп атлагандай чыкты, руслар бер җирдә дә ныклы каршылык күрсәтә алмадылар, зур тизлек белән чигенә башладылар.

карылган: туннельләр төзегәннәр, зур-зур тау башларына кадәр күтәрелгәннәр, япон гаскәрен Маньчжуриягә кадәр китергәннәр.

Юлдашым миңа болай диде:

– Бу җирләрдә яшәү һавасы бар, безнең Кореяда ул юк. Мин кайчакларда, безнең корея милләтен юк итү өчен җибәрелгән начар һава бичара японнарның да башына тия күрмәсен дип уйлыйм.

– Курыкма, японнар аның да бер җаен табарлар. Биредә бөтен юлчылар кытай кешеләре булганга, күңелегез дә кытайлардан нидер өмет иткәнгә, Сезгә шулай тоела. Югыйсә милләтләрнең алга китүендә яки артта калуында һаваның бер катнашы да юк.

– Катнашы булырга мөмкин, тик без аны аңлый алмыйбыз.

– Катгый ышандырып әйтә алам, андый нәрсә юк.

Бик сәер иде. Юлдашым Антокидан соң бөтенләй башка кешегә әйләнде. Үзен тагын да иркенрәк тотып сөйләшә башлады. Мин гаҗәпкә калдым. Әлбәттә, һава тәэсире дигән нәрсә була алмас, ләкин шулай да биредә тормыш бөтенләй башка төрле, бар кешедә дә ниндидер искиткеч эшчәнлек, хәрәкәт сизелә иде. Чагыштырып карасаң, хәл бөтенләй башка. Юлдашым да, үз сүзен исбатларга тырышып:

– Рус-япон сугышында японнар бирегә кадәр бик авырлык белән килделәр. Гаскәрләре, кораллары һәм көчләре күп булганда, Йало елгасына кадәр килеп җиттеләр, елганы кичкәч, бертуктамый Мукденга кадәр бардылар, руслар инде бу хәлләрдән соң берни эшли алмадылар. Без боларны үз күзләребез белән күрдек. Япон гаскәре елганы сикереп атлагандай чыкты, руслар бер җирдә дә ныклы каршылык күрсәтә алмадылар, зур тизлек белән чигенә башладылар. Японнар исә, кайда һөҗүм башласалар, шунда җиңә бардылар. Моны бөтен кытай һәм корея кешеләре күрде, күзләре белән шаһит булдылар. Моннан тыш, мин Сезгә әле менә шуны да әйтергә телим: японнар Йало елгасын кичкәннән соң, җилнең юнәлеше үзгәрде, кыш буе көнчыгыштан көнбатышка таба искән көчле җил, кар-буран русларның күзләрен дә ачтырмады. Тәңре һәрвакыт японнар ягында булды. Мукденда русларны тоташтан әсир алырларына хәтта бик аз гына калган иде. Куропаткин да әсир төшәчәк иде, чөнки аяк төпләренә килеп баскан япон гаскәриен күрер хәлдә түгел иделәр. Кар бөртекләре, пуля кебек, русларның күзләренә кадала иде. Японнар өчен һава шулкадәр уңайлы иде ки, дошманны да күрәләр, җил ярдәмендә бик зур тизлек белән алга томырылып очалар иде. Боларны Сез инкяр итәрсез, ләкин без үз күзләребез белән күрдек, ничек инкяр итә алыйк. Рус гаскәре өчен һава бер дә уңайлы булмады. Башка вакытларда юнәлешен дүрт якка үзгәртеп торган җил ул вакытларда, нәкъ биш ай буе, бертуктамый гел бер якка гына исеп торды.

Менә шундый сүзләр сөйләп, юлдашым бик күп дәлилләр китерә, фикерендә нык торырга тели иде. Чып-чын әфсен-төфсенгә ышану шушы инде. Корея милләтенең фикер ияләре менә шулкадәр аңлый ала.

Антокидан чыгып китүгә, юлчыларның күбесе кытай кешеләре икәнлеген күрдем. Ә хезмәткәрләр исә, кая гына карама, барысы да япон кешеләре иде. Бу хезмәткәрләр бичара кытайларга мыскыллап, түбәнсетеп карыйлар, аларны гел буйсындырып тотарга телиләр. Кытайлар аларның бу мөгамәләсен аңлыйлар, карап торышка буйсынган, итагатьле булып күренсәләр дә, коточкыч дошманлык хис итүләре барыбер сизелә иде.

Мин кореялы юлдашыма болай дидем:

– Карагыз әле менә шул кытайларга, никадәр нык алар. Күрәсезме, биредә японнар – хезмәткәр, түрә, ә кытайлар – сәүдәгәр, сәнгать остасы. Тирә-юньгә бер карансагыз, корея кешеләре белән кытайлар арасында бик зур аерма күрерсез. Бөтен Кореяны үттек, поезд станцияләрендә сөт, йомырка саткан бер корея кешесе дә күренмәде, ә биредә, карагыз: сөт, йомырка, икмәк, ит – бар нәрсәне дә кытайлар сата. Яшәү әсәре менә шул инде! Тереләчәк милләттә бераз шундый хәрәкәт күренә. Бик дөрес, корея халкында тормыш әсәре калмаган.

Мин бу сүзләрне әйткәндә, кореялы юлдашым елап җибәрергә җитешкән иде инде.

Ул көнне кичкә таба Җавко станциясенә килеп җиттек.

Биредә дә станция тирәсендә япон хезмәткәрләре күренә. Тик халыкның барысы да – кытайлар. Болар арасында мөселман бармы-юкмы, кызганыч, аңлап булмый, чөнки кием-салымнарында бернинди дә аерма юк, чәч, тырнак барысының да бертөрле. Тик барыбер башымда биредә мөселманнар булырга тиеш дигән уй бөтерелә.

Бу якларда поездлар төнлә кузгалмый икән. Бу төнне монда үткәрәсе булганга, бер кунакханәгә тукталдым. Кунакханәнең хуҗасы япон кешесе иде, эшчеләрнең исә барысы да кытай мөселманнары икән. Мин кичке намазымны укыганда игътибар иткәннәр, ашарга утыруга, берсе яныма килде. «Ансаләм алейкун», – дип сәлам бирде. Шунда мин дә япончa: «Бу тирәдә мөселманнар бармы?» – дип сорадым. Моңа каршы: «Станция тирәсендә юк, әмма авылларда, шәһәрчекләрдә бик күп», – дигән җавап алдым.

Иртәгесе көнне аннан кузгалып киттек һәм Мукденга килеп җиттек. Тик Мукден атамасын беркем белми иде.

Мукден

Мин менә тагын Маньчжуриядә, Кытай җирләрендә. Бу җирләр Аурупа телләрендә Мукден буларак билгеле булса да, японнар, кореялылар, маньчжурлар аны Хотин дип атыйлар, ә кытайлар Ший-Йак диләр икән.

Мин Мукденга килгән көн җомга иде. Әйберләремне кунакханәгә урнаштырдым да шунда ук шәһәргә киттем. Җомга намазын укыр өчен мөселман мәхәлләсе таба алырмынмы икән дип уйладым. Вакыт та бик аз калган иде инде.

Поезд станциясеннән шәһәргә трамвай йөри икән. Трамвайга утырып шәһәр үзәгенә барып җиткәч үк: «Коко хой хой йумйу? [Биредә мөселманнар бармы-юкмы?]» – дип сорадым. Берәү: «По [Бар]», – диде.

Шунда ук, як-ягыма карана-карана мәчет эзлим – күренми. Кытайлар мәчет димиләр, кытайча: «Лэ бэй су?» – дип сорадым. Юл күрсәттеләр. Йөгерә-атлый барып җиттем, намазга җыела башлаганнар иде инде.

Биредә нәрсә бар, нәрсә юк – бераз беләм, чөнки Цицикарда күргән идем. Кытай мәчетләрендә тәһарәт алыр өчен һәрвакыт җылы су бар. Истинҗа, абдәст, госел[1] өчен аерым урыннар бар. Барысында да җылы су да, сабын да бар. Мин, бик яхшылап юынып, җомга намазын укыдым.

Ах, намазда укылган бичара хөтбә! Мин башта хөтбәне кытайча укый да, шуңа аңлый да алмыйм, ахры, дип уйладым, аннары гына аера алдым: гарәп телендә укый икән ләбаса. Аннары намазга бастык. Монда укылган «Фатиха» сүрәсе – Аллаһ сакласын! Бик аяныч хәлләр! Бөтен «Фатиха» сүрәсеннән «галәмин» белән «нәстәгыйн» генә аңлашыла. Башка сүзләр бөтенләй юк дәрәҗәсендә.

[1] Истинҗа, абдәст, госел – гәүдәнең аерым өлешләрен шартларына туры китереп юу, арулану төрләре *(тәрҗ. иск.)*.

Мукден. XX гасыр башы

Кытайларның намазга билгеләнгән кәләпүшләре бар, намаз укыганда чәчләрен шул кәләпүш астына җыялар. Чалманы бары тик голәмәнең һәм шәкертләрнең башында гына күрергә мөмкин.

Чалма да, кәләпүш тә бары тик намазда гына киелә. Мәчеттән чыга-чыгышка, кәләпүшләрен салып, милли баш киемнәрен кияләр. Шуңа күрә мөселман кытайны мәҗүси кытайдан аерып ала алмыйсың.

Мәчетләренең эче нәкъ мәчет кебек: шәмаилләр, намазлыклар бар; ләкин тышкы яктан мәчеткә бер дә охшамаган. Бөтен мәчетләре дә шулай, кытай гыйбадәтханәләреннән берни белән дә аерылмый. Бигрәк тә мәчетнең өстендәге төрле хайван һәм хәшәрәт сурәтләре һич кенә дә кабул ителер нәрсәләр түгел, әмма җаһиллек нәрсәне генә кабул иттермәгән?!

Намаз укулары тулысынча хәнәфи мәзһәбендәгечә, хәрәкәтләре, торулары безнекеннән аерылмый. Тик Коръән укулары гына кешене өметсезлеккә дучар итә.

Биредә, җомга намазы укылганнан соң, минем чит ил кешесе икәнемне аңлап булса кирәк, берничә кеше яныма килде. Берсе: «Менке», – ягъни: «Мәккәдәнме Сез?» – диярга теләде. «Мей йу [Юк]», – дидем. Гаҗәпләнгән кебек бер-берсенә карашып алдылар, аннары мине мәдрәсәгә чакырдылар. Имам-ахун шунда иде. Берсе: «Әнтә йагләмү лисан-ел-гарәп? [Син гарәп телен беләсеңме?]» – диде. Ахун җәнаплары шулкадәр генә гарәпчә белә икән. Шулай да белгән кадәре дә безгә ярап куйды. Чәй китерделәр. Үземнең гарәп түгеллегемне, Мәккәдән дә килмәгәнемне аңлата алдым, шуның белән бергә, миңа хөрмәт тә артты. Ашарга да китерделәр. Кунак булып калыр өчен урын да бүлделәр. «Мукденда күпмегә калсагыз да, менә шунда яшәрсез», – дип, мәдрәсә бүлмәләренең берсен миңа бирделәр, шулай зур кунакчыллык күрсәттеләр.

Кунакханәдә калдырган әйберләремне бирегә китердем һәм мәдрәсәдә кунак булып яши башладым.

Биредә үземә тәрҗемәче була алырлык бер хаҗи таптым: Хиҗазда булган, бер ел Мәккәдә яшәгән бер кеше. Исеме – Мөхәммәт Җәмалетдин, хәлен сөйләп аңлатырлык гарәпчәсе дә бар.

Иң башта бу хаҗидан Маньчжурия мөселманнары турында бераз мәгълүмат алдым. Хаҗи әфәнде шактый фикерле ала торган кеше иде, Кытай мөселманнарының бу кызганыч хәлләренә бик кайгыра икән. Ул көнне кичкә кадәр һәм аннары төнге өчкә хәтле сөйләде дә сөйләде. Үзе гаять диндар кеше булганга, елап та җибәрә иде:

– Исламият бу җирләргә Хәзрәте Пәйгамбәр заманында килгән. (Бөтен кытайлар да шуңа ышана.) Хак дин ислам Саад ибн әбү Ваккас җәнаплары тарафыннан өйрәтелгән. Аннары җаһиллек өстенлек алып, бу хәлгә төшкәннәр. Бүген бөтен Кытай илендә (Төркестан Кытае, Кансу, Шанси өлкәләрен санамыйча) исламиятнең бары исеме генә калган. Мәҗүсилек исламияттән өстен чыгып, барлык мөселманнар мәҗүсилекне бөтен төгәллеге белән кабул иткәннәр. Бүген Кытайда мәҗүси белән мөселман кешесен аерып алып булмый. Без исламияттән бик ерак калдык. Шулай була торып, үз хәлебезне үзебез белмибез. Сез күрәсезме: бөтен Маньчжуриядә миннән кала бер хаҗи да юк. Хаҗ турында сүз дә була алмый, инде намаз да голәмәгә вазыйфа булып калган, гади халык арасында намазның нәрсә икәнен, аны ничек укырга кирәклеген, кагыйдәләрен белүче дә юк.

Хатыннарыбызда госел юк, хиҗап бөтенләй юкка чыккан. Дингә бәйләнешле бары тик ышанулары һәм ишекләребезгә язылган «Кәлимә-и тәүхид» кенә бар. ИншәАллаһ, калебләребездә дә бардыр. Хәерчелек чиктән ашкан. Христиан миссионерлар бик күп. Болар турында уйланып газапланам. Хәлебезне аңлаучы юк, аңлатыр мөмкинлегебез дә юк. Аңлатырга маташсаң, турыдан-туры, бозык мәзһәпле, диячәкләр. Бирегә Мәккәдән бик күп кеше килә. Милләтне алдап-юллап, мүтга никахы[2] белән 10-12 яшьлек кызларыбызны кияүгә бирәбез. Һәр кич берсен кияүгә бирәбез, аннары ул кызларда гыйффәт калмый. Җаһиллек исә моны матурлап күрсәтә. Болар барысы да дин исеме белән башкарыла. Безнең хәлебезне белсәгез, елыйсыз. Карагыз инде шул чәчләребезгә, шул тырнакларыбызга. Ислам әдәбенә туры киләме болар?! Мин Хиҗаздан чәчсез, тырнаксыз кайттым, мине үтерә яздылар. Аннан соң кабат бу чәч койрыгын үстерергә мәҗбүр булдым, 10 елда менә шундый койрык үстердек...

Безнең Мөхәммәт Җәмалетдин хаҗи әфәнде ачылганнан-ачыла бара иде. Ниһаять болай диде:

– Сез бирегә озак торырсызмы икән?

– Бер атна тирәсе.

– Алайса мәхәллә халкы Сезгә өйләнергә тәкъдим итәчәк. Бер атна буе никахсыз [өйләнмәгән, ягъни янығызда хатыныгыз юк килеш] яшәвегез безнең Маньчжурия мәзһәбе буенча дөрес түгел.

– Бу минем шәхси эшем түгелме?

– Шәхси эшегез, ләкин мин мондый бер тәкъдим булачагын күзаллыйм. Әлбәттә, Сезнең кабул итмәячәгегезгә дә ышанам.

– Сез борчылмагыз, мин иртәгәдән башлап Мукденның әйләнә-тирәсен карарга чыгачакмын. Шәһәргә бары тик кич җиткәч кенә кайтачакмын.

– Бик яхшы. Кабул итсәгез, мин дә Сезгә юлдаш булырмын.

*Төрекчәдән **Асия Рәхимова** тәрҗемәсе* ■

[2] Мүтга никахы – шигыйларда очрый торган, ләкин шәригать буенча тыелган никах төре; ир белән хатынның билгеле бер вакыт өчен генә никах укытып өйләнешүе *(тәрҗ. иск.)*.

Үтәмеш: беренче мәхәллә тарихы

Нияз Исхаков, Резеда Исхакова

Соңгы елларда авыллар тарихы белән кызыксыну көчәйде. Татарстанның Апас, Тәтеш, Чирмешән һәм Лениногорск районнарында Үтәмеш атамалы авыллар бар. «Безнең мирас» журналының 9 нчы (2017), 5 нче һәм 7 нче (2020) саннарында Урманасты Үтәмешнең (Чирмешән районы) һәм Тәтеш районына кергән Үтәмешнең тарихын яктырткан мәкаләләр басылып чыккан иде. Тәтеш районындагы Үтәмешнең үткәнен ачыклау максатында уздырылган яңа эзләнүләребезнең нәтиҗәсе буларак, өстәмә мәгълүматлар табылды. Шуңа күрә журнал укучыларын авыл мәчетләре тарихын тулыландыра алырлык хәбәрләр белән таныштырырга ният иттек.

Сембер губернасының картасында (фрагмент) Үтәмеш авылы. 1906 ел

Октябрь инкыйлабына кадәрге заманнарда мәчетләрне төзү шартлары һәм аларның төрләре закон актлары белән билгеләнгән. Мәчет салуга рөхсәт алу

өчен беренче шарт булып мәхәлләдә 200-300 ир җенесендә булучыларның яшәве таләп ителгән. Мәчет булмаган очракта авыл халкы күрше авыл мәчетенә беркетелергә тиеш булган. Ул чорда Россиядә мәчетләрне ике төргә бүлгәннәр: көндәлек биш вакыт намаз уку өчен җайлаштырылган биналар – мәхәллә мәчетләре һәм җамигъ мәчетләр. Әгәр авылда ике йөздән ким ир заты яшәсә, мәхәллә мәчетен төзи алганнар, андый мәчеткә манара кую рөхсәт ителмәгән. Җомга һәм гает намазлары бары тик җамигъ мәчетләрдә генә укылган.

Мәчетне үзгәртеп кору

XX гасыр башыннан Үтәмеш – ике мәчетле авыл. Ике мәчеткә ике мәдрәсә була. Беренче мәчет Сембер губерна идарәсендә җамигъ мәчет булып 1838 елда исәпкә алына. Мәчет 1882 елда үзгәртелә: бина ике катлы итеп корыла, аның аскы каты мәктәп итеп файдалануны күз алдында тотып эшләнә, керү-чыгу өчен икенче ишек урнаштырыла, зур булмаган мәйданлы өйалды булдырыла, мәчет түбәсе такта белән ябыла. Мәчетне үзгәртеп кору планы губерна идарәсендә карала һәм раслана. Бу эшләрне оештыручы төркемгә мәхәллә халкыннан Сөләйман Җаббаров һәм авыл старостасы Ихсан Хәсәнов керә. 1883 елда мәчет каршында мәктәп ачыла. Оренбург Диния нәзарәте фондында да шул ук еллар күрсәтелгән. Икенче җамигъ мәчет 1903 елда салынган. Бу вакытта авыл халкының гомуми саны 1077 кеше, ике мәчеткә караган мәхәллә кешеләре: ир-атлар – 563, шул исәптән гаилә башлыклары 200 кеше тәшкил итә.



Мәчет сызымнары: үзгәртеп корылуга кадәр (1873 ел); яңартып төзү планы (1882 ел)

Шулай да, ике архив документларында бертөрле вакыт – 1838 ел күрсәтелгән булуга карамастан, Үтәмеш мәчетләренең тарихы моннан күпкә алдарак башланган икән. Мәгълүм булганча, патша Россиясе заманында гражданнар хәле актларын мәчетләрдә метрикаларга язу 1828 елда башлана. Метрика язулары ике дәфтәрдә алып барылган. Аларның берсе ел ахырында Диния нәзарәтенә тапшырылган, икенчесе мәчеттә саклаган. Әлбәттә, бу тәртип барлык мәчетләрдә берьюлы тормышка ашырылмый. Аны гамәлгә кую өчен берникадәр вакыт кирәк була. Татарстан һәм Башкортстан Дәүләт архивларыннан Үтәмеш мәчетләрендә язылган метрикаларның мөмкин булган кадәр тулы күләмдә күчермәләрен соратып алдык. Иң элекке булган һәм 1833 елда язылган метрика кенәгәсендә мондый сүзләр бар: *«Сенбер* (ул заманда шәһәр Сембер түгел, ә Сенбер дип атала. – Авторлар) *өязе Үтәмеш иленең соборной мулла вә мөхтәсыйб Минуш Мостай углы никах хөтбәсенең укыдыкымга әлимза өчен кулым куйдым».* Шулай булгач, Үтәмештә 1833 елда ук инде мәчет булган һәм имам-җәмигъ вазыйфаларын Мостай улы Минуш башкарган. Бу мәгълүмат билгеле булгач, Сембер губерна идарәсе архивында күрсәтелгән *«...соборная мечеть построена в 1838 г.»* дигән язуны ничек аңларга? Әлбәттә, Үтәмештә мәчет 1833 елда инде эшләгән, әмма губерна идарәсендә мәчет рәсми рәвештә 1838 елда гына исәпкә алынган. Ул чорларда яңа мәчетләрне төзү эшләре тәмамлангач ук хөкүмәт органнарында теркәү катгый рәвештә таләп ителмәгән дип фикерләү нигезле булып күренә.

Беренче имам – Минуш бине Мостай

Әйе, Үтәмешнең архивларда саклана торган метрика кенәгәләре 1833 елдан алып барылган. Тик монда сорау туа: Үтәмештә мәчет 1833 елда ачылганмы һәм шул елда, мәчет ачылгач ук, метрикалар да языла башлаганмы? Бәлки, Үтәмеш моңа кадәр күпмедер еллар элегрәк мәчетле авыл булгандыр? Бу сорауларга анык җавап бирү мөмкин булмады. Шулай да, мәчетләр тарихын барлау өчен әлеге сорауларның мөһим икәнен күз алдында тотып, мәсьәләгә мөмкин булган күләмдә ачыклык кертү теләге табигый булып күренде. Шушы юнәлештә тикшеренүләребез нәтиҗәсе: 1833 ел да әле Үтәмеш мәчетләре тарихының башлану датасы түгел икән. Бу хәл 1922-1936 нчы елларда Диния нәзарәте мөфтие булган Ризаэддин Фәхреддиннең биобиблиографик хезмәте «Асар» белән танышкач ачыкланды. «Асар»ның икенче томында мондый эчтәлекле текст бар: *«Минуш бине Мостай бине Исмәгыйль бине Әхмәд бине Уразлы бине Уразай бине Уразгилде, Сембер ягында Үтәмеш авылында имам булып, 1269/1853 елда вафат булды. Бу кемсә үз тәрҗемәи хәлен болай яза: «Атабыз Мостай 1791 елда купец булып Казанга күчте, 1796 елда Буага кайтты, 1810 елда вафат булды. Мин 1793 ел апрелендә Сары Кокшай өязе Шинбер авылында имам булдым, 1812 елда имамлыкны ташлап кайттым вә шул елда Сембер өязе Үтәмеш авылында имам булдым. 1830 елда Уфа шәһәренә барып Мәхкәмә шәргыядә имтихан кылындым. Исмәгыйль бабайның Исхак, Мәүлүд, Мансур, Мостай исемле уллары булган. Исмәгыйль вафат булганда, атабыз Мостай бер яшендә калып, анасы Гайшәбикә тәрбиясендә тәрбияләнгән». Сахибе тәрҗемәнең төрле мәсьәләләрдә осталыгы булып, үз кулы белән күп китап вә Кәлам Шәриф язган – күчергән, ләкин язылган әсәрләре барысы янгыннарда янып, югалып беткән, диләр».*

Сары Кокшай – Царевококшайск. Мари Эл Республикасының башкаласы Йошкар-Ола 1919 елга кадәр шулай атала һәм өяз башкаласы була. Мәхкәмәи шәргыя – Диния нәзарәте. Анда халык тарафыннан имамлыкка сайланган дин әһелләре имтихан тотып, тиешле шаһәдәтнамә алганнар.

Татарстанда Ураз исемен кулланып аталган берничә авыл бар. Аларның берсе Яшел Үзән районының Мари Эл Республикасы чигендә урнашкан Уразлы авылы. Шинбер авылы Уразлыдан ерак түгел. Әйткәннәрдән чыгып, Минуш Мостай улы тумышы белән шушы Уразлы авылыннан булуы мөмкин дип фаразлыйбыз.

Татар китапларын һәм Коръәнне күчереп язу белән XVII-XIX гасырларда шөгыльләнгән осталар исемлегендә Минуш Мостай улының булуы турында башка чыганаклардан да билгеле. Шулай булгач, *«...язылган әсәрләре барысы янгыннарда янып, югалып беткән»* дип әйтү чынбарлыкка туры килми.

Минуш Мостай улы кырык елдан артык вакыт аралыгында Үтәмештә имамлык итә. Бу елларда **Хәбибулла Габделбакый улы** һәм **Габделвахид Вәлит** улы мәзин булалар.

1852 елда төзелгән метрика күчермәсе архивта юк. Ихтимал, моның сәбәбе – Минуш Мостай улының сырхау булуыдыр.

Минуш Мостай улының Фәхретдин, Мифтахетдин (гомер иткән еллары – 1809-1868), Хөснетдин, Исмәгыйль, Хисаметдин һәм Хөсәен исемле уллары була. Алар Үтәмештә яшәгән. Метрикалардан Фәхретдин, Мифтахетдин һәм Исмәгыйльнең Үтәмештә узган никах мәҗлесләрендә шаһит рәвешендә катнашуы билгеле. Буа мещаны Исмәгыйльнең Хөсәен исемле улы була. Ул, мирас буларак, аның улы Хөсәенгә дә күчкән. Хөснетдин – Самара ахуны Шиһабеддиннең (1855-1930) атасы. Хисаметдин Минуш улы хәзерге көндә Татарстаннан ары да билгеле булган һәм күптармаклы Минушевлар нәселенең башлангычы була.

Беренче мәчет имамнары

Минуш Мостай улы вафат булгач, аның урынына имам һәм мөгаллим булып улы **Хөснетдин** кала. Моңа ул 1853 елның гыйнварыннан керешә. Әмма бу хәл озак дәвам итми. 1859 елның 3 гыйнварында Үтәмештә төзелгән метрикада: *«Бакырчы иленең указной мулла Фазлулла мулла Габделбасыйр углы никах хөтбәсене укыганыма вә собраниегә тиешле акча алганыма әл-имза кылдым»,* – дип язылган. Бу вакытта Үтәмеш мәчетендә имам вазыйфасын башкаручы булмый. Хөснетдин Минуш улы *«27 яшьләрендә вакытында»* дөньядан китә.

«Асар»ның бер китап итеп 2010 елда нәшер ителгән өченче-дүртенче томнарында Ризаэддин Фәхреддин аның улы хакында мондый мәгълүмат китерә: *«**Шиһабеддин бине Хөснеддин** бине Минуш Самара шәһәрендә имам вә ахун һәм дә мөдәррис булып, 73 яшендә вакытында өч йөз кырык тугызынчы (1349/1930) елда вафат булды вә Самарада ислам мәкъбәрәсенә дәфен ителде. Шиһабеддин ахун 1855 ел миладидә дөньяга килеп, атасындан бер яшендә вә анасындан да сабый хәлендә ятим калган вә атасының туганнары тәрбиясендә үскән, вә авыл мәктәбендә укыган».*

Шиһабетдин Хөснетдин улы дини белемне, 16 яшьләрендә Буа шәһәренә барып, Татарстанның иң борынгы дини уку йортларыннан булган Габденна-

сыйр бине Мөхәммәдәмин мәдрәсәсендә алган. Ул беркадәр вакытлар шул мәдрәсәдә хәлфәлек итеп, шәкертләр укытып торган. 1888 елда Самара мөселманнары җыенында имам булып сайлана. Шиһабетдин шул ук елның 2 мартында Үзәк диния нәзарәтендә имтихан тапшырып, имам-хатыйблык шаһәдәтнамәсе ала һәм мөдәррис булырга лаеклы дигән дәрәҗәгә дә ирешә. 1888 елның 8 апрелендә ул, губерна идарәсе карары белән, Самара мәчетенә имам-хатыйб итеп билгеләнә. 1890 елны Диния нәзарәте аңа ахун исеме (дәрәҗәсе) бирә. Шиһабетдин шуннан соң Самара губернасы буенча ахун булып та хезмәт итә. Русча язылган кәгазьләрдә култамгасын ул *«Ахун Ш.Х.Минюшев»* дип куйган.

Хөснетдин Минуш улыннан соң, 1859 елның февралендә Үтәмеш мәчетенә *«имам-җәмигъ хатыйб вә мөгаллим»* булып **Хөснетдин Габдулла улы** билгеләнә. Ул Буа өязенең Янтуган авылыннан килгән.

1884 елның 5 июлендә *«имам-хатыйб, җәмигъ һәм мөгаллим»* булып **Хәйретдин Хөснетдин улы Габдуллин** раслана. Ул вакытта аңа 40 яшь булган. Бу вазыйфаларны ул бакыйлыкка күчкәнче, 1905 елның 8 февраленә кадәр үти. Аның үлеме турында метрикага Үтәмешнең икенче мәхәллә имам-хатыйбы Лотфулла Хәсән улы язып куя.

Хәйретдин Хөснетдин улы урынына, аның вафатыннан соң, имам-хатыйб булып **Сөнгатулла Хөснетдин улы** (1874 елда туган) сайлана. Хәйретдин һәм Сөнгатулла – туганнар. Аларның туган җире – Буа өязенең Янтуган авылы. Үтәмешкә килгәнче, Сөнгатулла Хөснетдин улы Буа өязенең Карлы вулысындагы Иске Тинчәле авылының 4 нче мәчетендә указлы мулла булып эшли. 1916 елда вафат була.

Беренче мәхәллә мәчетенең 1916 елда туганнарны язу кенәгәсе ахырында мондый сүзләр бар: *«Бу метрика эшләрен караучы мулла Сөнгатулла мулла Хөснеддин углы вафат улдыгыннан, вөҗүд фасылында һичнәрсә язылмай, ак рәвештә калган иде. Хатирә дәфтәрендән һәм балаларның аталарындан мөмкин кадәре югарыда язылган кадәрене җыярга булдык»*. Бу сүзләрне икенче мәхәллә имамы **Мөхәммәдгариф Хөснетдин улы Рәшитов** язган. Димәк, 1916 ел ахырында Мөхәммәдгариф Хөснетдин улы, беренче мәхәллә мәчетенә килеп, шул елда мәхәллә метрикасын тутырган. Әмма бу язулар тулы түгел. Мәсәлән, дөньяга туган сабыйлар исемлегендә Сәрия Зыяэддин кызы Батталованың теркәлмәгән булуы ачыкланды. Бу хәлне без нәсел шәҗәрәбезне төзү өчен мәгълүмат туплаганда аңлый алдык. Нәтиҗәдә, метрика язуларын булдыруның үзенчәлекле яклары да мәгълүм булды.

1917 елның 8 июнендә 1 мәхәллә мәчетенә имам-хатыйб булып Буа районының Әлши авылында 1891 елда игенче гаиләсендә туган **Камәретдин Баһаветдин улы Салихов** билгеләнә. Ул 1912 елда Буа мәдрәсәсен тәмамлаган һәм шунда 1917 елга кадәр укытучы булып калган. Үтәмештә 1924 елга кадәр эшләгән. Бу еллар гаять катлаулы иҗтимагый-сәяси вакыйгаларга бай була. Һәр кешедән тормышта үз юлын билгеләү һәм алган юнәлешен эзлекле рәвештә дәвам итә алу өчен чын мәгънәсендә каһарманнарча көч кую таләп ителгән. Көтелмәгән хәлләрдән сакланып кала алу да җиңел булмаган. Шундый очраклы хәлләрнең берсенә Буада булган вакытта Камәретдин Баһаветдин улы да юлыга. Камәретдин 1920 елда Буада Советлар алып барган сәясәткә каршы оештырылган җыенда катнашучылар белән бергә кулга алына һәм ирегеннән

Камәретдин Баһаветдин улы – Мәскәүнең җәмигъ мәчетендә имам-хатыйб. 1956-1963 нче еллар



Үтәмеш мәчетендә 1833 елда барлыкка килгән метрика кенәгәсе. Минуш Мостай улы никах хөтбәләре укуны язган бүлектән күчермә

мәхрүм ителә. Бер елдан соң иреккә чыга. Моңа авылдашларының яклавы, чыгышы белән ярлы гаиләдән һәм *«кызыл мулла»* (Совет хакимиятенә лояль) икәнлеге нигез. Дистә еллар узганнан соң да, үтәмешлеләр Камәретдин Баһаветдин улын олы хөрмәт белән искә алуны дәвам иттеләр. Өлкән яшьтәге авылдашлар, үзләренә карата күрсәткән онытылмас хезмәтләре өчен аңа рәхмәтле булып, *«Камәр мулла»* дип әйтә торганнар иде.

Камәретдин Баһаветдин улы 1945-1952 нче елларда – «Мәрҗани» мәчетендә, 1952-1956 нчы елларда Әстерхан җәмигъ мәчетендә имам-хатыйб була. Имамлык хезмәтен Үтәмештә башлаган дин әһеле СССРда мөмкин булган иң югары дәрәҗәгә күтәрелә – 1956 елның 26 июнендә Мәскәү җәмигъ мәчетенә имам-хатыйб итеп билгеләнә. Камәретдин Баһаветдин улы 1963 елда вафат була. Дөньякүләм билгеле шәхес Мәскәүнең Данилов мөселман зиратында җирләнгән. ■

Безнең мирас №5 май 2021

СӘЙФ САРАИНЫҢ ТУУЫНА 700 ЕЛ

«Игү аты»н калдырган инсан «үлемсез»*

Хатыйп Миңнегулов, филология фәннәре докторы

Дәгел ирлек – агызга йомрык (йодрык. – **Х.М.**) ормак,
Ир исәң – кой агызга бал вә каймак.
***
Сән игү бул, йаман дисен хәлаек (халык. – **Х.М.**),
Йаман булыб сәңа йахшы дигәнче.

***

Сәйф Сараи. ***Надия Фәхретдинова рәсеме***

Үзенең тамырлары белән ерак үткәннәргә барып тоташкан сүз сәнгатебез «хәзәр-болгар-кыпчак» дип йөртелгән чорда шактый гына үсеш ала. Кол Галинең атаклы «Кыйссаи Йосыф»ы, Дауд Сөләйман Саксинының аерым парчалары – үзләре генә дә күп нәрсә хакында сөйли. XII-XIII гасырларда яңа дулкын булып күтәрелгән бу хәрәкәт Алтын Урда чорында тагын да киңәя, тирәнәя һәм тизләнә бара. Әдәбиятыбызга Котб, Харәзми, Мәхмүд Болгари, Хисаб Кятиб, Әхмәд Хуҗа-Сараи, Мәхмүд Сараи-Гөлестани, Габделмәҗид кебек берсеннән-берсе талантлырак каләм әһелләре килә, сүз сәнгатебезнең төрле тармакларында һәм жанрларында күпләгән әсәрләр иҗат ителә. Болар арасында шагыйрь, прозаик, тәрҗемәче Сәйф Сараи (1321-1396) бик тә күркәм һәм үзенә лаеклы урынны били. Идел-йортта туып, Камышлы һәм Сарай шәһәрләрендә яшәп, гомеренең ахырын Мисырда уздырырга мәҗбүр булган әдипнең туына быел якынча 700 ел тула. Ни үкенеч, шагыйрь иҗатының хәзергә тик бер өлеше генә билгеле. Ул «Китабе Гөлестан бит-төрки» һәм «Ядгярнамә» дип исемләнгән ике кульязма аша мәгълүм. Урта гасырларда Мисыр-Сүрия та-

* Милләттәшләребезнең тарихи Ватаннарыннан читтә дә әдәби иҗат белән шөгыльләнүләре соңгы дәверләрдә генә түгел, элекке заманнарда да күзәтелә. Сәйф Сараи иҗаты да — мөһаҗирлектәге татар әдәбиятының бер мисалы.

рафларында төзелгән бу ядкярләр хәзерге вакытта Голландиянең Лейден университеты китапханәсендә һәм Ташкенттагы Кульязмалар институтында саклана. Алар узган гасырның өченче чирегендә ныклап өйрәнелә башлады, диссертация-монографияләр, күпләгән мәкаләләр язылды. Шагыйрьнең әсәрләре Төркиядә, Будапештта, Казанда, Ташкентта… дөнья күрде. Әмир Нәҗип, Хатыйп Госман, Зәйнәп Максудова, Рәшит Кадыйров һәм кайбер башка татар галимнәре үзләренең бөек бабалары Сәйф Сараины өйрәнүдә һәм пропагандалауда аеруча тырышлык күрсәттеләр. Без фәкыйрегез дә бу игелекле эшкә булдыра алган кадәр үз өлешен кертте: 1972 елда «Сәйф Сараиның тәрҗемә һәм оригиналь әсәрләре» темасына кандидатлык диссертациясе яклады. Ул «Сәйф Сараи. Тормышы һәм иҗаты» исеме астында аерым китап рәвешендә басылып та чыкты (Казан университеты нәшр., 1976. – 190 б.). «Татарская литература и Восточная классика (Вопросы взаимосвязей и поэтики)» атамалы докторлык диссертациябезнең (1991) һәм монографиябезнең (Изд. КГУ, 1993. – 384 с.) зур бер бүлеге дә шушы әдипнең иҗатын гыйльми яктыртуга багышланган. Шулай ук Хатыйп Йосыф угылының төрле телләрдә Сәйф Сараига мөнәсәбәтле күпләгән язмалары бар. Шул исәптән алты һәм сигез томлык «Татар әдәбияты тарихы» китапларының 1984, 2014 нче елларда дөнья күргән беренче томнарында, мәктәп-гимназияләр, югары уку йортлары өчен язылган дәреслек-хрестоматияләрдә дә. Хатыйп Миңнегулов өчен аеруча куанычлысы шул: ул әдипнең хәзергәчә билгеле барлык әсәрләрен туплап, тиешле шәрех-аңлатмалар, кереш һәм хатимә белән 1999 елда аерым җыентык рәвешендә нәшер итте: «Сәйф Сараи. Гөлестан. Лирика. Дастан» (Казан: Татар.кит. нәшр., 1999. – 296 б.). Шагыйрьнең аерым әсәрләре урыс, инглиз һәм кайбер башка телләргә дә тәрҗемә ителгән. Кыскасы, Сәйф Сараи белән ныграк кызыксынучыларга укыр өчен шактый гына басмалар бар. Шуңа күрә без бу язмада әдип иҗаты хакында гомуми белешмә бирү белән чикләнәбез.

С.Сараи мирасындагы иң күләмле әсәр – «Гөлестан бит-төрки» (1391), ягъни «Төркичә Гөлестан». Ул дөнья сүз сәнгатенең иң бөек әдипләреннән берсе – фарсы классигы Сәгъди Ширазиның (13 нче йөз) шул исемдәге китабына (1258) нигезләнеп язылган. «Гөлестан» тоташ сюжетлы әсәр түгел. Ул чәчмә һәм тезмә юллар катнаштырып иҗат ителгән «хикәят», «нәсыйхәт», «хикмәт» дип исемләнгән композицион берәмлекләрдән гыйбарәт. Алар 8 бабка бүленгән. Берничә битне кереш, хатимә тәшкил итә. Аларның күп өлеше татар шагыйренең үз иҗат җимеше. Үз туган теленнән тыш, фарсы-гарәп телләрен дә камил белгән С.Сараи, гомумән, оригиналга, аның төзелеш-структурасына, сюжетларына тугрылык саклый. Татарча текстта, бигрәк тә аның чәчмә өлешләрендә тәрҗемәнең классик үрнәкләре бар. Әмма татар шагыйре еш кына фарсыча әсәрнең, аеруча шигъри юлларның эчтәлек-мәгънәләрен бирүдә төрлечә эш итә. Биредә, төгәл тәрҗемә үрнәкләре белән бергә, иркле, иҗади тәрҗемәләр дә, шактый гына оригиналь юллар да күзгә ташлана. Татар авторы, барыннан да элек, Сәгъди «Гөлестан»ындагы гомуми рухны сакларга, аны үз укучысына җиткерергә омтыла. Шул асыл максатны күздә тотып, андагы кыйммәтләрне тагын да тулыландыра, көчәйтә торган фикер-кичерешләрен, сурәт-детальләрен дә әсәр тукымасына кертеп җибәрә. Болар бар да «Гөлестан бит-төрки»нең соңгы дәвер укучылары күнеккән тәрҗемә кысаларында гына калмыйча, аны чагыштырмача мөстәкыйль идея-эстетик кыйммәткә ия булган әсәр дип карауга да нигез бирә. Ул аеруча авторның тел байлыгы, шигъри стиленең камиллеге белән сокландыра. Шагыйрьнең күп кенә юллары тирән мәгънәле афоризмнар кебек кабул ителә.

Сәгъди һәм Сараи «Гөлестан»нары өчен идея-эстетик байлык хас. Авторлар тормышчан вакыйга-хәлләр, ситуация-вазгыятьләр аркылы яшәешнең катлаулылыгын, кызыклылыгын, адәм балаларының, алар арасындагы мөнәсәбәтләрнең гаять төрлелеген күрсәтәләр. Әхлаклылык, инсанлылык, белем-мәгърифәтле һәм һөнәрле булу, игелекле эш-гамәлләр кылу хуплана. Яшәешнең асыл максаты – үзгәләрне рәнҗетмичә, бер-берең әярдәм итеп, «игү ат» калдырырлык итеп тереклек итү.

«...Игү аты калса ирнең йахшырак,
Соңра калгыйнча тулы алтун рәвак (сарай. – **Х.М.**)

Йадкяре калса кемнең игү ат, –
Үлмәс ул ир,– кемдә булса бу сыйфат (43)».

Шунысы мөһим: «Гөлестан бит-төрки»нең керешендәге бу мотив алга таба Мөхәммәдьяр, Тукай, Җәлил һәм күп кенә башка шагыйрьләребез иҗатында да яңгырап килә.

Яшәеш тәҗрибәсен туплаган Сәгъди, Сараи «Гөлестан»нары тормыш дәреслекләре, тереклек кодексы рәвешендә дә кабул ителәләр.

Романтик рухлы, әмма тарихи чынбарлык белән дә бәйләнешле «Сөһәйл вә Гөлдерсен» дастанында (1394) Сәйф Сараи Аксак Тимернең агрессив сәясәтен, канкоюлы сугышларны гаепли, фаҗигале, олы мәхәббәткә дан җырлый. Әсәр тукымасында образлы сурәт рәвешендә Җирнең Кояш тирәсендә әйләнү фикере дә әйтеп кителә. Бер гасырдан соң бу идея Коперник һәм Бруно тарафыннан фәнни яктан да ныгытылды.

С.Сараи – шактый гына лирик әсәрләр авторы да. Аларның бер өлеше үз чордашларына, милләттәшләренә (Әхмәд Хуҗа-Сараи, Габделмәҗид һ.б.) нәзыйрә, ягъни җавап рәвешендә язылган. Аларда тереклекнең төрле мәсьәләләре, аеруча мәхәббәт гәүдәләнеш тапкан. Бу төр парчалар өчен хис-кичерешләрнең муллыгы, сурәт-детальләрнең байлыгы, оригинальлеге хас.



Сәйф Сараи «Гөлестан бит-төрки». Кулъязма Голландиянең Лейден университеты китапханәсендә саклана.

С.Сараи газәл, касыйдә, робагый, фәрд (икеюллык), дастан-поэма, хикәят, хикмәт, нәсыйхәт, мәсәл һәм кайбер башка жанрларда иҗат итә, аларны үстерүгә, камилләштерүгә үзеннән зур өлеш кертә, әдәбиятыбызны эчтәлек һәм сәнгати яктан шактый баета.

Аның иҗаты үзеннән соңгы сүз сәнгатенә сизелерлек йогынты ясады, традицияләре Мөхәммәдьяр һәм Мәүла Колыйлар, Габдерәхим Утыз-Имәни һәм Акмуллалар, Дәрдемәнд һәм Тукайлар тарафыннан дәвам иттерелде.

Журнал укучыларына без С.Сараиның 1999 елда дөнья күргән җыентыгыннан аерым үрнәкләр, өзекләр тәкъдим итәбез.

I. «Гөлестан бит-төрки» (Шигъри өзекләр)

...Гөл теләсә хатыйрең тулы табак,
Бу «Гөлестан»ымдан укы бер вәрәкъ (бит, кәгазь. – **Х.М.**).

Гөл җәмалы (матурлыгы. – **Х.М.**) берничә көндә кичәр,
Бу «Гөлестан» даимә(н) күңел ачар.

... Бу «Гөлестан» багбаны (бакчачысы, ягъни авторы. – **Х.М.**) ул әдиб,
Кем Сараи Сәйф ирер, назмы гариб (44, 46 б.).

***

Фетнә йөзле раст (дөрес. – **Х.М.**) сүздән бул ерак,
Мәслихәтле йалган андан йахшырак (49 б.).

***

Сыйгар бер хөҗрәга уникке миһман, –
Бер икълимә (илгә. – **Х.М.**) сыйгышмас икке солтан (52 б.).

***

Ул буе сәрв (кипарис. – **Х.М.**) вә җәмалы тулун ай,
Гыйлем вә ирдәм берлә камил, күреккә бай.

Кашлары фетнә иде, күзләре бәла,
Кем йөзен күрсә, булыр ул мөбтәля (кайгылы. – **Х.М.**) (55 б.).

***

...Кем золм илен озатса, солтан булырмы, – булмас,
Куйларга корт (бүре. – **Х.М.**) һәргиз (һич тә. – **Х.М.**) чубан булырмы, – булмас! (57 б.).

***

Дәгелдер дустың нигъмәтдә һәркем,
Мәхәббәт лафыны орса йаныңда.

Хакыйкать дустың – йарыңдыр ул кем,
Кулың тотса айакдан төшкәнеңдә (68 б.).

***

...Әй гаклы тиңиз, сүзе гөһәрбар (янтарь. – **Х.М.**),
Утырсаң, күзем өстендә йирең бар (71 б.).

***

...Йимеше күп агачка таш атарлар (71 б.).

***

Орышыб таш аткан ир белән сән
Җәрәхәт башыңа эстәб китердең.

Чәкиб йа (корып җәя. – **Х.М.**), аттың ук дошман йөзенә,
Күзең ач: укына каршы утырдың (76 б.).

***

Каринча хатыйрен азар кылма
(Кырмысканы да рәнҗетмә. – **Х.М.**),
Сөләйманча илендә булса кувәт (71 б.).

***

…Җәһан күргән кеше күп йалган әйтер (84 б.).

***

…Йитсә татлы суга сусамыш ир,
Куркмас алында (алдында. – **Х.М.**) булса аждәрһа (89 б.).

***

…Алдыңда йуаш куй бикин (кебек. – **Х.М.**) мөшфик (йомшак күңелле. – **Х.М.**) йар,
Артыңда бүре кеби тиреңне ертар (92 б.).

***

…Ни хаҗәт башыңа таҗе мәшаих (шәехләр таҗы. – **Х.М.**), –
Татар бөркен киеб, дәрвиш булгыл (100 б.).

***

Әгәр уйнаб бер кеше бер хәрф (сүз. – **Х.М.**) әйтсә,
Алыр андан белек әһле нәсыйхәт.

Килер ахмак колагына уенчак,
Укыр булсаң йөз илле баб хикмәт (104 б.).

***

…Мән ул кошмән – ничәләрдән котылган,
Сәнең гыйшкың тозагына тотылган (114 б.).

***

…Җәфаларга тәхәммел кыл (түз. – **Х.М.**), теләсәң
Йөзең Тәңре катында ак булгай.

Бу көн тубрак бул андан борынрак
Кем, иртә гөл тәнең тубрак булгай (121 б.).

***

…Уздаң кеше йабынса (кисә. – **Х.М.**), иске габа (кием. – **Х.М.**) йарашыр,
Күрексез киленгә күрекле тун кидереб йарашмас (124 б.).

***

…Күрексез әбҗинең (хатынның – **Х.М.**) ире күзсез кирәк,
Гәр күрәр булса йөзен, бирер талак (124 б.).

***

…Аның кем азукы юктыр, күгәрмеш
Коры итмәк табып сөккәр бикин йийр [шикәр (йөзем. – **Х.М.**)
кебек ашар] (137 б.).

***

…Җәһан сәүгән кешенең күзләрене
Канәгать тулдырыр йә, үлсә – тубрак (140 б.).

***

…Агач күрке – йимеш, ирнең – кәрәмдер (142 б.).

***

…Һөнәр заигъ (файдасыз. – **Х.М.**) булыр күргүзмәсә ир,
Һөнәр күргүзгән ир шәһд-ү шәкәр йийр (145 б.).

***

...Әҗәлсез адәми үлмәс диеб сән,
Еланны койрыкындан тотма, зинһар (148 б.).

***

Китер акча, кәмигә бер, йук исә – тышкары ултыр,
Ун ирнең куввәтен куйгыл, бер ирнең акчасын килтер (149 б.).

***

Гөлдер бу Сараи Сәйф, ликин (ләкин. – **Х.М.**)
Дошман күзенә тикән (чәнечкеле – **Х.М.**) күренер (155 б.).

***

Икке җаһил качан орыш башлар,
Йөз бозарлар орыб, йарыб башлар (157 б.).

***

Һәр кемне күңел теләсә, – күрекле улдыр (162 б.).

***

Нине күңлең теләсә – бар аны кыл,
Вафасыз дилрәба сән, и биле кыл (169 б.).

***

Күңелне баглама бер йиргә, зинһар,
Йәнә мөшкелдер андан алмак, и йар (178 б.).

***

Йомрык синең илеңдән татлы килер агызга,
Үзгә кеше илендән шәһд-ү шәкәр йийгинча (182 б.).

***

...Күзәтер үзгә гайбен – сән аны күр,
Мәгәр үз гайбенә даим күзе күр (сукыр. – **Х.М.**) (186 б.).

***

Кечелекдә әдәб үгрәнмәгән ир,
Олы булса, бел, андан хәйр килмәс.

Игелер йәш агач ничек теләсәң,
Коры игре (кәкре. – **Х.М.**) агач утсыз төзәлмәс ((197 б.).

***

Күңел бирмә ул узданга (гүзәлгә. – **Х.М.**) ки, мәкер вә хәйләсе чукдыр,
Хәрами (каракныкы кебек. – **Х.М.**) күзләр, кашы – йә (җәя. – **Х.М.**),
керпеке – укдыр (222 б.).

***

Адәми күңлен екар сүз сүзләмә,
Солх иясендән хосумәт (начарлык. – **Х.М.**) күзләмә (224 б.).

***

Әйа килгән җәһанга игелек ит,
Йаман эшне йаманларга куеп кит (227 б.).

***

Монда даим игелек иткән кеше
Җәннәт эчендә тамашадыр эше (246 б.).

Ахыры киләсе санда ■

Безнең мирас №5 май 2021

Дөррәт әл-фахирә яки Ахирәтнамә

Габдерәхим Утыз-Имәни

Габдерәхим Утыз-Иманинең иҗат мирасына барлыгы ун поэма керә.

Шәкертлек чорында язылган беренче поэмасы – «Дөррәт әл-фахирә яки Ахирәтнамә» («Мактаулы энҗе, яки Ахирәт хатлары») – дини эчтәлектә. Анда кеше үлгәч булачак вакыйгалар, үлгән кешеләр тереләсе көн (Кыямәт), ахирәт һәм шуңа бәйле хәлләр турында ислам дине өйрәткәнчә бәян ителә. Утыз-Имәни аны күренекле галим Мөхәммәд әл-Газалиның (1059-1111) «Дөррәт әл-фахирә фи кәшфе гомум әл-ахирә» («Ахирәт хәлләрен ачу юлында мактаулы энҗе») исемле проза әсәреннән файдаланып язган.

Утыз-Имәнинең бу поэмасы моңа кадәр беркайда да басылмаган иде әле. Ул хәтта авторның без әзерләп чыгарган 1986 елгы китабында да юк. Гарәп һәм фарсы сүзләре белән бик чуарланып беткән әлеге зур күләмле әсәр барлыгы 1456 шигырь юлыннан тора.

Поэманың тулы тексты дүрт кульязмада калган. Аның икесе Казан (Идел буе) федераль университетында, Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәнең Көнчыгыш кульязмалар бүлегендә саклана. Беренчесе 1808 елда Утыз Имән авылында мулла Габдулла бине Госман мәдрәсәсендә Йосыф бине Сәед Борһан тарафыннан күчерелгән. Ахырга «Мин нөсхәи мөәллиф» (ягъни «Автор нөсхәсеннән алынды») дип язып куелган. Бу кульязма безнең өчен нигез текст булып торды. Нәүбәттәге текст XIX гасырның икенче яртысында күчерелгән. Күчерүчесе билгесез. Әсәр ике баганалы кызыл сызыклы кыса эченә алынган, бүлек башлары кызыл кара белән язылган. Бу кульязма 1936 елда табылган.

Әсәрнең тагын ике кульязмасы Татарстан Дәүләт музее архивында саклана. Аның беренчесе 1813 елның 20 гыйнварында язып тәмамланган. Тулы текст. Ахырга: «Мән нәвәштем, сарыф кәрдәм рузкяр, мәнем каләмдин булыр ядкяр» (ягъни «Мин яздым, сарыф иттем вакытымны, минем каләмнән истәлек булыр»), – дип язып куелган. Икенчесе тулы текст түгел: әсәр башында 115 бәет төшеп калган, барлыгы 230 шигырь юлы теркәлгән.

Шушы дүрт кульязманы үзара чагыштырып, әсәрнең фәнни-чагыштырма текстын әзерләдек. «Безнең мирас» укучыларына шуннан берничә өзек тәкъдим итәбез. Текстлар башта автор үзе язган сүзләр белән китерелә, аннары юлга-юл тәрҗемә бирелә. Тәрҗемәдә текстларның шигъри формасы түгел, беренче чиратта, аларның мәгънәсен дөрес бирү максат итеп куелды.

***Әнвәр Шәрипов,** филология фәннәре докторы*

Кереш

Һәр кешегә үлем киләчәге, һәркемнең кабергә керәчәге турында.

Тотар аны йакадин нәгаһани,
Йыкар йиргә идеп мәкъһүр вафани...
Түшәкендә йатан ул һәм фирашың
Калыр тәнһа, ки гүргә керсә башың...
Мосаффа ул көмешдик ак бәдәнләр,
Төшәр тупрак эчигә сим тәнләр.
Мөҗәүһәр зөлефле пакь-ак йөзләр,
Шәкәрдин һәм зиядә татлы сүзләр –
Улыр гүрдә мөләүвәс хакъ-у-хашак,
Череп китсә, улыр мисле сийаһе хакъ.

***

Бере кыйлмаз вафаны, килсә үлем,
Ушандакдыр бу галәм хале мәгълүм.

Тәрҗемәсе:
Көтмәгәндә (үлем) тотар аны якадан,
Җиргә егар, кыерсытып, тугрылык иясен...
Түшәгеңдә яткан улың һәм хатының
Ялгыз калыр, әгәр гүргә керсә башың...
Көмеш кебек саф, ак гәүдәләр,
Туфрак эченә төшәр көмеш тәннәр.
Җәүһәрдәй чәчле ак-пакь йөзләр,
Шикәрдән татлырак матур сүзләр, –
Кабердә пычраныр туфрак, шакшылык белән,
Череп китсә, кара туфрак төсле булыр...

***

Беркем ярдәм итә алмас, үлем килсә,
Бу галәм халкының хәле шундый булыр.

Беренче баб

Үлгән кешегә зикер әйтүнең файдасы турында.

Икенче баб

Һичкайчан үлмәм, дип, дөнья куып йөрү һәм аның зарары турында.

Әмәлнең тоулегә ике сәбәп вар:
Берeдер – хөббе дөнья, әй борадәр.
Дәхи берсе җәһелдер, улгыл агяһ,
Гыйлаҗен эстәгел шам-у-сәхәргяһ.

Тәрҗемәсе:
Дөнья кууның ике сәбәбе бар:
Берсе – дөньяны сөюдер, и туганым.

Тагын берсе – наданлыктыр, сак бул син,
Аның даруын эзлә кичтән алып таңга кадәр.

Өченче баб[1]

Үлем исереклеге һәм аның көче-дәһшәте турында.

Үлемнең шиддәтен тел әйтә белмәс,
Юлыкган адәмиләр телгә килмәс...
Кылыч зарбы ки өч йөз төшсә башә,
Үлемнең шиддәтен бел андин аша.

Тәрҗемәсе:
Үлемнең ачысын тел әйтә белмәс,
Юлыккан кешеләр телгә килмәс...
Әгәр башыңа бер үк вакытта өч йөз кылыч килеп төшсә,
Бел, үлем ачысы аңардан да катырак булыр.

Дүртенче баб[2]

Кабергә күмелү, Мөнкир һәм Нәкирнең сорау алуы, Кыямәт көнендә Исрафил фәрештәнең сурга (быргыга) өрүе, Кыямәт көнендәге башка вакыйгалар, гөнаһларны, савапларны үлчәү, сират күпере, Аллаһның шәфкате, җәннәт чишмәләре, җәһәннәм һ.б. турында.

Кабергә күмелмәкнең бәяны

Күмелгәндә кабергә ибне адәм,
Тәкәллем әйләйүр кабре ушал дәм,
Дийүр аңа: «Керерсән бәйтү золмәт,
Ирүрмән бәйте фетнә, бәйте хиддәт.
Ирүрмән бәйте дидан, бәйте ихзан.
Нәчүк гафил улуб сән, әй би-дәрман!
Әгәр хәйрияте улса эшеңнең,
Вирүр һатиф җавабын ул кешенең».
Дийүр: «Сорагыл бу кәснең кыйлмышыни,
Кыйлан мәгъруф – нәһи мөнкәр эшени».
Дийәр: «Кабре ушандак улса мохсин,
Улурмән аңа җәннәте хуб рәнгин.
Мәнем рәхмәти мотигъларга би-нигъмәт,
Мәнем нигъмәти яманларга би-рөхсәт.
Мотигълар керсәләр моңа, чыкар шад,
Яманларга ирешмәз дад вә фөрйад.
Үлекләр чаграшурлар һәр тарафдан,

[1] Бу баб – поэманың иң зур бүлекләреннән берсе. Аның эчендә кешеләрнең ничек, ни рәвешле үлүләре турында дүрт хикәят китерелә. – **Ә.Ш.**

[2] Поэманың иң зур бүлеге. Ул үзе аерым мөстәкыйль поэма булып каралырга мөмкин. Баб эчендә 5 бүлекчә, 13 бәян бар. Баштагы бүлекчәләрдә Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәрнең, аннан соң Әбүбәкер, Гомәр, Госман һәм Галинең үлемнәре сурәтләнә. Шуннан соң төрле темаларга багышланган 13 бәян китерелә. – **Ә.Ш.**

Әйа мәгърур улупсән бәд холыкдан.
Бези күрдүң, нәчүк тотдуң әмәлне,
Горурлыкдан кылалмадың гамәлне».
Йиреӊ әтрафлари һәм нәгърә әйләр,
«Әйа, могътәр!» – дийүбән тагънә сөйләр.
Кәлүр төрлүк җаванидин садәләр,
Тәмамы халь телилә ләгънәт әйләр.
Әгәр салих кешидин улса ул кәс,
Аныңдик нәгърә-фөрйадни ишетмәс.
Мәлаиклар кәлүб каршы дөшәрләр,
Биһиштдин кәндил вә суаб дәшәрләр.
Дәхи кабери киң улур һәм мөнәүвәр,
Улур җаи фәрехняк хуш мөгәммәр.

Тәрҗемәсе:

Кабергә күмелү бәяны

Күмелгәндә кабергә адәм баласы,
Шул чак аңа кабере шуны сөйләр,
Әйтер аңа: «Син керәсең караңгы йортка,
Мин булырмын фетнә һәм кырыслык йорты.
Булырмын мин караңгылык һәм саклык йорты.
Ничек сизми калдың син, әй чарасыз!
Әгәр изгелеге булса эшеңнең,
Вөҗдан тавышың бирер җавабын».
Әйтер: «Сора бу кешенең гамәлләреннән,
Яхшылыкка өндәгән, начарлыктан тыйган эшләреннән».
Әйтер: «Яхшылык эшләүченең кабере шушы булса,
Булырмын мин аңа күркәм төстәге җәннәт.
Күндәмнәргә минем рәхмәтем байлык булмас,
Яманларга минем байлыгым рөхсәтсез барыр.
Күндәмнәр моңа керсә, шат чыгарлар,
Яманларга ирешмәс чакыру да, кычкыру да.
Үлекләр кычкырышырлар һәр яктан, –
Әгәр горурлансаң син начар холкың белән.
Безне күрдеңме, ничек тоттың ышанычны (иманны),
Горурлыктан кыла алмадың яхшы гамәлне.
Җирнең һәр тарафы сиңа куркыныч тавыш белән акырыр,
«Әй дин тотучы!» – диеп хурлап сөйләр.
Килер төрле егетләрдән тавышлар, –
Барысы каты тел белән ләгънәт әйтер».
Әгәр изге кешедән булса ул адәм,
Аның кебек акырыш-кычкырышны ишетмәс.
Фәрештәләр килеп, каршы төшәрләр,
Җәннәттән шәмдәл, кием китерерләр.
Шулай ук кабере киң һәм нурлы булыр,
Урыны хуш, шатлыклы, озын гомерле булыр.

Бәяне газаб әл-кабер вә сөаль Мөнкир вә Нәкир

Сөале гүр ирүр Хак, әй мөселман!
Ирүр важиб аңа кәлтүрмәк иман.
Вафат итдүкидә бер әһле иман,
Ачарлар рухина әбуваб әсман.
Ки мәндин кәлсә дийүбән игътибари,
Идәрләр рухына чук интизари.
Мәлаиклар тәмамы йир вә күкдин,
Йыйылурлар намазига офыкдин.
Куелса кабергә ул мәрде пакъ дин,
Зоһур әйләр мәлаиклар еракдин.
Мөнәүвәр йөзләри чун шәмси табан,
Могаттар хуш мөнәгъгәм фәрше әлван.
Сөальләр әйләйүрләр ул кешидин,
Зарурийәт тәмами дин эшидин.
Сорарлар һәм Хода берлә Рәсүлдин,
Дәхи дин вә мәзаһәб, изгү йулдин.
Әгәр тапсаң җавабында савабы,
Биһиштдин фәтех идәрләр анда бабы.
Кәлүр бер хөсне һәйәт хуш либаслу,
Кәламе хуш, ләтыйф ислү, әдәплү.
Бәшарәтләр вирүр дарел – сәламдин,
Биһишт җавидан гыйззәте тәмамдин.
Дийүр: «Кем сән, ирүрсән дәхи бәшарәт?»
Дийүр: «Мән шул – кыйлан хәйрат вә тагать.
Кәлүбмән имди сәңа һәмнәшин мән,
Али йәүмел-кыямәте хуб нәшин мән».
Идәр сохбәт тәмам әгъмали берлән,
Нәчүк кем ултурурди әһли берлән?
Әгәр кяфер улурса, кабихе бәддин,
Фәрештәләр кәлүр аңа газабдин.
Идәр ләгънәт аңа барча мәлаик,
Дәхи баглар сәмәватлардин ишек.
Ишекләр рухыни мәкруһ күрерләр,
Кәлүрсә җөмләсе, кирү сорурлар.
Мәлаиклар сөалинә җаваби,
Вирә белмәз җавабында сөали.
Кәлүр бер кабхе йөзлү, бәд либаслу,
Кәламе шух яман, аис бәд сияклу.
Сорар, әйдүр: «Нәчүк тән сән, нәчүк зат?
Күренмәс һич сәнең дәк кабих бер зат.
Берәр сәндик кабихны күрмешем йук,
Сәнеңдик бәд сийакны белмешем йук».
Җавап әйтүр: «Сәгаять итмешең мән,
Зәлаләтдин яман йул китмешең мән.
Кәлүб сәңа, идәрмен һәмнәшин лик,
Али яумил Кыямәт бәднәшин лик».
Идәр дузәх сараидин фәтех бабы,
Али йәүмел – җәзаи әбис әл-маэбы.
Йите башлу әфагыйлар тәфаккым,
Улуб тәгъзиб, идәрләр би-тәрәххым.
Улуб кабре би-гаять тәнг вә тарик,
Идәр загыт, улур чун хәбле барик.
Улур мөэминләр һәм зәгыйфь вә гүр,
Улур кяферләрә дип, улма мәгъруp.
Рәсулулла кызы Зәйнәбкә нә улды,
Безнеңдик кем бохитларга нә калды?

Тәрҗемәсе:

Кабердәге газап һәм Мөнкир белән Нәкирнең сорау алуы бәяны

Кабердә сорау алыр Аллаһ, и мөселман!
Аңа иман китерү үтәлергә тиешле гамәл булыр.
Вафат булса бер иманлы кеше,
Ачарлар аның рухына күкләрнең ишекләрен.
«Әгәр килсә миннән хөрмәтләү», – дип әйтү белән,
Аның рухына күп зарыгулар булыр.
Җир һәм күкнең барлык фәрештәләре
Җыелырлар намазга бар тарафтан.
Куелса кабергә бер саф динле кеше,
Фәрештәләр ераклардан ук килерләр.

Нурлы йөзләре якты, нәкъ кояш кебек,
Аяк асларына бай, төрле төстә келәм җәелгән.
Сораулар алырлар ул кешедән,
Барлык иң тиешле дин эшләреннән.
Сорарлар Аллаһ һәм пәйгамбәр (с.г.в.) турында,
Тагын дини юнәлеш (мәзһәп), изге юл турында.
Әгәр тапсаң җавабын, сиңа савап булыр,
Җәннәт ишекләрен анда ачарлар.
Килер яныңа бер күркәм сурәт, матур киемле,
Матур сүзле, йомшак исле, әдәпле.
Иминлек йортыннан шатлыклы хәбәр бирер,
Мәңгелек җәннәтнең бөтен хөрмәтен белдерер.
Әйтер: «Кем син, шатлыклы хәбәр алучы?»
Әйтер: «Мин шул – изге эшләр, Аллаһка гыйбадәт кылучы,
Мин килдем сиңа, әңгәмәдәш мин,
Ә Кыямәт көнендә яхшы утырдаш мин».
Сөйләшеп утырыр барлык эшләр турында,
Кем алай сөйләшер иде гади кеше белән?
Әгәр кяфер булса, әшәке дин кешесе, –
Фәрештәләр килер аңа газап белән.
Барлык фәрештә аңа ләгънәт укыр
Һәм дә күкләрнең ишеген бикләрләр.
Ишекләр рухын җирәнгеч күрерләр.
Килсәләр, һәммәсе, сорау алырлар.
Фәрештәләр соравына җавапны
Бирә белмәс, җавабын да сорауның.
Килер кабахәт йөзле, шыксыз киемле берәү,
Сөйләме ярлы, яман; өметсез, бозык гадәтле.
Сорар, әйтер: «Нинди гәүдә син, нинди зат?
Һич күренмәс синең кебек кабахәт бер зат.
Синең кебек бер кабахәтне күргәнем юк,
Синең кебек бозык гадәтлене белгәнем юк».
Җавабында әйтер: «Яла яккан идем мин.
Азгынлыктан яман юлга киттем мин.
Сиңа килеп, мин әңгәмәдәш булырмын,
Кыямәт көнендә начар утырдаш булсам да».
Җәһәннәм сараеннан ишек ачылыр,
Җәзалау көнендә, өметсезлектән сыеначак җир ул.
Җиде башлы еланнар өскә менәрләр,
Газапларлар, һичнинди мәрхәмәт күрсәтмичә.
Булыр кабере гадәттән тыш кысан һәм караңгы.
Кысылыр як-яктан, калыр нечкә җеп кебек.
Мөселманнарга да кысынкы кабер булыр;
Кяферләргә дә шулай, дип горурланма,
Рәсүлулла кызы Зәйнәбкә дә шул булды,
Безнең кебек гөнаһлыларга нәрсә калды?

Дәвамы бар ■

Безнең мирас №5 май 2021

Мөслим бабай варислары

Роза Хәбибуллина

Араларда ничә мең ел –
Бабаларым ерак-ерак,
Аргы башта – алар җаны,
Ә биредә – минем йөрәк.
Харрас Әюп

2020 елның 30 мартында Баулы тернәкләндерү үзәгеннән дәваланып кайттык. Яз башланды, кояшлы җылы көннәргә күңел шатлана, ямьле җәйләрне көтәбез. Профилакторийда шау-гөр килеп, концерт-танцыларга йөреп, Кытайдан килгән афәтне уйламадык та. 1 апрельдә тормыш ябылды – изоляция... Интернеттан Россия медицинасында югары урында утырган хатын ярып салды: «Пенсионерлар үлеп бетәчәк!» Үз күзләрем белән күреп, үз колакларым белән ишеттем! Шаклар каттым бу хатынның шундый җавапсызлыгына! Көлдем дә әле... Ләкин эшләр көләрлек түгел иде. Бөтен дөнья күләмендә кешелеккә янаган афәт килде...

Яшем олы инде, Аллаһка шөкер, китәргә күп тә калмагандыр, ләкин менә хәзер үләсем килми! Җеназага озатырга кеше дә килмәячәк! Юк-юк, берүк Аллаһ сакласын!

Бер-бер артлы эшлисе эшләрем барлыгы исемә төште. Нәсел шәҗәрәсенең эшен бетереп, балаларга, туганнарга таратасым бар. Миннән башка моны эшләр кеше юк!

Эзләнүләр

Әхмәдулла Әхмәтгалиевның районыбызның тарихы, авыллары, кешеләре, мәгарифе, мәгърифәте һәм табигате турында күп мәгълүматны эченә алган «Мөслим төбәге» дигән зур хезмәте – күләмле китабы чыгу минем өчен гаять әһәмиятле булды. Автор авылыбызга нигез салучы Мөслим дигән кеше һәм аның улы Мөэмин турында бәян иткән. Әткәй Шакир Галимов сөйләве буенча, нәселебез Мөслим бабайдан башлануын белә идек. Бу турыда 2004 елда район газетасы «Авыл утлары»нда «Мөслим бабай варислары» дигән очеркым басылып чыкты. Ул вакытта язганнарым ышанычлы, дөрес булса да, кулыбызда моны раслаучы документ – шәҗәрә юк иде.

Шәҗәрә ике экземплярда булган: берсе – әткәйнең әтисе Галимнәрдә, икенчесе – аның абыйсы Хафизларда. Галимнәрдәгесе, ут чыгып, янгында юкка чыккан. Икенчесен 1944 елда Хафиз картның 100 яшьлек карчыгы Сәрбихирам әби Мөслимдә тарих укыткан Идрис Туктар исемле укытучыга биргән. Идрис Туктар – язучы, шәҗәрәне Казанга алып киткән. Ихтимал, Мөслим авылы тарихын язарга уйлагандыр. Шулай итеп, Мөслим бабай шәҗәрәсе юкка чыккан. «Шәҗәрә зур гына кәгазьдә, таушалмасын өчен артына ситсы тукыма ябыштырылган иде», – дип искә ала иде әткәй. Озак еллар буе шәҗәрәне табасым килеп йөрдем. 2018 елны Уфа Республика архивы белән бәйләнешкә кердем. Һәм, ниһаять, 2019 елда документ килеп төште!..

Гасырлар чоңгылында

Документларны кулга алгач, гаҗәп халәт кичердем: атна буе башны калкытмыйча, гасырлар чоңгылына кереп чумдым…

Дүрт гасырны биләгән шәҗәрәдәге элгәргеләребез миңа бик якын-кадерле тоелды; аларның туган һәм яшәгән елларын, тирән мәгънәле, матур яңгырашлы сөйкемле исемнәрен укып, сокландым да, моңландым да, күңелем йомшап, елап та алдым… Күкрәгемдә каннан-канга күчкән рух җылысын тойдым… Искиткеч чибәр, нәфис кызлар: Бадьян, Балхис, Сәхибямал, Нәфисямал, Гөлбагидә, Газизә; ир-егетләр: Габделвахит, Габделкәрим, Хафиз, Җиһанша, Исмәгыйль – татарның затлы милли исемле ул-кызларын, аларның яшәешләрен күз алдыма китердем. Атна буе әллә нинди дулкында, җир белән күк арасында, хәзерге һәм элгәрге тормышта яшәдем.

Ләкин шәҗәрәдә Мөслим бабай юк, ул Мөслим улы Абдий Мөслимовтан башлана иде. Аптырадым, дулкынланып, борчылып, Уфага шалтыраттым:

– Нишләп шәҗәрәдә Мөслим бабай юк?!

Борчылуым тавышыма чыккандыр, ахры, теге баштан башкортча мөлаем гына аңлаталар:

– Беддәге архивта Мөслим җук, кәрәк булһа, Мәскәүгә ядыгыд, адресын бирермен.

Өметем яртылаш кына тормышка ашса да, тынычлана төштем: 1795 елгы «Ревизская сказка» дигән язмаларның беренче битендәге исемлектә Муэмин Муслимов һәм Абдий Муслимовлар тора (исемлектәгечә яздым). Мәскәү архивына кичектермичә сорап язарга җыендым.

Уфадан килгән шәҗәрә Мөслим улы Абдий бабай белән Фатима әбидән башлана. Безнең нәсел шулардан тармакланган, шулар канаты: Абдий – Габделваһап – Габделгази – Ибраһим – Мөхәммәтгалим – Әхмәтшакир – Мөслим, ул алтынчы бабам булыр иде… Мөслим бабай булмагач, эч поша. Шикләнә дә башладым: бар микән соң Мөслим шәҗәрәсе Мәскәүдә?..

Ләбүдә

Шулай икеләнеп йөргәндә, миңа берәү шалтырата:

– Исәнмесез! Сез Роза Хәбибулллина буласызмы?

– Әйе.

– Мин Кукмарадан шалтыратам, Сез мине белмисез. Сезнең авылга нигез салган Мөслим бабайның шәҗәрәсен төзим. Мин дә шул Мөслим нәселеннән. Исемем – Ләбүдә. Сезне эзләп табуыма мин бик шат!

– И җанкисәгем, Сезнең белән танышуыма мин дә бик бәхетле!

И Кадыйр, и Раббым! Мин шәҗәрә дип җан атып йөргәндә, тагын беребез тамырларын барлый икән. Без, телефонга ябышып, бик озак аерыла алмый сөйләштек, югалган туганыбызны яңа гына тапкандай куаныштык! Мин Ләбүдәгә Уфадан шәҗәрә килүен әйттем.

– Миңа да шушы көннәрдә генә Мәскәүдән Мөслим бабай шәҗәрәсе килде! Сөенечтән еладым, бер атна йоклый алмадым! – диде кардәшем.

– Шәҗәрәдә Мөслим бабай бармы?!

– Бар, бар!

– Син мине ничек эзләп таптың?

Ул мине ничек табуын сөйләп бирде.



2019 елда Мәскәүдә «Чыңгыз Айтматов укулары» дигән симпозиум үткән («Ислам дөньясы» дигән форумда). Татарстан делегациясендә Казаннан галимә, әдәбият тәнкыйтьчесе профессор Дания Заһидуллина, Кукмарадан музей директоры Ләбүдә Насыйрова һәм башкалар булган. Ләбүдә кунакханәгә Дания Фатиховна белән урнашкан. Танышып аралашкач, Дания Фатиховнаның Мөслим кызы икәнен белгән Ләбүдә ханым, дулкынланып:

– Минем фамилиям Мөслими булырга тиеш! – дип куя.

– Ничек Мөслими? – дип кызыксына Дания Фатиховна.

– Безнең нәсел сезнең район үзәгенә нигез салган Мөслим бабайдан башлана. Хәзерге вакытта Мөслимдә яшәүче Мөслим нәселеннән булган кешене белмисезме?

– Мин әйтә алмыйм, тик Сезгә моны белергә тиеш кешенең телефон номерын бирә алам.

Шулай итеп, хөрмәтле якташым, авылдашым – икебез дә Мөслим районы Әмәкәй авылында туып, шифалы суларын эчкән Дания Фатиховна Заһидуллина һәм коллегам, каләмдәшем, балалар шагыйре Мөҗәһит Әхмәтҗанов ярдәмендә Ләбүдә мине эзләп тапты.

Мин дә нәселебезнең бер асыл кызы белән таныштым! Ләбүдәләр Ижау ягы тармагыннан. Ул инде дүрт йөзгә якын нәсел дәвамчыларын җыеп теркәгән.

Кардәшемнең шундый мәртәбәле халыкара әдәби симпозиумда, профессорлар, министрлар белән чакырылуы нинди хезмәте өчен икән дип кызыксындым.

– Чыңгыз Айтматов чыгышы белән ярымтатар. Бөек язучының әнисе Нәгыймә Хәмзә кызы Габделвәлиева-Айтматованың әтисе безнең Кукмара районының Мәчкәрә авылында туган. Без аларның гарәп графикасы белән язылган шәҗәрәсен таптык һәм Чыңгыз Айтматовның шәҗәрәсен төзедек. Чыңгыз Айтматов хакындагы материалларны 1987 елдан туплый башладым. Алар безнең музейда саклана. Мөслим бабай шәҗәрәсен эзләвем Чыңгыз Айтматов шәҗәрәсеннән башланды.

Чыңгыз Айтматовның шәҗәрәсен туган иле Кыргызстанга җибәрдем. Бу зур вакыйга булып яңгырады. Мине Чыңгыз Айтматовның тууына 90 ел тулуга багышлап

Мәскәүдә үткәрелгән юбилеена да чакырдылар, шундый зур тантанада катнаштым.

Ләбүдә ханым бөтен дөньяга билгеле язучының шәҗәрәсен төзеп, дөньяга чыгарып, искиткеч әһәмиятле, олы хезмәт башкарган. Яңа тапкан тугандашымны шул көннәрдә үткән юбилеема чакырдым. Ул улы һәм кызы белән, зур бүләкләр төяп килеп төште. Бүләкнең зурысы-кечесе юк, диләр, әмма иң кадерлесе Ләбүдә алып килгән Мөслим бабай шәҗәрәсе иде.

Зифа Басыйрова исемендәге район мәдәният сараенда сәхнәгә Ләбүдә озын плакат – Мөслим шәҗәрәсен тотып чыккач, кадерле кунагыбызны тамашачылар алкышларга күмде.

Шулай итеп, Мәскәүдән килгән документлар белән безнең Мөслим бабай шәҗәрәсе тулыланды.

Мөслим бабай

Мөслим бабай 1669 елда Иске Вәрәштә дөньяга килгән. Әтисе Муса исемле булган. Мөслимнең ике улы: өлкәне Мөэмин – 1669 елда, кечесе Абдий 1705 елда туган. Мөслим авылына чама белән 1700 нче елларда нигез салынган.

Мөслим бабай турында бездә бабайларыбыз сөйләп калдырган риваять саклана. Ул бер бик матур җәйге көндә Иске Вәрәштән Мөслим Ык аръягындагы болынга чыккан. Искитмәле куе печән өлгергән булган. Шул печәнлекне карап йөргәндә, ике урысны очраткан. Тегеләр үзара сөйләшәләр икән:

– Менә монда килеп урнашсаң, ничек шәп булачак: җире кара туфраклы, балык тотыйм дисәң, елгасы нинди мул сулы!

Урысларның сөйләшүеннән аларның авыл өчен урын сайлаганнарын аңлаган. Мөслим, моны ишеткәч кайтып киткән дә, тегеләр килеп утырганчы, Ыкның икенче ягына төн эчендә бер бура чыгарып куйган! Ныклы, егәрлекле кеше булган безнең бабай, матурлыкны да аңлаган. Оҗмахка тиң әлеге искиткеч матур җирне ятларга бирмәс өчен, төн йокламыйча бура күтәргән. Шулай итеп, ул Кояшлы Ык буенда авылга нигез салган.

Казан татарлары

Архивтан килгән документлар күрсәткәнчә, алар бик күптән, Явыз Иван чукындыруыннан, эзәрлекләүдән качып килгәннәр.

Менә ул документ (текстта язылганча бирелә): *«Ревизская сказка 1811-го года Сентября 12 дня Оренбургской губернии Мензелинского уезда 5-ой команды Тептерского старшины Абдулмязита Абдрешитова деревни Муслюмовой осостоящих мужеска пола тептерях и бобылях вообщине жительствующих съясашными татарами Казанъ Азиновской волости».*

Димәк, безнең бабайлар, Казан ханлыгы яулап алынгач, уналтынчы гасырның икенче яртысында (ихтимал, азагындадыр) Иске Вәрәш авылына килеп урнашканнар. Иске Вәрәш бик күптән, борынгы гасырларда ук нигезләнмәдеме икән, чөнки зиратларында 1400 елда куелган кабер ташы булган дип ишеттем.

Мөслим улы Абдий

Безнең нәсел Мөслимнең кече улы Абдий бабай белән Фатима әбидән тармакланган, без шул канаттан. Бабаларыбыз таза-нык, озын гомерле булган. Мөслим бабай 78 яшькә җиткән. Авылда халык арасында Мөслимнекеләр ышанычлы саналган. Олы улы Мөэминне, еллар үткәч, оныкчыгы Габделмәҗитне старшина итеп

куйганнар. Алар халык санын алган елларда җитәкче команда башында булганнар дип аңладым.

Гаиләләр зур, ишле булган. Мөслим бабайның уллары икәү; оныклары унсигез, шуларның унысы – малай! (Болар ике улыныкы гына, кызлары Мәскәүдән килгән документларда күрсәтелмәгән.) Тормышлары әйбәт булгандыр. Мөслимнең оныкчыгы – Абдий бабайның оныгы Габделгазиның ике хатыны, тугыз баласы булган. 1788 елда ике хатыны да бәби алып кайткан: Балхис исемле кыз, Әбүбәкер исемле малай. Мондый хәл бер буын аша тагын кабатланган: әткәйнең бабасы Ибраһимның да ике хатынга тугыз баласы үскән. Шул балалар арасында минем әткәйнең әтисе Галим бабам һәм аның абыйсы – авыл тарихына кереп калган Хафиз булган.

Үрәтник Хафиз

Хафиз белән минем Галим бабамнарның әтиләре бер, аналары башка. Хафиз – беренче хатын, ә Галим – яшь хатын улы. Хафиз 1834 елда туган, энесе белән аралары уналты яшь. Хафиз көчле ихтыярлы, төпле акыллы, заманы өчен белемле кеше, авылда халык арасында дәрәҗәсе зур булган. Үрәтник Хафиз дип йөрткәннәр авылда. 1878-1917 нче елларда Россиядә урядник – өяз полициясендә кече офицер чины (хәзергечә участковый). Хафиз Ибраһимов күп еллар авылда урядник вазыйфасын башкарган. Тыныч холыклы, сабыр кеше, юк-барга халыкка җәбер-золым салмаган, авылдашлары аның янына киңәшкә килә торган булганнар. Хафиз хатыны Сәрбихирамны бик ихтирам итеп яшәгән. Ире Минзәлә өязенә эш буенча юл тотканда, киенеп-ясанып, ак шәлен ябынып, яхшы тарантасларга утырып Сәрбихирам да бара торган булган. Аларның ике уллары, өч кызлары туган. Йортлары хәзерге Мәҗит Гафури урамының Ык буе очында торган. Әткәй һәм туганнары әтиләренең Хафиз абыйсын «дүрәтәй» дип атап йөргәннәр, гадәт буенча шулай тиеш булган.

Галим бабай

Еллар аермасы буенча иң якын бабам – әткәйнең әтисе Галим бабай. Мулла кушкан исеме – Мөхәммәтгалим. Миңа аны да, әбиемне дә күрергә насыйп булмады. Кияүгә чыкканчы мин Галимова булып, аның исемен яратып йөрттем. Язылышы да, әйтелеше дә, мәгънәсе дә искиткеч матур.

Галим бабай 1850 елда туган. Мөслим нәселенә хас сыйфатларның иң кыйммәтлеләре аның килеш-килбәтендә дә, акыл-фигылендә дә кабатланган. Ул өлкән буыннардан ныклы сәламәтлек, көч, гайрәт алган. Яшь чагында замандаш дуслары белән сүз ярыштырып, бия астына кереп, аны эһ тә итмичә күтәргән. Ул Баланлы авылыннан Галләм кызы Сәгыйдәгә өйләнгән. Әбием баһадир иренә ике кыз, биш малай бүләк иткән.

Галим карт заманасы өчен алдынгы фикерле кеше булган. Ул балаларына белем бирергә тырышкан. 1901 елда Мөслимдә мәдрәсә ачылгач, Шакирны (минем әткәй) укырга биргән.

Ләкин биредә дин сабакларыннан башка нәрсә укытылмагач, бабай улын Олы Чакмак мәдрәсәсенә җибәргән. Соңрак улы Сабир да шушы мәдрәсәдә укыган. Олы Чакмак мәдрәсәсендә дөньяви гыйлем: математика, тарих, география, хәтта астрономияне дә белемле хәлфә Мөхәммәтшакир Фәйзуллин укыткан. Ун ел бу мәдрәсәдә укып, урта белем алып чыкканнар. Мөхәммәтшакир хәлфәнең хәзер дә Мөслимдә нәсел дәвамчылары бар. Район хастаханәсендә эшләп, пенсиягә чыккан Римма бабасының бабасы Оренбург ягыннан, атаклы Җәүдәт Фәйзиләр нәселеннән

булган дип сөйләде. Аның әйтүе буенча, бабасы Сорбонна университетында укыганмы, укырга теләгәнме – анысы төгәл билгеле түгел.

Катлаулы кискен еллар

Егерменче гасыр башы гаять катлаулы кискен вакыйгалар белән башлана. Бар авырлыклар халык өстенә төшә: япон сугышыннан Россия хурлыклы җиңелү белән чыга – Сахалин утравының яртысына, Курил утрауларына, Портартурга Япония хуҗа була. 1914 елда Беренче бөтендөнья сугышы башлана, аннан революция, Гражданнар сугышы китә!..

Галим бабайның бар уллары сугыш ялкынына кереп китә. Шул канлы сугышларда каты яралансалар да, гомерләре киселмәгән, бишесе дә исән-имин туган якларына – Мөслимгә кайтканнар. Авылда хәлләр коточкыч: ачлык-хәерчелек, сугышлар авылны тәмам корыткан була...

Октябрь революциясе булганнан соң, Галим бабайның гомер буе йөрткән хыялы тормышка ашкан: аларның гаиләсендәге бар кешегә дә, бабайның яңа туган оныгы – Хәким абыйның яңа туган беренче баласы Рәфрәфгә дә – һәммәсенә җир бүлеп биргәннәр! (Мәгълүм булганча, Патша Россиясендә хатын-кызга җир бирелмәгән!) Ул көнне бабай кояш кебек балкып, елмаеп, сөенеп кайткан.

Галим бабам (урыны оҗмахта булсын) бик мәрхәмәтле, кешелекле булган: җиде баласы өстенә ятим малай Зиннурны үзенә алып, үз баласыдай тәрбияләп үстергән.

Галим картның мәрхәмәтле күңеле заманаының сулышын тоеп, барысын да йөрәге аша үткәргән. Бигрәк тә картайган көнендә – 1921 елгы ачлыкта халыкның, балаларның ачлыктан үлүен авыр кичергән.

Хәким Галимов патша армиясендә хезмәт иткән вакытта. 1912 ел

***

Бабакаем хөр күңелле, бәхетле кеше булган дип уйлыйм: ул шатлана белгән, күңеле кешеләргә һәрчак ачык булган.

...Бервакыт Галим карт җил-җил атлап кайтып бара икән. Кәефе шәп, каршысына очраган авылдашларына елмаеп, исе китеп сөйләгән:

– Ярый әле үлмәгәнмен, бу әкәмәтне күрмичә китәсе булганмын. Хикмәтле нәрсә күрсәттеләр – тере кешеләр төшкән кәртинкә!

Бабай кино карап кайта икән – тавышсыз кино. Унтугызынчы гасырның кыл уртасында туган Галим карт яңа гасырның авырлыкларын да, хикмәтләрен дә күреп, замандашы Ленин белән бер елны – 1924 елда, хасталанып ятмыйча, йөргән җиреннән йогышлы чир эләктереп вафат булган.

Ахыры киләсе санда ■

Безнең мирас №5 май 2021

Нәселдәнлек

Рабит Батулла

Хәй Мушинский (Габделхәй Мөхәммәтшин)

Узган гасырның башларында татар артистлары арасында шундый гадәт барлыкка килде: алар, нәсел исемнәрен ташлап, Ауропада яшәүчеләр сыман, сәер кушаматлар ала башладылар. Әйтик: Ильская, Волжская, Болгарская, Ашказарский, Иманский, соңрак Гарский, Мушинский...

Хәй Мушинский татар артистлары арасында беренче иллюзионист-манипулятор булды. Татарлар иллюзионистларны «күз буучылар» дип атыйлар иде. Аның чын исем-фамилиясе – Габделхәй Мөхәммәтшин (1908-1984).

Хәй Хафиз улы Башкортстанның Тәтер елгасы буендагы Арслан исемле авылында туган. Үзенең кушаматын аклар өчен, Хәй ага үзенчә шаярта торган була: имеш, аны нәселе Гданьсктагы вак поляк шляхтичларының нәселеннән үк килә икән. Гомумән, Хәй аганың күңеле мистификациягә тартыла торган була. Сүз иярә сүз чыккач, шунысын да әйтим инде: күптән түгел генә аның торыны (оныгының оныгы) дөньяга килде, аңа Арслан исеме куштылар.

Туган авылындагы мәктәпне тәмамлагач, үсмер Габделхәй Оренбургка китә һәм педагогия институтының физфагына укырга керә. Шунда ул театр сәнгате белән кызыксына башлый. 1936 елда Габделхәй Казанга китә һәм театр техникумына актерлыкка укырга керә. Ул үзенең актерлык эшчәнлеген Камал театрында башлап җибәрә. Камал театрына багышланган китапта актер Хәй Мушинскийга атап язылган мәкалә дә басылып чыга.

Хәй аганың язмышында төрле хәлләр була. Кызыл Армиядә хезмәт итү, авыр контузия алу... Соңгысы Хәй абыйны яшәү белән үлем арасына куя. Аннан күп елларга сузылган тернәкләнү чоры... Ихтыяр көче, яшәргә омтылу... Холкының чарыш булуы аркасында, ул җиңеп чыга һәм 86 яшенә чаклы яши. Шөкер!

Драма театрында эшләгән чагында ук инде Хәй Мушинский иллюзия-манипуляция жанры белән мавыга башлый. Һәм дәүләт циркына эшкә алына. 1946 елдан алып ул гомере буе Татар дәүләт филармониясендә «күз буучы» булып эшли.

Хөрмәтле артистның иҗади тормышын тулысы белән ачып салырга алынмыйм, ләкин күп кенә концертларда Хәй ага Мушинский белән сәхнәдәш булып эшләдем, озын-озак гастрольләрдә аның белән бергә йөрергә туры килде, сәхнәдә дә, тормыш-көнкүреш шартларында да якыннан аралашкан идек. Бүген узганнар турында искә төшергәндә дә, мин Хәй аганы юксыну хисләре кичерәм, иптәш-сәхнәдәш буларак, әйтә алам: тәҗрибәсез егеткә ул остаз, яхшы тәрбияче булган икән.

1960 нчы елларда Филармониядә тугыз концерт бригадасы эшли иде. Һәр төркемгә концерт алып баручы (конферансье), фокусчы («күз буучы») кирәк иде. Җырчылар, биючеләр җитәрлек, әмма фокусчыларга, сөйләүчеләргә кытлык. Фокусчы белән сөйләүчеләргә, хәтта пенсиягә чыкканнарга да мохтаҗлык үзен сиздерә иде.

Хәй абый Мушинскийны һәр бригада үзенә алырга тырышты. Бервакыт 1967 елда җырчы Усман Әлмиев пенсионерлардан гына торган концерт төркеме оештырды: Динә Сираҗетдинова (җырчы), Наҗия Теркулова (җырчы), Җәваһирә Сәлахова (җырчы), Усман Әлмиев үзе (җырчы), Фәйзи Садыйков (музыкант), Николай Швецов (биюче), Гөлсем Баһманова (биюче), Хәй Мушинский (фокусчы), Рабит Батулла (сөйләүче). Буа, Чүпрәле якларына гастрольгә чыгып киттек. Карлы-буранлы кыш иде. Авылдан трактор чаналарында, җигүле атларга төялеп күченәбез. Халык өерелеп коцертка килә. Клублар салкын, ягылмаган. Тамашачы туңмый, алар җылы киенгән, артистлар исә җиңелчә концерт киемнәреннән җырлый-бии. Концертларыбыз тамашачы алдында һәрчак уңыш казана.

Мин эстрадада яңа кеше, сөйләүче буларак та тәҗрибәм юк, бу минем эстрада сәхнәсенә беренче тапкыр чыгуым иде. Дулкынланам, каушыйм. Хәй абый мине юата, киңәшләр бирә. Күңелне күтәрергә тырыша һәм, әйтергә кирәк, аның киңәшләре бик урынлы була иде. Хәй абыйдан шактый нәрсәгә өйрәндем, тәҗрибә алдым. Ул, ян пәрдә артына посып, мин сөйләгәннәрне игътибар белән тыңлый, соңыннан киңәш бирә. Сәхнәдә мин үземне ышанычлы, иркен тотарга өйрәндем. Усман ага да, алай итмә, болай ит, дип, мине гел өйрәтә иде. Бу ике олы артистка гомерем буе рәхмәт әйттем.

Артистларны гастрольләр вакытында, гадәттә, икешәр-өчәр итеп фатирларга урнаштыралар иде. Авылда кунакханәләр юк. Без Хәй абый белән фатирга икәү бергә төшәбез. Концерттан соң, шунда кайтып, төнге чәй эчәбез. Дәресләр самавыр янында да дәвам итә. Мин – шәкерт, Хәй абый – остаз.

– Һәр авылда төрле тамашачы була! – дип башлый ул сүзен. – Син бүген сәхнәдә каушап калдың, шуңа күрә тамашачы сиңа сирәк кенә кул чапты. Ни өчен? Бу авылда тамашачы бик үзенчәлекле. Биредә мишәрләр күп яши. Мишәр халкы туры сүзле, алар артык пафосны, купшылыкны, төчелекне яратмый. Син көлке урында елмаясың, кайгылы урында җылагандай итенәсең. Күпме генә тырышсаң да, тамашачы көлми дә, җыламый да, тик кенә утыра кебек. Әгәр дә безнең концерт аларга ошамаса, бу яктагы халык йөзеңә бәреп турысын әйтер. Алар артык тыйнаклыкны да сөйми, артык кыюлыкны да яратмый. Мишәрләр табигыйлыкны ошата. Шуңа күрә алтын урталыкны тотарга кирәк. Алдагы авылда син теге көлке хикәяң белән уңыш казандың. Бүген син үзеңне артык иркен тоттың һәм уңышсызлыкка дучар булдың. Чөнки син монда да уңыш казаначагыңа артык нык

Хәй Хафиз улы Мушинский хатыны Рабига Сөләйман кызы белән

ышанган идең. Уңыш артыннан ук уңышсызлык килә. Инерциягә ышанма син. Иркен тот үзеңне, ләкин әрсез булма! Үзеңә артык нык ышану белән кимсенү-каушау – бер бәланең ике башы.

Дөрес, чәй табыны янында без эстрада сәхнәсе турында гына сөйләшми, тормыш мәсьәләләре, көнкүреш мәшәкатьләре турында да гәпләшә торган идек.

– Энем! – диде ул бервакыт. – Авыл халкы күзәтүчән, гаепкә алучан була ул. Йорт хуҗалары да, башка авылдашлар да читтән килгән артистларга, командированныйларга җентекле игътибарлы була. Һичшиксез, алар синең турыда фикер туплый, син ничек ашыйсың, ашагач дога кыласыңмы, клубта халык белән аралашканда үзеңне ничек тотасың...

Гастрольләр вакытында бер артистыбыз, төнлә торып, тышка чыккан да ишек төбенә үк печ иткән. Иртән иртүк хуҗабикә сыер саварга чыккач, ап-ак карда сапсары бәвел эзләрен күреп: «Кайсыгызның эше бу, кяферләр?» – ди. Җир тишегенә кереп китә яздым. Ул турыда бөтен авылга хәбәр таралды: артистлар йомышларын аягүрә башкара икән. Кар белән дә күммиләр икән ул артистлар, дип сөйли халык... Хурлык, валлаһи!

Хәй абый күп нәрсәләр турында сөйләде ул вакытта. Бу тулы мәгънәсендә итагатьлелек дәресләре иде.

Әле дә хәтеремдә, Кама аръягындагы бер авылда колхоз рәисе артистларны үзенә кунакка алдырды. Төшке аш иде ул, ниндидер бәйрәм иде. Хуҗа кунаклар хөрмәтенә алкыш күтәрергә тәкъдим итте. Хәй абый стаканны тыйнак кына бер кырга этәреп әйтте:

– Рәхмәт! Бүген мәктәптә балалар каршысында көндезге концерт була! Ярамый! – диде.

Хуҗа шаркылдап көлә башлады:

– Мин үзем дә гармунчы, бер стакан дөпелдәтмичә, сәхнәгә чыкмыйм да! Әйдә, җиффәрдек!

– Юк, дустым, – диде Хәй абый. – Эш вакытында эчмим. Тәртибем шундый!

Колхоз хуҗасы никадәр кыстаса да, Хәй абый стаканга орынмады. Әгәр дә олы артист колхоз рәисе белән аракы чөмерсә, рәис үзе үк, артистлар алар эчкече, дип сөйләп йөриячәк...

Хәй абый миңа һәрчак игътибарлы булды. Мин дә аның концертка әзерләнгәнен гел күзәтә идем. Ул һәрвакыт концертка тәфсилләп әзерләнә, клубка иң беренче булып килә, реквизитларын, кечкенә чемоданыннан алып, тәртипләп тезә, бутафориясен җентекләп хәстәрли. Башкалар белән сөйләшми, үзен киләсе чыгышына әзерли яки борын эченнән генә татар халкының борынгы көйләрен көйли. Хәй абый аларны бик күп белә, пианинода бик оста уйный иде. Ул җаны белән музыкант булды. Кунакка килгән җырчыларга да Хәй абый уйный. Хатыны Рабига Сөләйман кызы Мушинская да җырчы, Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры солисткасы иде.

Хәй абый рәсем сәнгате белән якыннан кызыксына, сәнгать әсәрләрен ярата, аларга соклана иде. Үз кулы белән эшләнгән бизәкле түшәм, диварларда – табигать манзарасы, агачларда – сайрап утыручы кошлар, арысланнар сурәте аның фатирын бизи. Хәй абыйның кулы оста, ул рәсемнәр-сурәтләр өчен үз кулы белән гүзәл әрҗәләр (ырамнар) ясый. Гүзәл сәнгатькә битараф түгел иде Хәй абый. Өе борынгы антиквар әсәрләр белән тулган, әйтерсең лә, ул фатир түгел, ә күргәзмәләр залы. Бу – аның мохите, күңел күзе, күңел таләбе, бу – аның гаиләсе, бу – аның дәүләте. Җиздән бизәкләп эшләнгән шәмдәлләре белән иске пианино, нәзек муенлы кытай кувшиннары, музыкаль шкатулка, алтын йөгертелгән керосин лампасы – кыскасы, санап бетергесез антиквариат.

***

Гастрольгә әйләнеп кайтыйк әле.

Кичке концерттан соң, күрсәтелгән адрес белән без керәсе йортны эзләп киттек. Вакыт соң булуына карамастан, хуҗалар безне мул табын әзерләп көтеп торганнар. Хәй абый гомере буе гастрольләргә йөргән, елның 236 көне авылдан-авылга, шәһәрдән-шәһәргә күчеп узган. Остаз хуҗалар белән аралашканда итагать саклап күрешә, итагать саклап саубуллаша торган иде.

Төнге аштан соң йокларга җыенабыз.

Урын-җир әзерләнгән, кунакларга аерым ятак. Хуҗалар үзләре аерым йортта йокларга ятты. Без дә ятарга җыенабыз. Хәй абый кечкенә чемоданыннан пөхтәләп төрелгән җәймә алды:

– Мин һәрвакыт үзем белән җәймә алып чыгам, – диде ул. – Беренчедән, хуҗаларда артык җәймәләр, мендәр тышлары булмавы ихтимал. Икенчедән, ничектер, чит кеше җәймәсенә ятып йоклавы уңайсыз, читен бит. Ни карап торасың, син дә җәй!

Минем җәяргә җәймәм юк иде… Хәй абый чемоданыннан икенче мендәр тышы, ак җәймә чыгарды да миңа сузды:

– Миндә һәрвакыт запас була. Озын-озак гастрольләрдә йөргәндә кирәге чыгып тора…

Иртән безне аш көтә иде: пәрәмәч, корт, бал, шаулап торган самавыр һәм хуҗаларның ачык йөзе. Хәй абый, хуҗалар күрмәгәндә генә күкрәк кесәсеннән бер сум акча чыгарып, төпсә астына кыстырды. Ишарә белән миңа да шулай эшләргә кушты. Мин дә аныңча эшләдем. Бер сум ул чакта шактый бәяле, Филармония тәүлегенә бер сум «фатирный» бирә торган иде.

Кунакчыллыклары өчен хуҗаларга рәхмәт әйтеп, китәргә кузгалдык. Алар безне озата чыкты.

Юлда барганда Хәй абый аңлатты:

– Филармония безгә фатир хакы биргән икән, ул тәңкә үз вазыйфасын үтәргә тиеш. Әгәр син хуҗаларга бер сум тәкъдим итәсең икән, алар аны алмаячак, хәтта

үпкәләүләре дә бар. Иң мөһиме – синең җаның тыныч булачак, хуҗаларга бурычлы калмадың. Хуҗабикә табын җыештырганда ул ике сумны күрәчәк һәм, бәлки, эчтән генә безгә рәхмәт әйтер.

Әнә шундый холыклы иде Хәй абый, һәр гамәле алдан уйланылган булыр иде.

Эстрадада тәҗрибәсез булуым өстенә, әле мин көнкүрештә дә бичара идем. Филармониянең олы артистлары-пенсионерлары, карлы-буранлы, яңгырлы-давыллы чакларда да арбада, чанада өши-туңа гастрольдә йөргәнгә, юлга нык әзерләнеп, бөтен нечкәлекләре белән җыенып чыккан. Алар толып-тун кигән, җылы шәл ябынган, җылы бүрекле, аякларында – киез итек. Хәй абый сарык тиресеннән теккән күн бияләйдән. Шулай булгач, аларга салкын, буран нипочем! Ә мин җилән-пәлтәдән. Аякта – күн каталар, сукбай эт кебек, туңдым-каттым.

Без, өч чанага төялеп, башка авылга күчәбез. Артистларга нәрсә: алар салам түшәлгән чанада туннарына төренеп утырган да рәхәтләнеп бара. Хәлемне чамалап, Хәй абый мине чанадан төртеп төшерде. Мин егылдым, аннан, торып, чана артыннан йөгерә башладым. Чананың үрәчәсеннән тоттым дигәндә генә, кучер атларны куарга тотынды, мин тагын артта калдым. Ниһаять, шулай чапканнан соң, артистлар мине чанага тартып менгезде. Бу вакытта сулышыма ут капкан иде.

– Эссеме? – дип кычырды Хәй абый.

Әйе, эссе иде миңа.

– Юкса чанада катып үлә идең! – дип, Хәй абый тезләремне толып итәге белән каплады.

Эчтән генә аңа рәхмәтләр укыдым: чанадан этеп төшереп, ул мине катып үлүдән коткарып калды.

Икенче көнне без ерак бер авылга китәргә тиеш идек. Чатнама суык. Хәй абый фатир хуҗасына:

– Салкын тидерәчәк бит бу егет! – диде һәм хуҗадан тун белән киез итек сорап алды. – Боларны олаучыгызга кире биреп җибәрербез!

Хуҗа кеше ризалашты. Мин, аның тунын, киез итекләрен киеп, чанага алпавыт кебек киерелеп утырдым. Хәй абый мине алга таба да шулай тун һәм итекләр белән тәэмин итүне үз өстенә алды. Гастроль буе Алланың кашка тәкәседәй толып бөркәндем.

Без айга якын күчеп йөрдек. Хәй абый ай буе остазым вазыйфаларын башкарды. Мин ул әңгәмәләрне «Габделхәй абый дәресләре» дип атар идем. Мин аңа мәңге рәхмәтле, бу мәкаләм аның рухына дога булып ирешсен иде. Амин!

Тора-бара артистлык вазыйфам язучылык вазыйфасына әверелде. Һәм юлымда тагын бер Мушинский пәйда булды: Әхәт Габделхәй улы Мушинский иде ул. Әхәт Мушинский «Шәех белән Йолдыз санаучы» исемле кыйссасын бастырып чыгарды. Аның татарчасы «Һаваларда ак күгәрчен» дип атала. Хәй абый ул әсәрдә «Кыям Әхмәт улы Мөхәммәтшин» исеме белән җанланган. Игътибар итегез: автор нәсел исемен үзгәртмәгән – фамилиясен Мөхәммәтшин дип калдырган. Һәм Хәй абый ул кыйссада яланаяклы, ачлыктан интеккән кеше, атаклы артист буларак өлгергән шәхес, үтәкүренмәле саф чык тамчысындагы бриллиант очкыны сыман күренә. Монда ерак Башкортстан авылында яшәүче яшүсмернең исән калу өчен җан талашуы да, атасының зәмһәрир салкында урманда катып һәлак булуы да, оригиналь жанр артистының рәхимсез гаделсезлекләр күрүе дә, рәсем сәнгате белән мавыгуы да, шигырьләр язуы да кинодагы кебек җанлы рәвештә күз алдыннан уза…

Менә каян килә ул гадәти булмаган сәләт аның улына! Оныкларда табигать биргән талант йоклый, диләр. Дөрес түгел! Каләмдәшем Әхәт Мушинский атасын-

нан калган сәләтне үстереп, югары һөнәрмәнд дәрәҗәсенә җиткезгән, мәшәАллаһ! Бүген Әхәт Мушинкий күп проза әсәрләре – романнар, повестьлар, хикәяләр һәм мәкаләләр авторы. Әсәрләрен һәрдаим укыйм һәм яратып кабул итәм. Аннан соң Әхәт Мушинский шәп рәссам булырак та мәгълүм: шәп график. Ул җитәкләгән журнал – «Казанский альманах»тагы рәсемнәр, иллюстрацияләр үзе тарафыннан башкарылган. Дөньяда бер шәхестә баш мөхәррир дә, автор да, иллюстратор да булган башка бер генә журнал да юк шикелле, ди Рауль Мир-Хәйдәров. Каз каурые кебек җиңел оча торган буягычы Әхәтнең чын мәгънәсендә рәссам булуын раслый.

Альпинист Әхәт. Тянь-Шань, 1980 ел

Рәссам Әхәт Мушинский

Әхәт Казанда туган, Казанда яши. Шуңа күрә Әхәтнең иҗаты, башкалар иҗатыннан аермалы буларак, тирәнрәк, ихласрак һәм ул – гүзәл иҗат. Әхәт Казанны тәфсилле-җентекле белә, ул Казан өчен җаната, әтисе хатирәсен кадерләп саклый.

Әхәт Мушинский – Державин бүләгенә (Казан) ия язучы, Балалар өчен язылган милли әдәби әсәрләр ярышында (Мәскәү) бүләк иясе. Ул, Халыкара ПЕН-клубның Татарстан мәркәзе башкаручы директоры буларак, инде 25 ел хезмәт итеп килә, «Казан альманахы»н, «Идел» журналының башлангычыннан алып җитәкләгән мөхәррир.

Әгәр мөхтәрәм Хәй абый Мушинский бүген исән булса, улының әһәмиятле эш-гамәлләре өчен горурланыр, үзе хыялланганнарны улы Әхәтнең башкаруына канәгать калыр иде. Киләчәктә Мушинскийларның торыннары бу эшләрне дәвам итәрме-юкмы – анысын киләчәк күрсәтер, иншәАллаһ!

Редакциядән: *Танылган каләмдәшебез Әхәт Хәй улы Мушинскийның 27 майда гомер бәйрәме. Әдипне юбилее белән ихластан котлап, сәламәтлек, иминлек һәм иҗат уңышлары теләп калабыз!* ■

Безнең мирас №5 май 2021

Фаил блокноты, Ишморат хаты...

Эльмира Шәрифуллина

Фаил Шәфигуллинның архивы Казанның Милли музеенда саклана. Мин аны 1989 елда музей хезмәткәре, Фаилнең якташы Рәмзия Абзалина тәкъдиме белән тапшырган идем. Берничә блокнотын, күп адреслар, күп кенә исем-фамилияләр язылганга күрә, суд эшләренә кирәк булса, дип, архивка бирмичә калдырдым. Фаилнең вафатына утыз тугыз ел тулган көннәрдә ул блокнотларны менә тагын бер кат җентекләп карап утырам һәм тагын игътибарга лаек булырдай фикерләр, сүзләр табам. Кайберләрен «шигырьгә детальләр» дип тә язып куйган ул аларның. Табигый ки, блокнот, Фаилнең яраткан алымы буенча, тиз-тиз сызгалап куелган рәсем-штрихлар белән дә «бизәлгән». Менә ул фикерләр:

Язучы Фаил Шәфигуллин Әдәби атналыкта. Балык Бистәсе, 1972 ел. ***(Шагыйрь Кадыйр Сибгатуллинның шәхси архивыннан)***



***

Ут алынды, гүя өйләр чәчәк атты.

***

Ай, калын кар катламы артындагы мунча лампасы кебек, тонык нур сибә.

***

Кимсетелгәнне кимсетүең белән үзеңне дә кимсеттең түгелме соң?

***

Ии кешене, бер-берен чәйнәп атарга җитешкәннәр инде.

***

Үпкәләшеп кенә алдык, җәннәтне ычкындырганым да юк, ычкындырмыйм да, мәйтәм...

***

Кирәк бит арбага бишенче көпчәк.

***

Шуннан, утырган да шуган,
Тауга түбән булган.

***

Бал, дисәң, бер үкси,
Кашык төртсәң, ике үкси.

***

Күзләре тегермән ташы чаклы.

***

Теше сызлый торган кеше – беркем дә озатмый, беркем дә каршы алмый торган кеше.

***

Ватык чынаяк кебек.

***

Урманда җиләк эзләп йөрсәң – юк ул, ә кырыйда гына басылып җыйсаң, җиләк белән кайтасың.

***

Бездә, ягъни безнең шәһәрдә иң үтемле товар – чәчәкләр, кабатлап әйтәм, чәчәкләр.

***

Борынгылар әйтә: «Сабыр төбе – сары алтын».

***

Кыз балалар курчак-курчак уйный, ир балалар уйный ат-ат.

Риза Ишморат хаты

Гали Хуҗи (сулда), Мөхәммәт Садри, Риза Ишморат фронт газетасы редакциясендә. 1944 ел

Хөрмәтле якташым Эльмира!

Үзеңә һәм сөекле кызларыңа күп сәламнәр җибәреп, һәрвакыт шат күңел белән бәхетле яшәвегезне теләп калганымны белдергәннән соң, язар сүзләрем шул:

Бирегә килгәч (Малеевкадагы иҗат йортына. – **Э.Ш.**), «Казан утлары»ның 7 нче санында Фаил Шәфигуллинның тәмамланыр-тәмамланмас хәлдә калган кульъязмасын – синең кул белән матбугат өчен әзерләнгән «Өй салуның ние бар?» повестен бик яратып, дулкынланып укып чыктым. Ул миндә зур тәэсир калдырды. Талантлы әдип, Ватаныбызның кыю патриоты, көчле рухлы, тирән фикерле кеше, чын кеше булган икән Фаил дустыбыз дигән элеккеге фикерем тагын да көчәя төште. Аның фаҗигале төстә һәлак булуы әдәбиятыбыз өчен зур югалту булса, синең өчен, гаиләң өчен, аеруча балаларыгыз өчен нинди олы фаҗига булганын әйтәсе дә юк. Барын да зур сабырлык белән кичереп, эшеңне, бигрәк тә мактаулы иҗатыңны зур уңыш белән дәвам иттерү – бу соклангыч хәл. Барысы өчен дә рәхмәт сиңа, Эльмира!

Үз иҗатың турында әйтсәк, ул – сокландырырлык, дулкынландырырлык, уйландырырлык матур иҗат.

Кечкенә генә «Яңгыр җиле» китабында йомшак кына, назлап-иркәләп исә торган мәрхәмәтле җил дә, җылы-кояшлы яңгыр да, давыл-гарасат та, утлы яшен дә бар. Яшьләр газетасында һәм журналларда басылган «Безнең күңел» шигыре белән китапның тәмамлануы да бик урынлы, минемчә. Тирән мәгънәле, уйландыра да, сискәндереп тә куя торган, шуның белән бергә Синең рухи көчеңә ышандыра торган көчле шигырь ул.

Яшь композитор Закировның (Илгиз Закиров. – **Э.Ш.**) нәкъ шушы шигырьгә көй-музыка язуы юкка гына түгелдер дип уйлыйм.

Хәзергә шул.

Тирән хөрмәт һәм иң изге теләкләр белән – якташың **Риза Ишморатов.**

Малеевка, Серафимович исемендәге иҗат йорты, 12.09.1988. ■

Безнең мирас №5 май 2021

Адәм баласы ниләр күрми

Сәмига Сәүбанова

Сафия апа кызы Халидә белән

Журналист халкы, кызыклы вакыйгалар, кызыклы шәхесләр эзләп, җир читенә китәргә дә әзер. Ә шундый кешеләрнең янибызда гына яшәп ятуы да мөмкин бит.

Вакытында без Олы Әтнәдә туып үскән Сафия апа белән бер бүлмәдә утырдык, соңыннан да хәбәрләшеп яшәдек, җәйге бакчаларыбыз да бер ширкәттә иде.

Бергә-бергә җырлашып чәй мәҗлесләрендә утырдык, бәйрәмнәр үткәрдек. Мин аны артистлардан да уздырып матур җырлаганы өчен генә түгел, киң күңелле, ачык, ярдәмчел кеше буларак та яраттым, хөрмәт иттем.

– Җырчы итеп алып китәргә бик теләгәннәр иде, тик артистлар, кияүгә чыгып, юньле тормыш кора алмыйлар дип курыктым, – дигән иде ул бервакыт.

Дөрестән дә, шул юлдан китсә, Әлфия Авзаловалар кебек, халкыбызның яраткан сандугачына әверелгән булыр иде ул. Тик Сафия апа бу юлдан китмәвенә һич тә үкенмәде, бергә җыелышып чәй эчкән чакларда рәхәтләнеп җырлап

күңелебезне ача торган иде. Инсафлы балалар үстерде, алар да аңа кайгы-хәсрәт китермәделәр, ипле гомер иттеләр.

Яшь чакта үткәннәр белән түгел, алга карап яшисең. Олыгая төшкәч кенә үткәннәрне барлыйсың икән. Без дә соңгы вакытларда үткәннәргә еш кагыла башладык.

– Минем әни бу якларныкы түгел, ул Адыгея Республикасының Майкоп шәһәрендә туып үскән, – диде ул күптән түгел. – Рязань өлкәсеннән булган әтисе анда ничек килеп эләккәндер, балалары үсеп, үзе олыгайгач, хатыны белән Ленинградта яшәгән олы уллары янына китәргә булганнар. Ә әнине шунда яшәүче хатыны үлгән олы гына бер бай кешегә, никах укытып, кияүгә биреп калдырганнар. Ул чагында аның күкрәкләре дә калыкмаган була әле. Ире, бергә яши башлаганчы, аның җитлеккәнен көткән. Бервакыт җәй көне, ишегалдында учак ягып йөргәндә, кавказ халыклары кия торган җиләнле, папахалы җайдак аны атына салып, урлап алып китә башлагач, бабай, ул кешегә уктан атып, әнине коткарып калган.

Ире кырык яшьләр тирәсендә генә булгандыр әле. Берничә ел бер өйдә яшәп, ниһаять, хатын вазыйфасын үти башлагач, 1914 елда уллары туган, аңа Хәким исеме куйганнар.

Әти-әниләреннән берүзе калган Маһирә бик сагынган, иреннән үзен аларны күреп кайтырга җибәрүен сорап ялынган. Заманалар куркыныч, Беренче бөтендөнья сугышы чорлары булгач, ире аның белән юлга чыга алмаган, яшь хатынын да сабыр итәргә үгетләсә дә, аның күз яшьләренә түзә алмыйча, әниләре янына кайтырга рөхсәт иткән.

– Син аннан барыбер кире кайтмыйсың инде, кирәк әйберләреңне дә ал, – дигән ул.

– Мин кунакка гына барам бит, – дигән Маһирә. Чөнки, бердән, иренең җибәрмәвеннән курыкса, икенчедән, алда ни көткәнен үзе дә белмәгән әле ул.

Ире аны яшь ярымлык улы белән озатып җибәргән. Күпне күргән кеше буларак, аның кире кайтмаячагын белгән инде.

Маһирә әтисе белән әнисе яшәгән абыйсы белән җиңгәсенең зур булмаган фатирына кайтып кергән, тегү фабрикасына эшкә урнашкан. Җиңги кеше аның бала белән кайтуын яратмаган, билгеле. Шул чагында аларга Касыймхан Чанышев дигән кеше белән очрашырга Казан шәһәреннән Рабига исемле хатыны килеп төшә. Менә шул Рабига дигән хатын малайны үзләренә уллыкка бирүне сорый, чөнки аларның балалары булмый.

– Син яшь, балаларың тагын булыр, бусын үз балабыз итеп үстерербез, җитмәсә, үзебезнең як егетенә дә кияүгә чыккансың, кирәк чагында килеп йөрерсең, – ди ул.

Бала хәтле баланы биреп җибәргәч, ул хатын аларның бик белгән, якын, ышанычлы кешеләре булгандыр, күрәсең. Соңыннан, чынлап та, алар Рабигаларга еш барып йөриләр, мәктәптә укыганда каникулларга Хәким үзе дә Әтнәгә әнисе янына кайтып йөри.

Уллыкка алсалар да, үзләренең исем-фамилиясен биреп, аны рәсмиләштерүгә игътибар итмәгәннәр, күрәсең, малай үз әтисе фамилиясендә калган.

Ә Маһирә... Чибәр кызга урыс егетләре дә бик кызыккан. Әтисе исә, хәрби гарнизонга барып, кызына кияү булырдай татар егете эзләгән һәм шунда мулла булып хезмәт итүче Кәрим Баязитов дигән егет белән танышып, аны үзләренә кунакка чакырган. Ул чагында армиядә рәсми рәвештә христиан

динендәгеләргә поп булса, татар егетләренә мулла штаты да каралган. Полковой мулла дип йөрткәннәр аларны. Әтнә мәхәлләсе мулласы Баязит Әтнәленең улы Кәрим заманында Кышкар мәдрәсәсендә укыган. Ул армиягә Габдулла Тукай белән бергә каралырга баргач, шагыйрьне, бер күзенә ак төшеп күрмәү сәбәпле, армия хезмәтеннән азат итүләрен искә ала торган була.

Солдат хезмәтен тәмамлагач, менә шул Кәрим белән никахыннан туган Әминә исемле кызлары белән өчәүләп иренең туган авылы Әтнәгә кайтып төшәләр. Кәрим Баязитов Әтнә авылында волость башлыгы булып эшли башлый.

> «Шулай да үз әтисен бер тапкыр күреп кала ул. Кемдер аның алар йортына таба килүен әйтә. Моны ишетеп, сабый урамга йөгереп чыга. Әтисе кызын күтәреп сөйгәндә, бите буйлап ике күзеннән яшь ага. Ул елый, кечкенә Сафия елый. Хатынының: «Балаларны кызган», – дигән сүзләрен исендә тотып, капканы ачып ишегалдына да керә алмыйча үтеп китә ул.

Шулай итеп бәхетле генә яшәп китә болар. Тик аларга теш кайраучылар да була шул. Чибәр, бөтен яктан булган хатыныннан да нык көнлиләр, араларын төрлечә бозмакчы булалар, мулла кеше ничек совет оешмасына җитәкчелек итә, дип, шикаятьләр язалар. Кыскасы, бик матур җырлаучы, тау халыклары кызлары белән бергә гармунда уйнарга өйрәнгән, тегү-чигүгә оста булган Маһирәне үзенеке итәргә теләүчеләр күп була.

Максатларына ирешә алмагач, Сафия туып бер ай үткәч, 1931 елның августында кызу урак өстендә көпә-көндез авылның берничә җирендәге иң шәп йортларга ут төртәләр. Бөтен кеше басуда чагында янгын чыгып, ярты Әтнә янып бетә. Янгын вакытында бер айлык Сафияне, ут зыян салмасын өчен, бишеге белән бергә Әтнә уртасыннан аккан елга буена илтеп куялар. Бу афәттә аларның асты таш, өсте агач ике катлы зур йортлары да юкка чыга.

Янгынның зурга китүендә гаепне волость башлыгы Кәримнән күрәләр һәм суд аны зур срокка төрмәгә ябарга дигән карар чыгара.

Төрмәгә кергәч кире кайта алмаячагын аңлаган Кәрим башта урманга качып яши, көннәр салкынайгач, төрле җирдәге таныш-белешләрендә кунып йөри, кешеләргә ялланып, тамагын туйдырырга мәҗбүр була. Аннан соң Биектау районында яшәүче туганнарына барып сыена, соңыннан бер марҗа әбидә фатирда тора.

Ә Маһирә... Башта алар кемнеңдер мунчасында яшиләр. Лениградта чагында тегү фабрикасында ирләр күлмәге тегәргә өйрәнгән була, әлеге һөнәре бик ярап куя – кешеләргә шуны тегеп, акча җыеп, йортлык бура ала, кечкенә генә булса да йорт җиткерә. Бер төндә ире ишекне шакый. Тик Маһирә:

– Зинһар, безне кызган, балалар кечкенә дип тормаслар, башымны Себергә олактырырлар, рәнҗемә, ача алмыйм, – дип, аны өенә кертми. Чөнки авылга ут төртүчеләрнең аның да һәр адымын күзәтеп торуларыннан шикләнә. Ә үзенең йөрәгеннән кан тама.

Тормыш берәүләрнең башына кайгы килде дип туктап калмый. Маһирәнең дә елап утырырга вакыты булмый. Колхозда җир җимертеп эшли, исеме гел алдынгылар рәтендә була. Әтнәнең менә дигән егетләре яучылый аны. Шулай итеп, ул өченче тапкыр үзеннән шактый яшьрәк, үзе кебек үк тырыш Хәкимулла дигән егеткә кияүгә чыга.

Тагын бер малай дөньяга килә. Аңа Рәфкать дигән исем бирәләр. Әминә ул чагында җиткән кыз булып, үз көнен үзе күрә башлый инде. Әтисен дә яхшы хәтерли. Ә менә аңардан бер айлык кына булып калган Сафиянең әти дигән сүзне әйтәсе бик килә. Ул үзенә күчтәнәч итеп биргән конфетларны да, әти дип әйтергә рөхсәт итмәсме, дип, Хәкимулла абыйсына алып кайтып тоттыра. Тик үги әти бала тансыклаган сүзне әйттерми.

– Бигрәк әтисенә охшаган бит, – дип, хатынының үткәненнән көнләшүен яшереп тә тормый.

1941 елда ил өстендә сугыш куркынычы тугач, йомшара төшә тагын. Фронтка киткән чагында:

– Синең кулың белә, минем кышкы пальтомнан Сафия белән Рәфкатькә пальто тегеп кидер, – дип әйтеп калдыра.

– Шул пальтоны кигәч, әти кочаклаган шикелле була иде, – дип искә ала Сафия апа.

Сугыш Хәкимулланы да йота…

Шулай да үз әтисен бер тапкыр күреп кала ул. Кемдер аның алар йортына таба килүен әйтә. Моны ишетеп, сабый урамга йөгереп чыга. Әтисе кызын күтәреп сөйгәндә, бите буйлап ике күзеннән яшь ага. Ул елый, кечкенә Сафия елый. Хатынының: «Балаларны кызган», – дигән сүзләрен исендә тотып, капканы ачып ишегалдына да керә алмыйча үтеп китә ул.

Әниләре сугыштан соң райкомда курьер, җыештыручы булып эшли. Шул чагында аңа булышырга килгән Сафия, андагы язу машинкасында басарга өйрәнеп, райсоюзда машинистка булып эшкә урнаша. Берничә ел эшләгәч, Әгъзам исемле Казан егетенә кияүгә чыгып, Татарстан китап нәшриятында эшли башлый. Мин аларның коллективына килеп кергәндә, Сафия апа Язучылар союзы карамагындагы хәзерге шул исемдәге журналның чишмә башы булган «Идел» альманахында эшли иде.

Сафия апа гомер буена язучылар белән аралашып, дус булып яшәде, аларның кулдан язган әсәрләрен, күз нурларын түгеп, машинкада басты. Күңеленә ошаган абзацларны, шигырьләрне, эшен туктатып, безгә дә кычкырып укый иде. Бүгенге көндә халыкка танылган әдипләрнең күбесенең беренче иҗат җимешләре Сафия апаның бармагы аша кәгазьгә күчеп, китапларга әйләнде, алар күпме газета һәм журналларны бизәде.

2019 елның 31 августында Сафия апа бакыйлыкка күчте. Авыр туфрагы җиңел булсын мәрхүмәнең. ■

Безнең мирас №5 май 2021

КАРА ТӘКЪДИР

(Ачы язмышлы шәхесләр)

ГЫЙЛЬМИ ФӘРИТ (1947-1993)

Татар язучысы. Татарстанның Мөслим төбәгендәге Уразмәт авылында туган.

Фәрит Гыйльми 1993 елның 16 октябрендә кичкырын, эштән кайтып килгәндә, үз йорты янында билгесез җанкыярлар тарафыннан кыйнап үтерелә. Әлмәт районындагы Бигәш авылы зиратында җирләнә.

ГЫЙЛӘҖЕВ АЯЗ (1928-2002)

Прозаик һәм драматург. Татарстанның Сарман төбәгендәге Чукмарлы авылында мөгаллимнәр гаиләсендә туган.

Университетта укыганда: «Нигә сез безгә Галимҗан Ибраһимов, Мәхмүт Галәү, Дәрдемәндләрнең иҗатын өйрәтмисез?» – дигәне өчен, аны репрессиялиләр. Ул биш ел тоткынлык газабын татый.

ГЫЙМАДИ ӘХМӘТ (1915-1943)

Балалар язучысы. Казан типографиясендә хәреф җыючы гаиләсендә туган.

Әхмәт Гыймади Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак була.



ДИБАГ МАМУТ (1905-1942)

Кырымтатар шагыйре. Кырымдагы Бакчасарай каласында туган.

Совет Севастополен немец баскынчыларыннан саклаганда һәлак була. Ике елдан соң аның гаиләсен сөргенгә җибәрәләр.

Дәвамы. Башы журналның 10 нчы (2020) санында.

ДӘРДЕМӘНД (1859-1921)

Татар шагыйре. Дәрдемәнд (Закир Садыйк улы Рәмиев) Оренбург губернасының Эстәрлетамак өязендәге Җиргән авылында сәүдәгәр гаиләсендә туган. Советлар хөкүмәтенә бөтен байлыгын, алтын базларын (приискларын), йортларын ихтыяри тапшырганнан соң, ул үзенең элеккеге хезмәтчесе өендә 1921 елда Орск шәһәрендә вафат була һәм аның җәсәде Татар зиратына җирләнә. Ләкин... Совет хакимияте Татар зиратын җимереп, аның өстенә патроннар ясый торган хәрби завод корып куя. Дәрдемәнднең кабер ташы да, сөякләре дә шул мәхшәрдә юкка чыга.

ДӘҮЛӘТКИЛДИЕВА МАҺИПӘРВАЗ (1882-19??)

Балалар табибәсе. Ленин ордены иясе. Статский советник Шаһбазгәрәй Әхмәров гаиләсендә Казанда туган.

1920 елда Кызыл террор вакытында Шаһбазгәрәй йортына революцион солдатлар басып керә. Тентү ясаганда, кызыл командир маузерен Маһипәрваз ханымның күкрәгенә терәп, Советларга каршы листовкалар таптыра.

Маһипәрвазның 18 яшьлек улы Рөстәм, гәүдәсе белән әнисенең күкрәген каплап, кызылларга чыгып китәргә куша. Кызыл командир егетнең йөрәгенә ата. Рөстәм шулай һәлак була.

Рөстәмне җирләгәннән соң, ике көннән командир каты җәрәхәтләнгән үз улын Маһипәрваз янына алып килә. Маһипәрваз Рөстәмне атып үтергән командирны таный, ләкин ул, табиб буларак, яралы балага ярдәм итми кала алмый. Маһипәрваз, малайга катлаулы операция ясап, аны үлемнән коткара. Командир да Маһипәрвазны таный. Ул табибәдән кичерү сорый. Маһипәрваз аңа: «Алга таба балаларга атасы булмагыз, балалар гаепле түгел!» – ди.

ДЕВИШ ГОМӘР (1897-1964)

Татар режиссеры. Касыйм шәһәрендә туган. Төрле татар театрларында эшләп карый. Гомәр Девиш, хезмәттәшләренең аңа шикләнеп каравы аркасында, еш кына эш урынын алыштырырга мәҗбүр була: Казан, Кырым, Мәскәү, Әлмәт театрлары.

Бераз ГУЛАГта да утырып чыга. 65 яшендә вафат була.

ДЕРМЕНҖИ АБДУЛЛА (1905-1976)

Кырымтатар язучысы. Кырымдагы Ялта төбәгенең Кәкәнеиз авылында туган. Кырымны фашистлардан саклауда катнаша.

Бу сугышта ул каты яралана, гарипләнеп, туган авылына кайта. Әмма ни күрә: авыл буш, ач хайваннар гына караусыз калган, татарларны Ватаннарыннан сөргәннәр. Гаиләсен ул Үзбәкстанда эзләп таба. Абдулла Дерменҗи, җәрәхәтләре ачылып, туганнары кулында тәрбияләнә. Ташкентта җирләнгән.

*Текстны басмага **Рабит Батулла** әзерләде.* ■

Истә, һаман да истә!

Язучы
Тәуфикъ Әйдинең
тууына 80 ел



Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1991), 1982 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы, язучы, публицист Тәуфикъ Әйди (Тәуфикъ Рамазан улы Әйделдинев) 1941 елның 1 маенда Мәскәү өлкәсенең Шатура районындагы Туголеевский Бор бистәсендә туган. Бала һәм үсмер чагы Татарстанның Апас районындагы Түбән Балтай (1941-1951; 1955-1957), Олы Бакырчы (1954), Омск өлкәсенең Азов районындагы Төк (1951-1953) авылларында уза. 1983-1985 нче елларда ул Мәскәүдә СССР Язучылар союзы каршындагы ике еллык Югары әдәби курсларда укый. Т.Әйдинең балалар өчен язган беренче хикәяләре «Яшь ленинчы» газетасы һәм «Ялкын» журналы битләрендә 1967 елда басыла.

Әдипнең кайбер китаплары: «Бөҗра» (1978), «Яңа уен» (1988), «Безгә ни булды?» (1991), «Елан угы» (1991) h.б.

Т.Әйди 2001 елның 2 апрелендә Казанда вафат булды. Мәрхүмнең җәсәде Биектау районының Әлдермеш авылы зиратында җирләнде.

Язучы
Гафур Коләхмәтовның
туына 140 ел

Прозаик, драматург, публицист Гафур Коләхмәтов (Габделгафур Юныс улы Коләхмәтов) 1881 елның 22 апрелендә (яңа стиль белән 5 майда) Пенза шәһәрендә туган.

Гафур энесе Каюм белән башта Түбән Ломов өязендәге Ятмис авылы мәдрәсәсендә белем ала, аннары Казан шәһәрендәге Учительская школада укый.

Драматург Г.Коләхмәтовның атаклы «Ике фикер» әсәре беренче мәртәбә 1925 елда Ф.Агиев төзеп чыгарган «Г.Коләхмәтов мәҗмугасы»нда дөнья күрә. Аның «Яшьләр» драмасы исә, 1907 елда язылып, 1908 елда аерым китап булып басылып чыга.

Г.Коләхмәтов 1918 елның 1 апрелендә Пенза губернасының Краснослободск өязе хастаханәсендә үпкә авыруыннан вафат була. Мәрхүмнең җәсәде Мордва Республикасының Торбеево районындагы Юнә авылы зиратында җирләнә.

Режиссер
Шириязданн Сарымсаковның
тууына 110 ел

Татарстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (1958), режиссер Шириаздан Мөхәммәтҗан улы Сарымсаков 1911 елның 12 маенда Казакъстандагы Акмола өязенең Атбасар шәһәрендә туган.

Ул 1928-1930 нчы елларда Казандагы Татар театр техникумында укый, 1945 елдан Казан театр училищесында актерлык осталыгына өйрәтә.

Ш.Сарымсаков 1942-1943 нче һәм 1952-1958 нче елларда Г.Камал исемендәге татар дәүләт академия театрының баш режиссеры була. Театрда утыз ел эшләү чорында ул татар, рус һәм чит ил драматургларының җитмештән артык пьесасын сәхнәгә куя.

Ш.Сарымсаков 1999 елның 30 сентябрендә Казанда вафат булды һәм Яңа бистә зиратында җирләнде.

Композитор
Солтан Габәшинең
тууына 130 ел

Татарлардан беренче профессиональ композитор һәм педагог Солтан Габәши (Солтан Хәсәнгата улы Габәши) 1891 елның 13 маенда хәзерге Биектау районының Keче Солабаш авылында мулла Хәсәнгата Габәши авылында туган.

Солтан кечкенә вакытында ук кубызда һәм гармунда халык көйләрен уйнарга өйрәнә. 1913-1915 нче елларда ул үзенең «Кәккүк», «Рокыя-гөлкәем», «Вальс», «Пикник» һәм «Татар кызы» дигән әсәрләрен яза.

С.Габәши 1915 елда Казанга килә һәм татар драма труппасының берничә спектакленә (Г.Исхакыйның «Зөләйха», Ф.Бурнашның «Таһир-Зөһрә», К.Рәхимнең «Бүз егет» әсәрләре) көйләр яза. 1932 елда ул Уфага күчеп китә һәм Башкорт сәнгать техникумында укыта, Башкортстан Композиторлар берлеген оештыручыларның берсе була.

С.Габәши 1942 елның 8 гыйнварында Борай районының Чалкак авылында вафат була.

Сәхифәне ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.* ■

Матбугат һәм туган тел

Рүзәл Юсупов, филология фәннәре докторы

Хәзер татар телен, бигрәк тә әдәби телне, саклау һәм үстерү өчен шартлар көннән-көн кыенлаша: соңгы бер-ике дистә елда милли мәктәпләрнең саны бик кимеде һәм булганнарында да туган телне укытуның сәгатьләре бик аз калды. Димәк, ана телен өйрәнү һәм аны куллану дәрәҗәсе кискен түбәнәя бара. Шуңа бәйле рәвештә татар әдәбиятын укучыларның сафлары да күзгә күренеп сирәгәя. Бу – телебездән файдаланучыларның мәйданы да тарая, татар теленең яшәешенә куркыныч яный дигән сүз.

Әлбәттә, халык туган теленең бетүе белән килешеп тормас, Татарстанның хакимият ияләре дә туган телебезнең, мәдәниятнең һәм милләтнең киләчәгенә һәрвакыт битараф булып тормаслар. Ләкин вакыт уза һәм әлегә дәүләт, телебезне саклап калу өчен, тиешле дәрәҗәдә җитди чаралар күрергә ашыкмый. Республикабызда мондый халәт хөкем сөргәндә, туган телебезне, аның сафлыгын, дөреслеген югалтмыйча саклау өчен ниләр эшләргә, нинди чаралар күрергә мөмкин икән соң? Бу сорау барыннан да бигрәк көндәлек эшләре туган тел белән бәйләнгән һөнәр ияләренә карый. Мондый һөнәр ияләренең иң бәрәкәтлеләре, иң куәтлеләре – журналистлар. Матбугат – халыкның дөрес әдәби туган телен өйрәнүенә һәм куллануына ярдәм итеп торырга тиешле бик әһәмиятле чара. Безнең журналистларның изге бурычы – матбугатны саф, матур, чын татар әдәби телендә әзерләп укучыга җиткерү.

Матбугатның табигый дөрес татар телендә чыгып баруы – телебезнең саклануы өчен иң нәтиҗәле, иң мөһим шарт. Без бу язмабызда матбугатка куелган шушы югары таләп җирлегендә бүгенге газеталар теленең торышы, сыйфаты, андагы проблемалар хакында һәм шул уңайдан татар журналистлары алдында торган бурычлар турында сүз йөртербез.

Без халыкның рухи тормышында әһәмиятле роль уйнаган журналистларның фидакарь хезмәтләренә югары бәя биреп, татарча газета-журналларның бүгенге көндә туган телне саклау өлкәсендәге роленә аеруча зур игътибар итәргә кирәк дигән фикердә торабыз. Хәзерге шартларда милли матбугатка куелган иң мөһим таләпләрнең берсе шул: аның теле үрнәк әдәби тел булырга тиеш. Безнең газеталарның җәмгыятьтә тоткан урынын билгеләгәндә, аларның эчтәлеге, тематикасы белән бер үк вакытта, телләренең сыйфатын, әле әйтелгән үрнәк тел таләбенә җавап бирә алу-алмауларын да исәптә тоту зарур.

Дистәләрчә еллар буена татар матбугатын даими рәвештә укып, аның турында йөзләрчә мәкаләләр, дистәләрчә китаплар язган кеше буларак, татарча газета-журналларның теленә карата мөнәсәбәтемне белдерерлек нигезем һәм моңа хакым бардыр дип уйлыйм.

Матбугаттагы иҗтимагый-сәяси, фәнни-техник эчтәлекле материалларның, төрле хәбәр-белдерүләрнең теле көннән-көн җанлы, табигый сөйләм теленнән аермалы, үзенә күрә бертөрле коры, «казенный», ясалма-калька теле була бара. Бу кырыс фикеребез буш сүз генә булып калмасын өчен, без аны реаль фактлар, конкрет мисаллар белән расларга тырышырбыз, шул ук вакытта бүгенге

матбугат телендә киң таралган, күп санлы тупас ялгышларның барлыкка килү сәбәпләрен ачыклап, алардан арыну һәм аларны моннан соң булдырмау чараларын да тәкъдим итәрбез.

Татарча матбугат теленең шулай торган саен ныграк бозыла, коры, бизәксез, «казенный» телгә әверелә баруының төп сәбәбе журналистларның, күп материалларны русчадан тәрҗемә итеп алганда, тәрҗемә эшенең принцип-методларын белмәгәнлектән, рус теленә генә хас сүз, тәгъбир, җөмлә өлгеләрен механик рәвештә татар теленә күчереп куюларында. Тәрҗемә, нигездә, алар тарафыннан сүзгә-сүз, хәрефкә-хәреф (калькалаштыру) ысулы белән башкарыла. Болай тәрҗемә итү, мәгълүм булганча, икенче телдә оригиналның эчтәлеген, мәгънәсен төгәл белдерергә комачаулый һәм тәрҗемә теленең табигый төзелешен бозуга китерә.

Безнең татар һәм рус телләре белән эш итүче каләм ияләре бу эштәге иң әһәмиятле, хәлиткеч принципны исәпкә алмыйлар: бер телдәге текстны, сөйләмне икенче телгә күчергәндә оргиналның эчтәлеге, мәгънәсе мөмкин булганча төгәл белдерелергә, шул ук вакытта тәрҗемә теле дөрес, табигый тел буларак сакланырга тиеш. Бу принцип оригиналның җөмләсенә (кайчакта аннан да киңрәк контекстка), сүзтезмәсенә (тәгъбиренә, гыйбарәсенә) салынган мәгънәне тәрҗемә теле чаралары ярдәмендә белдерү юлы белән гамәлгә ашырыла. Татар матбугатында хезмәт итүчеләр исә, нигездә, оригиналның һәр сүзен тәрҗемә телендәге аерым сүз ярдәмендә тәгъбир итү ысулы белән эшлиләр. Шуның өстенә, тәрҗемә телендә оригинал сүзенә тәңгәллек, гадәттә, ул сүзнең киң контексттагы (тексттагы, җөмләдәге, әйтелмәдәге) мәгънәсен белдерерлек итеп түгел, бәлки, аның иң күп таралган, ике тел сүзлекләрендә теркәлгән, төп мәгънәсен белдерерлек итеп кенә билгеләнә.

> **«Татар матбугатында яңа сүзләр ясап куллану гадәткә кереп бара. Әгәр дә алар табигый сүз ясалышы кагыйдәләре буенча ясалып, тиешле мәгънәне ачык, төгәл итеп белдерсәләр, моннан зыян булмас иде. Ләкин алар, нигездә, киресенчә, уңышсыз, ялгыш ясалган лексик берәмлекләрне тәшкил итәләр һәм туган телне бозуга, чүпләүгә генә китерәләр.**

Мәсәлән, рус телендәге **птица, лететь** сүзләре һәм аларның татар телендәге тәңгәллекләре **кош** һәм **очу** сүзләре ике телдә дә, үзара мәгънәле бәйләнешкә кереп, табигый сүзтезмә (җөмлә) тәшкил итәләр: **птица летает – кош оча.** Шул ук вакытта рус телендәге **человек** һәм **лететь** сүзләре, үзара бәйләнешкә кереп, мәгънәле берәмлек тәшкил итсә (мәсәлән, «Р.Н.Минниханов полетел в Москву» җөмләсендә), аларның татар телендәге тәңгәллекләре (**кеше** һәм **оча**), үзара бәйләнешкә кереп, табигый сөйләм берәмлеге тәшкил итә алмый: **кеше оча** (мәсәлән, «премьер-министр Кытайга оча») дип әйтеп булмый. Русчадан тәрҗемә итеп эшләүче журналистларның (аларның барысына да диярлек күпмедер дәрәҗәдә тәрҗемә итәргә туры килә) телендәге күп ялгышлар нәкъ менә шушы ике телдәге тәңгәл сүзләрнең мәгънәле бәйләнешкә керү үзенчәлекләрен исәпкә алмаулары, тәгаенләп әйткәндә, татар һәм рус телләрендәге тәңгәл сүзләрнең

семантик бәйләнешләрендәге гомуми һәм аермалы сыйфатларын белеп эш итмәүләре, рус телендәге сүзләр бәйләнеше өлгеләрен татар теленә механик рәвештә күчереп куюлары аркасында килеп чыга.

Сүзләрнең сөйләмдә үзара табигый семантик бәйләнешләре бозылып төзелгән әйтелмәләр (сүзтезмәләр) газеталарда меңнәрчә исәпләнә. Аеруча гыйбрәтлеләрен – татар теле өчен бигрәк тә ят, сәер, котсыз, ямьсезләрен – укучылар игътибарына да тәкъдим итәргә булдык.

Рус теленең **рост, развитие** сүзләрен һәр очракта да ялгыш **үсү** сүзе белән тәрҗемә итү нәтиҗәсендә барлыкка китерелгән «гарип» сүзтезмәләр (тәгъбирләр): *хезмәттәшлек үсә* (дөресе – хезмәттәшлек киңәя, җәелә, ныгый һ.б.); *элемтәләр үсә* (элемтәләр киңәя, ныгый һ.б. кирәк); *акча күләме үсә* (…арта кирәк); *температура үсә* (күтәрелә); *тарифлар үсә* (күтәрелә, арта); *мөнәсәбәтләр үсә* (…ныгый кирәк); *канәгатьсезлек үсә* (көчәя); *вакыйгалар үсә* (куера, кискенләшә); *Россиядән качарга теләүчеләр саны үсә* (арта); *бәяләр үсә* (арта, күтәрелә); *ризасызлык үсә* (көчәя, арта); *киеренкелек үсә* (көчәя, арта); *авыру үсә* (көчәя); *хәл үсә* (киеренкеләнә, катлаулана); *куркыныч үсә* (арта) һ.б.

Глубокий (-ая, -ое) сүзен һәрчак төп мәгънәсендәге **тирән** сүзе белән тәрҗемә итү аркасында барлыкка килеп, газета-журналларда гына түгел, радио-телевидениедә дә һәм башка урыннарда да еш кулланыла торган гайре табигый гыйбарәләр: *тирән ихтирам* (дөресе – нык (бик) ихтирам итү, зур, олы ихтирам һ.б.); *тирән мәхәббәт* (көчле мәхәббәт, нык ярату һ.б.); *тирән кайгы* (зур кайгы, кара кайгы); *тирән борчу* (зур борчу); *фәнне тирән белгән укытучылар* (фәнне яхшы белгән укытучылар); *тирәнтен ялгыша* (нык ялгыша); *тирән рәхмәт* (зур рәхмәт); *тирән тәэсир* (көчле тәэсир); *тирән кызыксыну* (нык кызыксыну); *тирән үзләштерү* (нык, яхшы, төптән үзләштерү); *тирән игътибар* (зур игътибар); *тирән ышаныч* (нык ышану, зур ышаныч); *тирән дуслык* (нык, көчле дуслык); *тирән канәгатьләнү* (нык, зур канәгатьләнү); *тирән уйлану* (ныклап уйлану, җитди уйлану); *тирән үзгәреш* (зур үзгәреш); *тирән ачу* (зур ачу); *тирән аңлау* (яхшы, төптән аңлау) һ.б.

Рус телендәге **крупный (-ая, -ое)** һәм татар телендәге **эре** сүзе мәгънәләре белән бер-берсенә өлешчә генә туры киләләр: бер үк төрле зур кисәкләрдән торган (киресе – **вак**), шулай ук данәләп исәпләнә торган әйберләр (эре күкәй, эре суган, эре алма һ.б.). Үзара мөнәсәбәттәге телләрнең специфик (берсенә генә хас) үзенчәлекләрен белеп бетермәгән каләм ияләре **крупный** сүзен, контексттагы (сөйләмдәге) конкрет мәгънәсенә төшенеп тормыйча, һәр очракта да **эре** дип тәрҗемә итәләр һәм, нәтиҗәдә, тупас ялгышлар ясыйлар. Мисаллар: *эре шәһәрләр* (дөресе – зур шәһәрләр); *эре предприятиеләр* (зур предприятиеләр); *эре җитәкче* (зур…); *эре халыклар* (күп санлы халыклар) һ.б.

Предупредить, мәгънәсенә карап, татар теленә төрле сүзләр белән тәрҗемә ителергә тиеш: а) ниндидер ярамаган, хәтәр, зарарлы эш (күренеш) булуы турында кешеләргә алдан әйтеп, хәбәр итеп куйганда **кисәтү** сүзе белән (мәсәлән, баланы шырпы белән уйнарга ярамаганлыгы турында кисәтү); б) ниндидер тискәре, зарарлы күренешне, хәлне булдырмас өчен тиешле чаралар күрү мәгънәсендә **булдырмау, булдырмый калу, саклану** сүзләре белән. Ләкин ике тел ияләре еш кына бу хакта белмиләр һәм **предупредить**ны һәр очракта да **кисәтү** дип тәрҗемә итәләр. Нәтиҗәдә, әлбәттә, татар теленең дөрес сөйләм нормалары тупас бозыла. Мәсәлән: *«Максат – сәламәтлеккә зыян салуны кисәтү»* (дөресе – «…зыян китермәү, зыян китерүдән саклану»); *«Астманы ничек кисәтергә?»* («Астманы ничек булдырмаска?» яки «Астмадан ничек сакланырга?»); *«Җир җиләге кан тамыры-йөрәк авыруларын*

кисәтә» (дөресе – «...авыруларын булдырмаска ярдәм итә» яки «...авыруларыннан саклый»); «*туберкулезга каршы кисәтү чаралары»* (дөресе – «туберкулезга каршы көрәш чаралары»); «*авыруны дәвалауга караганда, кисәтү җиңелрәк»* («дөресе – авыруны дәвалауга караганда, аннан саклану җиңелрәк») һ.б.

Соңгы ике-өч елда безнең журналистлар телне куллану өлкәсендә аеруча зур новаторлык күрсәтүгә күнегеп киттеләр. Тик ул новаторлыклары үзләрен канәгатьләндерү һәм шатландыру өчен генә булса инде, югыйсә аның халык өчен, матбугат укучыларга һич кенә дә кирәге юк, чөнки алар чын татарча түгел, тиешле мәгънәне аңлаешлы итеп белдерә алмыйлар. Менә аларның кайберләре.

Рус теленең **звучать, озвучить (озвучивать)** сүзләрен тәрҗемә итә белмәүдән килеп чыккан **яңгырау, яңгырату** ярдәмендә ясалган тузга язмаган әйтелмә-сүзтезмәләр: *анда яңгыраган мәгълүматларга караганда...; шелтәләр дә яңгырады; теләкләр дә яңгырады; ...саннар коллегия утырышында яңгырады; сораулар да яңгырады; ...дәресендә яңгыраткан идеяләр; фикерләр яңгырады; чынбарлыкны яңгыратты.* Бу әйтелмәләрдәге төшенчәләрнең берсе дә яңгырый торган нәрсәләр түгел ләбаса, ул тәгъбирләрне алардагы *яңгырады* сүзен тиешле сүзләр белән алыштырып, чын татарча итеп әйтү бер дә авыр түгел: *шелтәләр белдерелә (ясала); теләкләр белдерелә (әйтелә); саннар китерелә; сораулар бирелә; идеяләр белдерелә, әйтелә; фикерләр белдерелә; тәкъдимнәр ясала.*

Русчадагы **сократить (сокращать)** сүзен һәр урында да ялгыш **кыскарту** дип тәрҗемә итү аркасында *татар теле сәгатьләрен киметтеләр яки азайттылар, татар мәктәпләрен киметтеләр* яки *яптылар, хезмәт хакын киметтеләр, чиновниклар санын киметтеләр* дип әйтәсе урында *татар теле сәгатьләрен, мәктәпләрен, хезмәт хакын, чиновниклар санын кыскарттылар* дип язалар һәм сөйлиләр.

Бүгенге матбугат битләрендә **живой** сүзеннән уйлап тормыйча гына тәрҗемә ителгән **тере** сүзе белән төзелгән сәер әйтелмәләр дә шактый күп күренә: *тере традиция, тере могҗизалар, тере тавыш, тере акча, тере чәчәкләр, тере тәгълимат, моңның тере гәүдәләнеше һ.б.*

Текә (круто, крутой) сүзе белән ясалган гыйбарәләр дә татар телен бозуга җитди өлеш кертәләр: *текә егетләр, текә почта бүлекчәсе, ...ярышта текә исем өчен 63 әби көч сынашкан һ.б.*

Рус теленнән механик рәвештә, ягъни уйлап тормыйча гына калькалаштырып алынган мондый тупас, шыксыз тәгъбирләр татар телен нык бозалар, пычраталар, аның табигый төзелешен какшаталар: *үз өстем(ң,н)дә эшләү, кул белән тудырылган гүзәллек, кошлар җырлаудан туктамый, тыйнак кына утыручы радио бинасы, яңгыраган җан ачысы, кыргый табигать, кыргый пляж, күп шалтыратулар кабул итә, укучылар өстендә нык эшләргә кирәк, сәламәт яшәү рәвеше алып бару, 100 яшьлек мәчет, тәнкыйть күзлегеннән чыгып карау, нечкә иреннәрен кысып, бер төркем... хаҗ кылырга очты, сине начальникка сорыйлар, киң танылу ала, яшь кызларга үреп салган чәчләр бара, кочегар булып эшләдем, күмер йоттым, матур сөйләмгә зур басым ясарга уйладык, авылларыбыз картаймасын, тәрәзә тирли, чи сөтне эчмәгез, төен пункт, вулкан эшләп тора, калын гәүдәле, нечкә тема, иң-иңнәр...*

Хәзер инде чын татарча *станокта эшләү, өстәл янында, табында утыру, партада, компьютер алдында утыру, гармун уйнау, скрипка уйнау, Мәскәү янындагы (тирәсендәге) сугышлар* кебек әйтелмәләр урынына русчадан ялгыш калькалаштырып ясалган формалар *(станок артында эшләү, өстәл артында, парта артында, компьютер артында утыру, гармунда, скрипкада уйнау, Мәскәү астындагы сугышлар)* телебездәге гадәти күренешкә әверелә баралар.

Бүгенге журналист үзенең төп бурычы дип тиешле материалны вакытында әзерләп бирүне саный, үзе иҗат иткән язмасы теленең югары сыйфатлы булырга тиешлеге турында борчылмый, хәер, аннан моны таләп тә итмиләр. Нәтиҗәдә, матбугат битләрендә һәртөрле тупас тел ялгышлары тулып ята.

Шундый кырыс хөкем сүзләре җирлегендә газеталар теленең сүзлек составына караган проблемаларга анализ ясап карыйк.

Беренчедән, сүзләрне аларның үзләренә хас булмаган, башка төрле, ят мәгънәләрдә куллану күренеше тарала бара.

Соңгы вакытларда журналистлар кирәксә-кирәкмәсә, урынлы-урынсыз, дөресме-юкмы икәнлеген исәпкә алмыйча, **җирлек** сүзен куллана башладылар. Ләкин ул татар теленең аңлатмалы сүзлегендә теркәлгән үз мәгънәләрендә кулланылмый. **Җирлек –** *1) җир булу сыйфаты, туфракның уңдырышлылыгы; 2) үсеп утырган яки басып торган әйбер астындагы җир; 3) башка төсләр, бизәкләр аерылып торган төп, нигез төс, фон; 4) нәрсәнең дә булса барлыкка килүендә нигез, чыганак; 5) нинди дә булса бер эш, вакыйга өчен кирәкле шартлар, мөмкинлекләр.*

Абруйлы булып саналган бер республика газетасының соңгы саннарыннан алынган мисалларга күз салыйк: *авыл җирлекләрендә балалар саны кимүе; авыл җирлекләрендә ...укытучылар берничә фән укыта; авыл җирлегендәге кешене... яклау җитми; җирлеккә җиде авыл керә; ...Олы Мәңгәр авыл җирлеге башлыгы...* Бу һәм башка күп санлы шундый сүзтезмәләрдәге **җирлек – җир, авыл** мәгънәсендә кулланыла. Бу урында бер нәрсәне искәртеп китү мөһим. Соңгы берничә елда, рус телендәге **поселение** дип йөртелә торган берничә авылны берләштергән хуҗалыкны татарча **җирлек** дип атый башладылар. Ни өчен җирлек ул? Ни өчен авыллар берләшмәсе, авыл хуҗалыгы, утар һәм башка шундыйрак сүз (исем) түгел? Кемнең башына килде икән **поселение**не **җирлек** дип атау?

Кайсыдыр еллардан башлап берничә буын татар кешеләре иркен кулланып килгән **союз** (Советлар Союзы, Язучылар союзы һ.б.) сүзен **берлек** сүзе белән алмаштырдылар. Кемгә кирәк булды икән бу яңалык? Үзен аклыймы икән бу үзгәреш? Моңа уңай җавап бирү кыен.

Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә **берлек**нең өч төрле мәгънәсе күрсәтелгән: 1) бер сумлык акча; 2) грамматикадагы термин (берлек һәм күплек категорияләре); 3) бердәмлек, оешканлык, тыгыз, ныклы бәйләнеш. **Журналистлар союзы** һәм башка шундый атамалардагы **союз** ул **– берләшмә** мәгънәсендәге сүз. Шулай булгач, халыкка бик мәгълүм **союз**ны аның мәгънәсен дөрес белдерми торган **берлек** сүзе белән алмаштыру кирәкле гамәл булдымы икән?

«Шушы кошлар... җырлый-җырлый, кош балалары үстерделәр. Сыерчык җырларын тыңлап, без дә үстек». Шулай итеп, безнең каләм ияләре сайрар кошларны да җырлата башладылар инде!

«Биектән егылганда, бала күп төрле ***җәрәхәтләр*** *ала. Аның баш миенә, умырткалыгына, эчке органнарына зыян килә».* Текстның эчтәлегеннән күренгәнчә, сүз җәрәхәтләнү (**җәрәхәт** ул **– тәндәге яра**) турында түгел, **имгәнү** турында бара, димәк, *бала бик нык имгәнә* дип әйтергә кирәк иде.

Рус телендәге **ценность** сүзен ялгыш **кыйммәт** дип тәрҗемә итү аркасында матбугат телендә *рухи кыйммәтләр, гаилә кыйммәтләре, тормыш кыйммәте* кебек тәгъбирләр киң таралды. **Кыйммәт** ул – *зур, югары бәяле диган сүз,* ә **ценность –** *бәя, хак, әһәмият, байлык, хәзинә.* Димәк, *рухи кыйммәтләр* түгел, *рухи хәзинәләр, гаилә кыйммәте – гаиләнең әһәмияте, роле һ.б. Тормыш кыйммәте – тормышның (яшәүнең) әһәмияте, мәгънәсе, уңай, мөһим яклары һ.б.* (контекстка карап тиешле сүз сайлап алына).

Спрос, просить сүзләрен ялгыш **сорау** дип тәрҗемә итү аркасында, бу сүзне үзенә хас булмаган мәгънәләрдә куллану очраклары күп. Мәсәлән: *«Яз салкын килсә дә, үсентеләргә **сорау** зур»* (дөресе – …үсентеләргә **ихтыяҗ** зур); *«…сорау булганда тәкъдим итүче табыла»* (…ихтыяҗ булганда…) һ.б.

Рус телендәге **призвать (призывать)** сүзенең төрле мәгънәләре татар телендә **чакыру, өндәү, кушу, тәкъдим итү, теләк белдерү, боеру, хәрби хезмәткә алу** һәм башка кайбер сүзләр белән белдерелә. Ләкин ике тел белән эш итүчеләр, гадәттә, төрле синонимнарның тиешлесен сайлап тормыйлар, башларына беренче килгәннән (төп тәңгәллеге **чакыру** сүзеннән) генә файдаланалар. Мәсәлән: *«Министр берләшергә чакыра»* (Министр берләшергә өнди, куша, кирәк, ди һ.б.); *«Егетләрне армиягә чакыралар»* (дөресе – «…армиягә алалар»); *«А.Песошин эшне кызулатырга чакырды»* (кушты, кирәк, диде һ.б.).

Хәзерге матбугат хезмәткәрләренең сүзләрне бөтенләй нигезсез, көтелмәгән, гадәти булмаган мәгънәләрдә куллана башлаулары нык гаҗәпләндерә. Андый сүзләр шактый. Менә берничәсе: *«Оештыру комитеты рекорд куйганын җиткергәч, Булат бер мәлгә аптырап кала»; «Альтекс» фирмасы фаҗигадә зыян күрүчеләргә ярдәм итәчәген җиткерде»; «Бу хакта ...Ирина Нижельская җиткерде».* Җөмләләрдән күренгәнчә, сүз аларда кемнәрнеңдер кемнәргәдер нәрсәдер турында хәбәр итүе, яңалык әйтүе турында бара, димәк, җөмләләрдәге **җиткерү (җиткергәч, җиткерде)** сүзе **әйтү, хәбәр итү** кебек сүзләр белән алмаштырылырга тиеш.

«Көмеш туйга **бәһасез бүләк**» (мәкалә исеме); «**Бәһасез шәхесләребез** язмышы аркылы… горурланып яшәргә»; «безнең икътисад өчен **бәһасез ресурс**». Бу җөмләләрдәге **бәһасез** сүзен укучы ничек, нәрсә дип аңлый торгандыр: текстның эчтәлегенә караганда, ул русчадагы **бесценный** сүзеннән хәрефкә-хәреф тәрҗемә итеп ясалган һәм **бик кыйммәтле** дигән мәгънәне аңлатырга тиеш булса кирәк. Ләкин ул **бәһасе юк,** димәк, **бер тиенгә тормаслык** дип аңлашыла. Уйламыйча, телгә җиңел карап, русча сүзләрне әйләндереп барып кына эш итү шундый башваткычлар китереп чыгара шул.

Безнең телдә русчадан калькалаштырып ясалган һәм каләм ияләре тарафыннан мәгънәсенә төшенмичә генә кулланыла торган сүзләрнең берсе – **кызганычка каршы.** Ул рус телендәге **к сожалению** дигән кереш сүзнең хәрефкә-хәреф тәрҗемәсе. **Кызганычыка каршы** – составындагы ике сүз үзара табигый мәгънә бәйләнешендә тормаган әйтелмә – оригиналдагы мәгънәне төгәл белдерми. Ул мәгънәне **аяныч, үкенеч(ле)** сүзләре тулырак белдерә. Шуның өстенә, әлеге әйтелмә, гадәттә, текстның эчтәлеген төзүдә җитди роль уйнамый: аны күп очракларда төшереп калдырсаң да, сөйләмгә сизелерлек зыян килми. **К сожалению** мәгънәсе кирәк дип табылган очракта, татар телендә аны белдерерлек башка – тел өчен кулайрак, табигыйрак чаралар да бар, аларны куллана белергә генә кирәк. Мәсәлән, рус телендәге «к сожалению, забыл» дигән әйтелмәнең мәгънәсен безнең телдә «онытканмын шул; гөнаһ шомлыгы, онытканмын бит!» кебегрәк тәгъбирләр белән белдерергә мөмкин.

Татар матбугатында яңа сүзләр ясап куллану гадәткә кереп бара. Әгәр дә алар табигый сүз ясалышы кагыйдәләре буенча ясалып, тиешле мәгънәне ачык, төгәл итеп белдерсәләр, моннан зыян булмас иде. Ләкин алар, нигездә, киресенчә, уңышсыз, ялгыш ясалган лексик берәмлекләрне тәшкил итәләр һәм туган телне бозуга, чүпләүгә генә китерәләр.

Ахыры киләсе санда ■

Алмания безне алкышлады*

Камил Саттаров

Алманиядәге беренче концерт Мальхау шәһәрендә булды. Сәхнәдә – чәчәкләр, урак һәм чүкеч эмблемасы, кызыл материалга «СССР төзелүгә 50 ел» дип язылган. Һәрберебез бик нык дулкынлана. Без, күп милләтле илебезнең вәкилләре, шушы чыгышыбыз белән немецларга мәдәният буенча нинди баскычка күтәрелүебезне исбатларга тиеш. Акрын гына пәрдә ачыла. Халык бию ансамбле «Яшьлек» дигән лирик татар биюен башкара. Егет-кызларыбызның дәртле биюләре, искиткеч киемнәре, тирән хисле музыкабыз немец тамашачылары күңелен беренче минутта ук сихерләде. Финал биюен барлык тамашачы аягүрә басып карады һәм көчле алкышлар белән бүләкләде. «Зур рәхмәт!», «Тагын килегез!» дигән сүзләрне ишетү һәрберебез өчен дә күңелле булды.

Веретенвальде һәм Франкфурт шәһәрләрендә үткәрелгән концертлар аеруча истәлекле булды. Безнең коллективка Франкфурт шәһәренең истәлекле медален тапшырдылар. Моңарчы мондый медаль белән СССРның бары тик ике генә вәкиле – Святослав Рихтер белән Давид Ойстрах кына бүләкләнгән булган.

ГДРда барлыгы 28 концерт бирдек. Концертлар мәдәният учакларында да, мәктәп һәм гимназия сәхнәләрендә дә барды. Заллар тамашачы белән тулы булды һәм искиткеч җылы кабул ителде. Шулар арасында Шверин шәһәрендә булган концертны ассызыклап китми булдыра алмыйм. Немец дуслар: «Чыгышны карарга безнең шәһәрдә урнашкан совет солдатлары да киләчәк, бу аларга зур шатлык һәм бүләк булачак», – диделәр. Чыннан да, концерт башланырга сәгать ярым чамасы вакыт калганда, үзенең солдатларын ияртеп, Советлар Союзы Герое Никифор Григорьевич Большаков килеп, минем белән танышты:

– Беләсезме, иптәш Саттаров, 1945 елны дивизиядә күпчелеге татарлардан торган сугышчылар белән Шверин шәһәрен фашистлардан азат иттек. Хәзер дә СССР Оборона министрлыгына, миңа хезмәт итәргә татарларны күбрәк җибәрегез, дим. Чөнки сезнең халык тәртипле, сүз тыңлаучан, өлкәннәргә хөрмәт белән караучан, тырыш һәм талантлы. Менә бүгенге бәйрәмгә килер өчен дивизиямдә хезмәт иткән барлык татар егетләренә бер тәүлек ял бирдем. Алар, мунча кереп, парадный киемнәргә ак якалар тектереп, шушы бәйрәмгә ашкынып, сезнең талантлы чыгышыгызны карарга килде. Бу солдатларга зур шатлык булсын! Иптәш Саттаров, без нигә сәгать ярым алдан килдек дип уйлыйсыз? Чөнки минем егетләрнең сезнең кызлар белән аралашып, серләшеп утырасы килә. Рөхсәт бирерсезме икән?

– Иптәш полковник, хәзер фикерләрен белеп чыгам, – дидем.

Алар «урра» кычкырып риза булдылар. Мин чыктым да:

– Ишеттегезме, иптәш полковник, бөтенесе «урра» кычкырып риза булды, – дидем.

Буфетлар эшләп торды, зал да шыгрым тулы. Икенче кыңгыраудан соң, без үз урыннарыбызга утыра башладык. Җитәкчеләр төркеме беренче рәттә урын алды.

* 1972 елда Камил Саттаров җитәкчелегендәге бер төркем сәнгать әһелләре Германия Демократик Республикасына бара. Төркемне туплау һәм иҗатчыларның юлда күргәннәре турында авторның журналыбызның 4 нче санында (2021 ел) басылган «Алманиягә сәфәр» исемле истәлек-язмасыннан укып белергә мөмкин.

Beifallsstürme im Bad Doberaner Kulturhaus

Volkskunst aus Kasan

In der langen Reihe der sowjetischen Volkskunstensembles, die bisher in unserem Kreis gastierten, nehmen die tatarischen Volkskünstler mit ihren wirbelnden Tänzen, der flotten Musik und dem begeisternden Gesang am Montagabend im Bad Doberaner Stadtkulturhaus einen würdigen Platz ein. Und wenn man weiß, daß die Mitglieder des Tanzensembles „Junost“ (das bedeutet Jugend) des Kulturpalastes „X. Jahrestag der Tatarischen ASSR“, des Volksgesangsensembles „Ssas“ des Klubs „W. W. Kuybischew“ und des Instrumentalensembles „Surprise“ aus Kasan, der Hauptstadt der Tatarischen ASSR, fast durchweg Laienkünstler sind, so ist ihre Leistung um so höher einzuschätzen.

Temperamentvolle Tänze in farbenprächtigen Kostümen – das Auge des Zuschauers war fast überfordert, wenn das gesamte Tanzensemble auf der Bühne seine tollen Wirbel entfachte. Begeisterungsstürme erzwangen manch Dacapo, und die 100 Minuten echter sowjetischer Volkskunst vergingen wie im Fluge.

Die Tanzszene „Das Geschenk" (unser Foto oben) sollte die tiefe Liebe der Tataren zu Lenin ausdrücken – das Mitgehen des Publikums bewies, daß die Tänzerinnen diese Aufgabe glänzend erfüllten. Bewundernswert war auch das Können (und die Kondition !) der Tänzer des Ensembles, auf dem Foto links. Wie alle Mitwirkenden sind auch sie zumeist Studenten aus Kasan.

Fotos: Marquardt

Lokalredaktion 256 Bad Doberan, Aug.-Bebel-Straße 6, Fernruf 23 66. Leiter der Lokalredaktion: Hans Marquardt. Redakteure: Manfred Bork, Regina Mattern.
Alleinige Anzeigen-Annahme: DEWAG-Werbung 25 Rostock, Waldemarstr. 20a, mit allen Zweig- und Annahmestellen im Bezirk. Gültige Anzeigen-Preisliste Nr. 10 der „Ostsee-Zeitung“.
Zuständig für Anzeigenaufträge ausländischer Auftraggeber: Interwerbung.

Казан артистларының ГДРдагы «Ostsee-Zeitung» газетасында басылган фотолары. 1972 ел

Уң ягымда – Вальтер Кунце һәм шәһәр җитәкчеләре, сул ягымда – тылмач Наташа, ә аның янында – чандыр гына, бик пөхтә киенгән һәм нечкә генә мыек җибәргән зыялы бер кеше. Аннан соң үзенең кызы һәм тормыш иптәше белән полковник. Безнең арттагы рәтләрдә – Шверин шәһәренең гарнизонында хезмәт иткән якташларыбыз – татар егетләре.

Миңа чит булган әфәнде, кулына программаны алып: «Салих Сәйдәшевнең «Совет Татарстаны» маршы Бөтендөнья маршлары арасында бик эчтәлекле. Матур мелизмасы буенча ничәнче урында торганын беләсеңме икән?» – дип сорады.

Мин:

– Найн! – дидем.

Ул:

– Бишенче урында! – диде.

Мин уйга калдым. «Бездән бик ерактагы Шверин шәһәрендә яшәүче бу кеше халкыбызның яраткан маршын каян белә икән?» – дип Наташадан сорадым. Наташа: «Ул – Шверин консерваториясенең профессоры. Әле күптән түгел генә дөнья маршлары буенча докторлык диссертациясен яклады. Шуңа күрә Сәйдәш маршы аңа билгеле», – диде. Мин немец профессорына маршны ошатып, бик зур бәя биргәне өчен чиксез рәхмәтемне белдердем. Түземсезлек белән баянчыларның маршны башкаруын көтә башладык. Концертны алып баручы маршның исемен һәм кемнәр башкаруын атап чыкты. Сәхнәгә Рәфкать Гомәров, Ильяс Шәрипов һәм Таһир Сөләйманов чыгып басты. Аларда бик сыйфатлы концерт баяннары. Тынлык. Егетләр әкрен генә маршны уйный башлады. Профессор, сәхнәгә очып менеп, баянчыларның һәрберсен кочаклап алырдай булып талпына иде. Аларның башкару осталыклары профессиональ дәрәҗәдә югары! Баянчыларыбыз уйнап бетергәч, залдагы тамашачылар, басып: «Very good!» – дип алкышлады. Профессор, егетләр янына килеп, маршны тагын бер мәртәбә уйнауларын үтенде.

Немец дусларга фольклор биюләребез дә бик ошады. Алар арасында иң җылы каршы алынганы Габдулла Тукайның «Таз малай» әсәре буенча куелган хореографик композиция иде. Аны ансамбльдәге егетләр составы башкара. Сәхнәдәге шәкертләр кечкенә генә намазлыкларда утыра. Сәдака җыярга казый керә һәм, һәрберсе янына килеп, акча ала. Бай малайлары кесәләреннән чыгарып бирәләр. Иң азактагы малай янына килеп җиткәч, аңа кулын суза, ә тегесе акчасы юклыгын белдерә. Казый, йөгереп барып, тал чыбыгын ала да таз малайны уртага чакыра. Шәкерт, иске намазлыгын астына салып, күрсәткән урынга барып ята. Казый каты гына селтәнеп бер суга, аркадан ниндидер ят тавыш ишетелә. Икенче сукканда да шундый ук тавыш. Казый өченче тапкыр суга да, малайны тиргәп, чыгып китә. Таз малай, казыйны алдый алганына шатланып, аркасыннан тимер поднос чыгара. Немец тамашачыларының мондый галәмәтне күргәне булмаган, ахрысы: егыла-егыла шаркылдап көләләр. Бу композицияне башкарган егетләрнең һәрберсе профессиональ дәрәҗәдә уйный. Шуңа күрә немец дуслар талантлы яшьләребезгә бик яхшы бәя биреп, алдагы концерт номерын әйтергә дә ирек куймыйча, аларны сәхнәгә кабат-кабат чыгара. Гомумән, «Яшьлек» ансамбленең милли биюләре алкышларга күмелә.

Алар арасында дусларыбызга бик ошаган тагын бер юмористик биюне әйтми китә алмыйм. Ул «Черт и монашка» дип атала. Аны иң оста, әйдәп баручы биючеләр Рамил Гайнуллин белән Дамира Шәйдуллина башкарды. Җен бик яшь монашканы чишендерергә бөтен көчен куя. Тегесе теше-тырнагы белән җеннең бу уена каршы килә. Җен дә бирешми, кыз алдында төрле хәйләләр кора, койрыгын болгап ала. Бик озак тырышканнан соң, монашка бер киемен салып ыргыта, бии-бии, икенчесен, өченчесен сала. Бию бик кызу темпта бара. Ахырда монашка, бөтен киемнәрен салып, пляжда ята торган формадан кала. Җен белән кочаклашып, рәхәтләнеп биеп китәләр. Монда инде тамашачы дусларыбыз егыла-егыла көлмичә булдыра алмыйлар.

Алга таба бик талантлы баянчы, музыкант, хормейстер Рәфкать Гомәров җитәкләгән «Саз» ансамбле турында искә алып, шуны әйтәсем килә: коллективтагы кызлар һәр җырны оста башкарулары белән аерылып торды. Рәфкатьнең хор белән эшләве яңа методика нигезендә, үзенчәлекле стильдә иде. Кызларга немец телендәге бик популяр җырларны да өйрәтте ул. Аларны башкарганда, тамашачылар кызларга кушылып, аягүрә басып, бергә җырлады, соңыннан: «Very good!», «Спасибо!» – дип, алкышларга күмделәр.

Җиденче ноябрьдә булачак концертыбызны дусларыбыз ГДРдагы иң матур шәһәрләрнең берсе Ростокка билгеләгән иде. Вальтер Кунце мине шәһәрдә совет солдатлары һәм офицерлары җирләнгән зиратка алып барды. Шунда шәһәр уртасындагы зиратның чисталыгына, матурлыгына таң калдым. Һәр кабердә ак мәрмәрдән ясалган таш һәм алар чәчәкләргә күмелгән иде. Мин, кемнәр җирләнгәнен белер өчен, зират буйлап атлап киттем. Һәр ташта мәрхүмнәрнең исем-фамилиясе, туган һәм үлгән еллары алтын хәрефләр белән язылган. Аларның барысы да сугыш беткәч, 1945 елның июнь-декабрь айларында һәм 1946-1947 нче елларда вафат булганын белдем. Араларында ватандашларым, милләттәшләрем дә күп булып чыкты. Кисәк кенә күз алдыма Мирсәй Әмирнең үзем куйган «Тормыш җыры» спектаклендәге Басыйрның яраткан хатыны Фатыйманың (аны талантлы артисткабыз Фидания Сәлахова башкарды), ире үлү хәбәрен ишеткәч: «Сугыш беткәч, сугыш беткәч бит!» – дип өзгәләнеп, үксеп-үксеп елавы килеп басты. Мондый хәлләрнең чыннан да булганлыгын, дөреслеген әлеге зират янә бер дәлилләде.

Без ГДР шәһәрләре, музейлары, архитектура үрнәкләре, спорт сарайлары һәм Икенче бөтендөнья сугышының кара шәүләсе булып калган концлагерьлар белән

Артистларыбыз ГДР сәхнәсендә

таныштык. Менә алар арасында яманаты чыккан «Равенсбрюк» хатын-кызлар концлагере. Монда фашистлар 92 мең хатын-кызны һәм бала-чаганы газаплап үтергән. 60 мең кеше ачтан һәм төрле эпидемиядән һәлак булган. Үз күзләребез белән газ камераларын һәм крематорий мичләрен күрдек. Һәрберебезнең тамак төбенә төер тыгылды. Без, аеруча сугыштан соң туган буын, фашистлар турында укып һәм ишетеп кенә беләбез. Алмания җирендә әти-әниләребез, абый-апаларыбыз батырлыгы алдында ихтирам белән тагын бер тапкыр баш идек. Алар дөньяны фашист чумасыннан коткарды, илебез азатлыгын саклап калды, безгә укырга, эшләргә һәм иҗат итәргә мөмкинлек бирде. Мондый мәхшәрне безгә һәм киләчәк буынга Ходай башка күрсәтмәсен иде.

Цизендорф авыл хуҗалыгы кооперативында да безне җылы каршы алдылар. Аның рәисе – СССРда берничә тапкыр булган, рус телендә дә ярыйсы гына аңлаша торган, энергияле, тырыш, 30-35 яшьләр тирәсендәге җитәкче. Биредәге сыер фермаларының чисталыгына, мөгезле эре терлекнең тазалыгына сокланып карадык. Цизендорф бистәсендә бөтен йортлар да ике катлы, аның эчендә барлык уңайлыклар да булдырылган.

Ял итеп, кооперативның мәдәният йортына җыелгач, мәктәп укучылары муеныбызга зәңгәр галстуклар бәйләде. Шулай итеп, без илебезгә ГДР пионерлары булып кайттык. Клуб эчендә кафе төзелгән. Немецлар шунда кичке ашны ашап, концертыбызны карап, җырлап-биеп, матур бәйрәм ясады. Җитәкче буларак, җылы каршы алганнары өчен, хуҗаларга олы рәхмәтемне белдердем. Рәфкать Гомәров аларга «Саз» кызлары башкаруында немец телендә бик матур җыр багышлады. Залдагы тамашачы, кушылып җырлап, безне кабат сөендерде.

Без, саубуллашып, рәхмәтебезне әйтеп, кунакханәгә кайтып киттек. Автобуска утыргач, артистларым: «Урра, иртәгә ял итәбез! Туйганчы йоклап, кибетләрдән күчтәнәчләр алып, чит ил мунчасында рәхәтләнәбез!» – дип кычкырып җибәрделәр. Әмма кичке унынчы яртыда берәү ишек шакыды... Карасам, бик матур хәрби формадан подполковник басып тора иде:

– Концерт труппасының җитәкчесе Сез буласызмы? Безнең гарнизонда бик күп татар хезмәт итә. Алар сезнең уңышлар турында немец газеталарыннан укып сөенә. Без беләбез: иртәгә сезнең ял көне. Шуңа күрә татар солдатлары: «Якташларыбыз янына барып, үтенечебезне җиткерегез әле. Алар гарнизонга бер-ике сәгать концерт күрсәтә алмаслар микән? Туган илгә кайткан кебек булыр идек», – диделәр.

– Иптәш подполковник, мин моны үзем генә хәл итә алмыйм. Коллективның фикерен белергә кирәк, – дип, үземә төркем җитәкчеләрен чакырдым. Алар, берсүзсез, барырга риза булуларын, тик менә Германия күчтәнәчләрен алырга вакыт җитмәвенә борчылуларын белдерделәр.

Подполковник, үзенең җитәкчесе белән киңәшеп:

– Килсеннәр генә! Ял көне булуга карамастан, гарнизондагы бөтен кибетләрне ачтырам, алырга теләгән товарларга 25 процент ташлама да ясатам, – диде.

Без икенче көнне ике сәгатьтән гарнизон капкасына килеп җиттек. Дежур солдатлар елмаеп каршы алды. Кибетләре бик бай иде. Кирәкле барлык әйберләрне дә алдык. Мәдәният йорты шактый зур, концертны, гадәттәгечә, татар биюе белән ачтык. Программа, инде күп мәртәбә күрсәтелгәнгә, яхшы темп, ритмда барды. Сәхнәгә төрле үтенечләр килә башлады: «Мин – Актаныш районыннан. Актанышка багышланган җырны башкарыгыз әле...» Әнә шундый эчтәлектәге язмалар Арча, Мөслим, Сарман һәм Апас районнарыннан булган якташларыбыздан бертуктаусыз явып торды. Рәфкать миңа: «Камил абый, нишлибез?» – дигән язма җибәрде. Мин, «Саз» кызларының барысы да, бәлки, Мөслим, Апаска багышланган җырларны белеп бетерми торганнардыр дип уйлап: «Арча» – ике куплет, «Сарман» – ике куплет», – дигән кыска хәбәрне җибәрдем. Рәфкать монда да үзенең тырышлыгын, тәгәллеген күрсәткән, күрәсең, кызларын сәхнә артына чакырып, вакытын да табып, репетиция ясарга да өлгергән. Алып баручы сәхнәгә «Саз» ансамблен чакыргач, кызлар «Сарман»ны, ә аннары «Арча»ны җырлады. Хезмәт иткән татар егетләре кызларга кушылып, бергәләп җырлап бетерде. Алкышлар бик озакка сузылды. Гарнизон җитәкчесе дә: «Молодцы, татары!» – дип, каты гына кул чапты. Милләттәш егетләребез, безнең янга килеп: «Бик әйбәт концерт программасы әзерләп килгәнсез, рәхмәт сезгә! Йөзгә кызыллык китермәдегез. Кайткач, безнең яхшы гына хезмәт итүебезне, алдынгы сафларда булуыбызны массакүләм мәгълүмат чаралары аркылы туганнарыбызга, дусларыбызга һәм республикабызда яшәгән барлык халыкка җиткерсәгезче. Бәлки әле, туган илебездә дә очрашырга туры килер», – дип, хәерле юл теләделәр.

Китәсе көн дә килеп җитте. Шушы арада туганлашып беткән дусларыбыз: Вальтер Кунце, тылмачыбыз Наташа, автобус шоферы Роланд безне Берлинга алып китте. Безне «ГДР-СССР дуслыгы» йортында җитәкчеләр көтеп тора иде. Алар сәнгать коллективларын киләсе елда Берлинда узачак XI халыкара яшьләр фестиваленә чакырды. Олы рәхмәтләрен белдереп, һәрберебезгә зур пакетка салынган сувенирлар һәм ике тәүлеккә җитәрлек тәмле ризыклар бирделәр. Без, кочаклашып, дуслашып, аларны Казаныбызга чакырып, Берлинда тагын очрашуларны өмет итеп, вагонга кереп утырдык. Поезд кузгалып китте, немецлар кул болгап, елмаеп озатып калды. Алмания җиреннән чыкканда, баянчыларыбызга: «Әйдәгез әле, моңлы татар җыры белән юлны дәвам итик!» – дидем. Алар «Авыл көен» уйнап җибәрде.

***

Яраткан шәһәребез Казан безне немец профессоры искиткеч зур бәя биргән, халкыбызның даһи композиторы Салих Сәйдәшевнең «Кызыл Армия маршы» белән каршы алды. Без бәхетле идек. Әйе, бик бәхетле! ■

ФАТЫЙХ ӘКРАМ УЛЫ КОЛБАРИСОВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Аллаһ колының варисы

Әхтәм Зарипов

Фатыйх Колбарисов

Театрда эшләп, җуелмас эз калдырган артистларны искә төшергәндә, аларны сәхнә образлары аша хәтерлим.

Әйтик, Хөсәен ага Уразиков. Ул минем хәтердә «Зәңгәр шәл» спектаклендәге Ишан хәзрәт, «Хуҗа Насретдин» спектаклендәге Колый Тархан образларында җанлана. Гөлсем апа Камскаяны «Зифа» спектаклендәге Кәләмзәсе, «Татар хатыны ниләр күрми»дәге каенанасы белән хәтерлим.

Саный китсәң, Камал театрының инде күптән мәрхүм булган һәр артисты тудырган онытылмас образлар аларның театрыбыз тарихында маяк булуына шаһит.

Язмам шул якты маякларның – каһарман шәхесләрнең берсе Фатыйх Колбарисов хакында.

Фатыйх абый фамилиясен шәрехләгәндә «Колбарис» – «кол», Аллаһ колы булуны күрсәтсә, «варис» дигәне өстәлгәч, «Аллаһ колының варисы» булып чыга түгелме?

Гәрчә, минем белүемчә, Фатыйх абыйга коллык төшенчәсе, гомумән, ят. Ул һәрчак, һәркайда үзен ирекле тоткан шәхес буларак күңелләрдә саклана.

Фатыйх абый, 9 яшеннән Казан каласына килеп, абыйсы Зәки Әкрамович гаиләсендә тәрбияләнә. (Зәки Әкрамович республиканың бердәнбер тукыма фабрикасы директоры буларак танылган шәхес.)

Фатыйх абый Казанның мәшһүр 18 нче мәктәбендә укый. Ә 16 яшендә инде ярдәмче состав артисты булып театрда эшли башлый. 1939-1941 нче елларда театр оештырган студиядә Зәйни Солтанов, Касыйм Шамил, Хөсәен Уразиков кебек талантлардан сабак ала. Ул 1981 елга кадәр, ягъни 40 ел буе Академия театрында эшләп, дистәләрчә образлар тудырган оригиналь талантлы артист буларак танылa. Аны алыштырырлык амплуадагы башка артист булмады һәм булмастыр да. Кешене алыштырып булса да, шәхесне алыштырып булмый бит. Фатыйх абый шәхес иде. Аның уенын күргән тамашачылар хәтерендә ул алыштыргысыз талант иясе буларак сакланыр дип ышанам.

Фатыйх абый үзе сорап, әрсезләнеп рольләр алган артист түгел, ни бирсәләр, шуңа ризалашып эшләүче тыйнак, гадел иҗатчы иде. Театрда артист булып эшләгәндә, мин радиода режиссер вазыйфаларын да башкаргач, тапшыруларны тасмага яздырганда, Фатыйх абыйны диктор буларак чакыра идек. Аның дикциясе әйбәт, тавышы көр һәм чиста булуы өстенә, язмадагы җитешсезлекләрне үзе төзәтеп, сызасын сызып, җитмәгәнен өстәп, текстның камил яңгырашына ирешә иде.

Артист булудан тыш, ул тәрҗемә эшләрендә дә осталыгын күрсәтте. Фатыйх абый тәрҗемә иткән пьесалар буенча спектакльләр куелып, аларның театр репертуарын баетуы факт. Бу язмамда Фатыйх Әкрам улының тәрҗемә өлкәсендәге эшләренә дә, уйнаган рольләренең үзенчәлегенә дә игътибарымны юнәлтмим. (Андый эшләрнең үз осталары бар.) «Җилкәнсезләр» спектаклендә башкарган роле өчен беренчеләрдән булып Тукай премиясенә лаек булуы гына да күп нәрсә турында сөйли. Тукай премиясенә аның бөтен иҗаты лаек. Әйе, Фатыйх абый Тукай премиясе алган беренче артистлар төркеменнән иң лаеклысы.

Бу факт кына аңа тәнкыйтьчеләрнең игътибарлы булуын күрсәтми. Фатыйх абый хакында язма истәлекләр күп түгел.

Ул – озак еллар шул премиясе белән генә юанып, званиесез иҗат итүгә дучар булган артист. Бу хәлнең сәбәпләренә тукталмыйча язмамны дәвам иткәндә, Фатыйх Әкрам улының ихлас, чиста күңелле, тыйнак артист булуы – аның төп сыйфатларыннан. Әгәр ике артист очрашып сөйләшә икән, бүген алар кимендә өченче бер артистның гайбәтен «саталар». Имеш, ул званиегә лаек түгел, уйнаган рольләре төссез.

Фатыйх абыйга андый сөйләшүләр гайре табигый. Ул кеше шатлыгына ихлас сөенүче киң күңелле шәхес иде. Кемдер аны сүзе белән рәнҗетсә дә, ул аңа ачу сакламады, үч алуны белмәде. Әмма яратмаган кешесе белән әңгәмә корудан кача иде.

1964 елны Фрунзе шәһәренә гастрольләргә баргач, кунакханәдә Фатыйх Әкрам улын Габдулла абый Фәтхуллин белән бер номерга урнаштыралар. Гастрольләрнең ничәнче кичендә булуын хәтерләмим, Фатыйх Әкрам улының спектакле юк, ә Габдулла абыйның «Татар хатыны ниләр күрми» спектаклендә уйнаган киче.

Сәгать төнге 12ләр тирәсендә, Дунаев белән мин инде ятарга әзерләнгәндә, күрше бүлмәдә кычкырышкан тавышлар ишетелде. Габдулла абый тавышы иде бу. Аңа җавап биргәндәй, Фатыйх Әкрам улы нидер әйтеп куя. Шулай ничәдер минут әйтешүдән соң, тавыш тынды һәм безнең номерга Фатыйх абый килеп керде. Аптыраштык. Ул сөйләгәннәрдән без шуны аңладык: Фатыйх Әкрам улы йокларга яткан.

«Бәйрәм кичендә» (Эдуардо де Филиппо) спектакленнән бер күренеш. Ненилло – Әзһәр Шакиров, Паскуалино – Фатыйх Колбарисов, Лука Купьелло – Габдулла Шамуков. 1966 ел

Шул чакта Габдулла абый кайтып керә дә, ашарга утырыр алдыннан чемоданын ачып, яртылаш бушаган аракы шешәсен чыгара.

Фатыйх Әкрам улы исә барысын да күреп ята. Габдулла абый, бутылкасын ачып, стаканга 100 граммлап аракы сала да, шешәсен, кабат сөлге белән төреп, чемоданына яшергәч, ашарга утыра.

Фатыйх Әкрам улы түзми, Габдулла абыйга: «Кемнән яшерәсең, мин синекен үзең салып бирсәң дә эчмим», – ди. Габдулла абыйга шул сүз җитә кала: «Мин салганны көтмәгәнсең, үзең салып эчкәнлегеңне телең көрмәлүе әйтеп тора», – дип гаепли. Берсеннән икенчесе уздырып әйтешү башлана. Икесе дә тынычлангандай була. Бераздан, ишек шакып, Фатыйх Әкрам улы безгә килеп керә дә Дунаевка акча суза:

– Бар, Дунай, бер ярты табып кайт, теге крокодилның авызын каплыйм… Казаннан алып килгән аракысын эчүдә мине гаепли.

– Магазиннар бикле, каян алыйм мин аны? – ди Дунай.

– Ресторанннан ал.

– Сәгатеңә кара.

– Бикле булса, каравылчыдан алырсың. Аларда запас булмый калмас.

– Синең бу акчаңа ярты түгел, чирекне дә бирмиләр ич, Фатыйх Әкрамович.

– Алайса, мә, тагын шуның кадәр.

– Кунакханәдән чыгармасалар?

– Теге чакта сөйләшкәч чыгарганнар иде бит. Аңлатырсың, чыгарырлар.

– Кертмәсәләр?

– Үзем төшеп сөйләшермен.

– Баш ватмагыз. Акчаны тәрәзәдән генә ташлагыз да, простыняны простыняга ялгап, бутылканы күтәреп алырбыз, – дидем, сөйләшүгә катнашып. Шуннан соң, тәрәзәдән каравылчыны чакырып, акчаны ташладык та простыняларны ялгарга керештек. Булды дигәндә генә, каравылчы кычкырды:

– Акчагызны ташлагыз, – ди.

– Ташлаганы ике шешәлек бит! Санап кара!

Шуннан соң Дунай кунакханәгә керергә рөхсәт иткән язуын алды да тиз-тиз каравылчы янына төшеп китте. Фатыйх Әкрам улы, аны озаткач, дежур янында көтеп торырга булды. Мин, тәрәзәдән карап, каравылчыны сөйләштереп тордым. Дунаев аның янына килгәч, шешәне күрсәтүне сорады. Ә каравылчы һаман бер сүзне кабатлады: «Акча!»

Дунаев түзмәде – каравылчыны урыныннан кыймылдатты да, кәгазьгә төргән акчаны аяк астыннан кулына алып, бутылканы простыняга бәйләгәч, безгә аны күтәрергә боерды. Күтәрдек.

«Соңгы корбан» (А.Островский) спектакленнән бер күренеш. Флор Федулин – Фуат Халитов, Глафира – Фатыйма Ильская, Ирина – Хәлимә Искәндәрова, Лавр Мироныч – Фатыйх Колбарисов. 1968 ел

Шуннан соң ни булганы язмый гына аңлашылса да, икенче көнне, Габдулла абыйның зарлануы буенча, җыелышта Фатыйх Әкрам улына «Кунакханәнең эчке тәртип кагыйдәләрен үтәмәгәне өчен» шелтә белдереп, башка эчмәскә сүз бирүен сорыйлар. Фатыйх абый, мөмкин булганча үзен тыныч тотарга тырышып, сүз әйтер өчен торып баса да, Габдулла абыйга карап: «Рәхмәт сиңа, Габдулла, мине акылга утырту өчен тырышуыңа. Ләкин мин эчмәскә дип түгел, Габдулла Фәтхуллин белән бер номерга кермәскә, аның белән эчмәскә дип кенә сүз бирәм.

Дөресен әйткәндә, ул кичне мин яртының 150 граммын гына эчеп, калганын Габдуллага салып бирдем. Баш тартмады. Эчте дә мине гаепләп акырына башлады. Янәсе, мин аны исертеп, репетициягә соңлатмакчымын. Ә мин соңламадым, бармадым гына. Шуның өчен, үкенеп, гафу үтенәм. Иптәшләрдән. Гаеплемен», – ди.

Фатыйх Әкрам улы гаҗәеп дәрәҗәдә ихлас, саф күңелле, юмарт кеше иде.

Габдулла абый белән Фатыйх Әкрам улы арасында булып узган бу конфликттан соң без, яшьләр, аларны татулашмас дип фаразлап, нык ялгышканбыз.

Фрунзе шәһәрендәге гастрольләрдән соң, театрыбыз Ташкентка юл тотты. Поездда барганда без аларның бер купеда тату баруларына гаҗәпләнсәк, Ташкент кунакханәсендә номерга бергә урнашуларын белгәч, Фатыйх абыйдан: «Татулаштыгызмы?» – дип сораганым хәтердә.

Аның җавабы әле дә онытылмый:

– Кешеләр татулашырга омтылырга тиешләр.

Чын мәгънәсендә туры сүзле, үч тотмас, беркатлы кеше иде мәрхүм.

Ничәнче елда икәнен хәтерләмим, Иделдә боз киткән, кошлар оя хәстәрли башлаган җепшек көн иде. Зарплата алырга чират торабыз. Телләрдә бер генә тема: эш хакының азлыгы.

Фатыйх абый, сүзгә катнашмый басып торды-торды да, акчаны алгач: «Акча, тота белсәң, җитә ул», – дип, чыгуга таба юнәлде. Без, яшьрәкләр, әлбәттә, аның кибеткә таба китәчәгенә шикләнмәдек. Чыгышлый Фатыйх Әкрам улының проходной телефонында сөйләшеп торуына гаҗәпләнеп калуымны күргәч, ул трубкага бер үк сүзне кабатлады да миңа дәште: «Сине көтәм», – диде. Яшермим, шикләнүдән: «Радиода эшем бар», – дип, чыгарга ашыктым. Ягъни качтым.

Фатыйх абый мине куып тотты да: «Син Зыя Мансур дигән шагыйрьне беләсеңме?» – дигән сорау бирде.

Мин белүемне, аның күрше авылдан булуын, җәйләрен әтиләренә үпкә чиреннән дәваланырга кайтып йөрүен, мин унынчы классны бетергәндә, миңа артистлыкка укырга урнашуда ярдәм вәгъдә итүен хәтерләвемне әйттем.

Фатыйх абый сүзем беткәнне дәшми генә тыңлап торды да:

– Ә син беләсеңме, бүген ул, яшәү белән үлем көрәшенең тәмамлануын көтеп, өендә авырып ята, – диде.

– Без барыбыз да шул яшәү белән үлем көрәшенең тәмамлануын көтеп яшибез ич, Фатыйх абый, – дидем мин.

– Остарма, энем, без хәзер шул якташыбыз янына барырга тиешбез.

– Больницагамы?

– Өенә. Ул да Сез яшәгән Комлев урамында яши. Хәзер без, кибеткә кереп, күчтәнәчләр алабыз.

– Күчтәнәч? – дидем мин, ризасызлыгымны белдергәндәй.

– Курыкма, син башка чакта алырсың. Бүген мин алам.

Шуннан соң без, кибеттән күчтәнәчләр алып, Комлев урамына киттек.

Зыя абый, бик бетерешкән булса да, урыныннан торып, өстәл әзерләргә кушты. Балык тотып яр буенда утырганда ярдәм сорап килүемне онытмаган икән. Хатирәләргә бирелеп, озак кына сөйләшеп утырдык. Аерылышу алдыннан мин аннан Довженконың истәлекләр китабыннан бер хикәяне тәрҗемә итүен сорадым. Ул, шатланып, ризалашуын белдерде дә, озакка сузмам, диде. Рәхмәт йөзеннән мин Зыя абыйга беренче очрашуда аның Базы елгасы ярында балык каптыруын төшергән фотосы саклануын әйткәч, шатлануы гомергә онытылмас тәэсир калдырды.

Ләкин миңа ул фотоны аның үз кулына бирү насыйп булмады. Довженко хикәясенең тәрҗемәсен алырга барганда, шагыйрь Зыя Мансурны инде җирләгәннәр булып чыкты.

Бу хәлләр узгач, очрашканда Фатыйх абый гел бер сүзне кабатлый иде:

– Булдыра алганда кешене шатландырырга ашыгырга кирәк, энем. Без гел соңлыйбыз. Соңламас өчен ашыгырга кирәклекне онытабыз.

Зыя Мансур тәрҗемә иткән хикәя буенча фильм төшереп, аны, Җиңү көнен бәйрәм иткәндә, телевизор аша күрсәттек. Хикәянең Зыя абый тәрҗемәсендәге кульъязма нөсхәсе миндә һаман саклана. Шагыйрь анда, үзенә Довженко дигән яңа дөнья ачкан өчен миңа рәхмәтен белдереп, «Яшьлек» вальсының бер куплет текстын язган.

Бу турыда Фатыйх абыйга гаҗәпләнүемне белдергәч, ул миңа шул вальсның икенче куплетын гына җырлады да:

– Аптырама, аның сине шатландырасы килгән. Яңа шигырь язарлык хәле булмагач, иң популяр шул җырын бүләк иткән, – диде.

– Халык җыры ич ул.

– Халыкныкы булып таралган җыр, Зыя Мансур сүзләре.

Шулай итеп, Фатыйх абый миңа шагыйрь Зыя Мансурны ачты:

– Булганны сакламыйбыз, югалткач үкенәбез, – диде.

– Нишләмәк кирәк, кеше гомере шатлыклар һәм үкенечләр белән аралашудан тора, – дидем мин, җавапсыз калмас өчен генә. Фатыйх Әкрам улы «Яшьлек» вальсының тагын бер куплетын җырлады:

«Тиңләр идем шаулап аккан
Язгы ташу суына.
Сулар кибә, яшьлек шаулый,
Шаулый гомер буена».

«Яшьлек шаулый», – дип җырласа да, күңеле белән һаман яшь булса да, Фатыйх абый шау-шулы бер сүз әйтеп кыерсытсалар, биш сүз белән җавап кайтарган кеше түгел иде. Кыерсытуларны сүзсез үткәрмәсә дә, вакланмыйча, бер-ике сүз белән генә җавап бирә иде.

Көнләшә белми, югалтулары булганда зарланмый, табышлары булса, күрсәтеп шатланмый – тиешле, хәләл нәрсә буларак кабул итә.

Татар артистларының алтмышынчы, җитмешенче елларда керем чыганагы буларак куандырган «дубляж» дигән кәсепләре бар иде. Ягъни, русча фильмнарны татарчага тәрҗемә итеп, гонорар эшләү. Бу кәсепкә артистлар бик теләп алынсалар да, аңа һәр артист чакырылмый. Фатыйх абый булмаган дубляжны хәтерләмим.

Гадәттә, бу эш төнлә белән генә эшләнә. Артистлар дубляж авырлыгыннан түгел, йокы килүдән интегә. Тәнәфес булуга, ятып черем итәргә ашыгу гаеп ителми. Фатыйх абый зарланмый да, йокламый да. Көтә, түзә. Дубляж өчен түләүнең ниндидер тарифы юк. Дубляж ясаучы режиссер ничек язса, шулкадәр сумма түләнә. Рольнең зурлыгына, эшнең күләменә карап түгел, кешесенә – артистына, холкына карап бирелә ул. (Роль язылган текстның беренче битендә хакы күрсәтелә.) Бер-береннән шул хакны күреп, сүз чыкмасын өчен, аны ертып ташлыйлар. Фатыйх Әкрам улы ертмый, саклый, чөнки аның, нинди роль дублировать итсә дә, бер үк хак. Кайбер артистның роле бик кечкенә булса да, хакы зур була. Нигә шулай дип кызыксынырга ярамый. Сорамыйча да һәр артист үзе белә; сорасаң, башка чакырылмавың бар. Күз йомасың.

Равил Шәрәфиев дигән мәшһүр иҗатташыбыз күп чакта, «йокы качыру» өчен анекдотлар сөйләп, үзен уяу тотарга тырыша.

Бер төнне ул үзе дә арып йокларга яткан, башка артистлар да кайсы кайда урын тапкан. Бер Фатыйх абый гына «бодрствует», Равилне эзли. Сөйләшер кеше кирәк аңа.

Ниһаять, аны тапса, Равил тәмләп йоклап ята икән. Фатыйх абый өчен бу гайре табигый хәл. Ул аны йокысыннан уята да күзен дә ачмаган Равилгә:

– Син нәрсә, йоклыйсыңмыни? – ди.

Равил куркып кала:

– Чиратым җиттеме? – ди.

Фатыйх абыйның җавабы әзер:

– Уян, барысы да йокыга талганын күр. Көлдерергә кирәк! – ди.

Шул хәлдән соң без Фатыйх Әкрамовичка: «Уян, көлдер», – дип шаярта башладык.

Холкы белән кайчак көлке хәлдә калдырса да, Фатыйх абый кешеләргә шатлык китерерлек гамәлләр генә кылып, яхшы сүзләр сөйләве белән генә хәтердә саклана.

«Намус хөкеме» (Диас Вәлиев) спектакленнән бер күренеш. Равил – Наил Дунаев, Тикшерүче – Фатыйх Колбарисов. 1971 ел

60 яшен дә тутыра алмый бакыйлыкка күчсә дә, Фатыйх Әкрам улы оригиналь холкы белән дә, уйнаган рольләре белән дә аны белгән-күргәннәр күңелендә җуелмас эз калдырган шәхес.

Мин күргән спектакльләрдән иң соңгысы тәрҗемә әсәре буенча куелган «Сукыр» спектаклендәге сукыр роле иде. Бу спектакльнең миндә яхшы тәэсир калдыруын әйткәч, Фатыйх абый, мактау сүзләремне кабул итмичәрәк: «Тормышта барыбызның да сукыр булуыбызны аңламадыңмы?» – дигән фикер әйтте.

Бу аның соңгы роле иде. Шуннан соң ул, авырып, больницага керде. Әнвәр ага Гобәйдуллин белән хәлен белергә баргач, янына аны гына керттеләр. Хәле авыр, диделәр. Авыр булса да, театр эчендәге хәлләр белән кызыксынып, «Казан сөлгесе» дигән яңа спектакльдә аңа роль бирелгәнме икәнлеге турында сораганга: «Юк», – дигән җавап ишеткәч, ул: «Аллага шөкер, дип әйтмим, барыбер картларга кертәчәк», – дигән борчылуын сиздерә.

Картларга түгел, Фатыйх Әкрам улы башка рольләргә дә керә алмады. Больницадан аның җансыз гәүдәсен генә алып кайттылар.

Җирләү мәрасименә Фатыйх абыйның улы Зөфәр дә килгән иде. Әтисенә охшаган мәһабәт сынлы хәрби кеше икән. Әтисез үссә дә, Фатыйх Әкрам улына үпкә тотмаган, сабыр табигатьле егет булып күренде ул. Соңыннан күрешеп сөйләшербез, дисәм дә, аны кабат очрата алмадым. Университетта укытканлыгын ишетсәм дә, очрашу насыйп булмады. Кызганыч.

Фатыйх абыйның улыннан да нәселне дәвам итәрлек бала калмавын сөйләделәр. Хатыны Зәмирә Саликованы Фатыйх абыйдан туган Раушания исемле кызы карый икән дип ишеткән идем, Колбарисов фамилияле бүтән кеше барлыгын өзеп кенә әйтә алмыйм.

Урман төрле агачлар белән генә матур булган кебек, театр да, төрле холыклы, төрле талантлы артистлары булганда гына, тамашачыны спектакльләргә җәлеп итә ала.

Фатыйх Әкрам улы Колбарисов дигән оригиналь холыклы артистның тууына 100 ел тулган бу көннәрдә аны искә алып язарга утыруым аның рухына кылган дога булып ирешсен иде.

Фатыйх Әкрам улы Колбарисов дигән Тукай премиясен беренчеләрдән алган талант иясе бар иде, бер иде.

Зиратта аның кабере өстенә куелган гранит ташка: «Монда артист Фатыйх Колбарисов», – дип язылган. «Артист» сүзенә «шәхес» дигәнне өстәү артык булмас иде. Әйе, ул артист иде. Артист үлми – ул, телләргә, хәтерләргә күчеп, яшәвен дәвам итә. ■

Безнең мирас №5 май 2021

«Җырлаганда... җылата иде»

Филүсә Арслан, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе

Басканнар (сулдан уңга): сеңлесе Роза, Марс, апасы. Утырганнар: әнисе һәм туганнан туган абыйсы. 1961 ел

Танылган композитор, виртуоз баянчы, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Марс Макаров (1939-2016) кечкенәдән күпкырлы сәләткә ия була. Ул виртуоз оста баянчы-башкаручы, композитор гына түгел, шагыйрь һәм журналист та иде әле. Аның иҗаты инде татар сәнгате түрендә күптән үзенең лаеклы урынын алды, халык мәхәббәтен казанды. Ул язган җырлар, музыка әсәрләре репертуардан төшми, һәрдаим башкарылып килә, чөнки аның иҗатына халыкчанлык хас.

Марс Макаров 1939 елның 28 октябрендә Норлат районындагы (элеккеге Биләр районындагы Октябрь колхозына кергән) Чурабатыр авылында дөньяга килә. Ул туып-үскән авылның тирә-ягы – урман. Урманнан бәреп чыккан чишмә-инешләр, шау чәчәкле болын-кырлар кочагында композитор күңелендә илһам чаткылары туа. Марсны әтисеннән калган гармуны белән кышын кечкенә чанага утыртып, Чурабатыр малайлары аулак өйләрдәге кичке уенга йөртәләр. Биш яшеннән гармунчы булып танылган Марс үзеннән өлкәннәрне биетә дә, җырлата да. Ул елларда күңел көр булгач, халык ачлыкка-ялангачлыкка бирешми. Маруся апа (Марсның әнисе) өч баласы язмышын кайгыртып, 1954 елны Казанга килеп, заводка эшкә урнаша. Алар гаиләсе Соцгород бакчасы каршындагы йортның подвалында яши. Шунда торганда, Марс 26 нчы, 89 нчы татар мәктәпләрендә белем ала. Аннары ул музыка училищесын тәмамлый. Ата-бабадан күчкән асыл гадәт – киң күңеллелек Макаровларга бүген дә хас булган асыл сыйфат. Шушы мохиттә үскән Марс композитор һәм шагыйрь булып киткән икән, моның нигезендә Маруся

ападан балаларына – улына һәм кызы Розага, нәселенә күчкән киң күңеллелек ятадыр.

Марсның сеңлесе Роза Андреевна хәтерләве буенча: «Моңлылык Марска әбидән килгән, чөнки ул, җырлаганда, Марс белән мине җылата иде. Әтиебез дә гармунда матур уйный торган булган (әтиләре 1942 елны вафат була – **Ф.А.**). Марсның җырга-моңга, музыкага тартылуы әниемнең җырлавына һәм әтиебезнең гармунда уйнавына бәйле. Авылда яшәгәндә, без оркестрлар оештыра идек: мин – мандолинада, Марс – баянда, әни җырлый, апа кашыклар кагып тора, икетуганыбыз пилада уйный иде. Авылдашларыбыз тәрәз төбенә килеп тыңлый, әнинең җырлавын тыңлап җылыйлар иде. Авыл урман уртасында булгангадыр, кыргый бал күп җыела, авыл картлары да матур озак яшиләр (100 яшькә җитәләр) иде. Авылда гөмбә, җиләк, кыргый кура җиләкләре, карлыган, кыргый алмалар, гөмбә, бал һ.б. ашап үскәнгә, ачтан үлмәгәнбездер. Безнең яшьлек шул авылда узды. Марска – 14, миңа 12 яшь, урысча бер сүз дә белмибез – Казанга килдек. 26 нчы татар мәктәбенә укырга керергә кирәк. Әбинең кызыл яулыгы калган иде, шуны урталай бүлдек тә, пионер галстугы ясадык, янәсе. Мин – 5 нче, Марс 7 нче класста укый. Мәктәп елларында Марс белән икебезнең уен коралларындагы дуэтларны Рафаэль Ильясов яздырып та алды. Марсны сәхнәдә чыгышлар ясаганда күренекле баянчы Рәис Сафиуллин күреп алган һәм аңа укырга киңәш биргән. Марс урта мәктәпне тәмамлагач, ул, безнең өйгә килеп, уен коралларында уйнаганыбызны тыңлап карады. Мин дә гитарада, курайда, мандолинада уйный идем. Икебез дә слухка инде, музыкаль белемебез юк бит. Марсның мәктәптә югары классларда укып йөргән чакларында ук Бату Мөлеков, Ифрат Хисамов белән якыннан аралашуы да аның иҗат юлына бер ныклы этәргеч булды.

Рәис ага Марсны музыка училищесына юллады. Миңа пианино алырга киңәш итте һәм, вакыт үткәч, тыңлатырга Екатерина Соколовага алып китте. Ул, минем бик яхшы ишетү сәләтем барлыгын белеп, үзенең бер укучысының өенә йөрергә киңәш бирде. Өч еллап Е.Соколованың укучысында фортепианода уйнарга өйрәндем. 10 класстан соң бик җиңеллек белән генә, Марс – баянда, мин колагымда яңгырап калган А.Хачатурянның «Кылычлар белән бию»ен слухка уйнап, музфакка укырга кердем...

Күпмедер вакыт подвалда яшәгәннән соң, безгә Белинский урамыннан ике бүлмәле фатир бирделәр (мин йөрдем инде Мәскәүгә, Кремльгә барып хәлне аңлатканнан соң алдык), без аны өч бүлмәле итеп ясадык. Музыка училищесын тәмамлаганнан соң, Марсның тулы җанлы иҗат тормышы башланды. Ул эшли башлагач, И.Шәмсетдинов, А.Ключарев, С.Йосыпов, З.Сәхәбиева белән Х.Бигичев, Н.Теркулова, Нәфисә Василова (Анастасия Васильева) һ.б. бездә күп тапкыр булдылар. Алар, озын-озак утырып, репетиция ясыйлар, Марс аккомпанементлык итә иде. А.Ключарев кебек олпат композиторлар аңа өмет белән карадылар, киләчәктә безгә алмаш килә, дип, аңа ярдәм итеп, юл күрсәттеләр. Марс Андреевич Александр Сергеевичка булган рәхмәтен үзенең «Татарның чын моңсары иде» мәкаләсендә аерым бер җылылык белән белдерә. *«...А.Ключарев бөтен гомерен халык иҗаты белән бәйләде, халык фольклорының бөтен нечкәлеген өйрәнде һәм музыкаль әсәрләрендә бик уңышлы файдалана белде»*, – дип, композиторны халык музыкасы фольклорын җыючыларның атасы дип атый. А.Ключаревның югары профессиональлеге аның өчен үрнәк кенә булып калмыйча, иҗат юлында уңай тайпылыш ясарга да ярдәм итә. «Каз канаты» көенә фантазиясен тыңлагач, А.Ключарев аңа: *«Баян өчен симфония бу»*, – дигән бәя бирә.

Әлеге QR-код аша Марс Макаров җырларын тыңлый аласыз.

Марс шул вакытларда бик күп язмалар эшләде, бу аның иҗатының югары ноктасы булды дия алам», – дип сүзен тәмамлады Роза Андреевна.

Кешеләрне ярату хисе Марс күңелендә җырлар, шигырьләр, симфоник әсәрләр булып тугандыр. Шагыйрьләр, җырчылар, композиторлар табигатьнең иң асыл мизгелләрен көткән гөлләр кебек бит алар. Марс Макаровның Хәсән Туфан сүзләренә язган җырлары аның йөздән артык музыкаль әсәрләре арасында аерым урынны алып тора. «Киек казлар», «Юксындырсаң нишләрем?», «Ай чыга Арча кырыннан», «Без барасы юллар озын», «Барган саен еллар җылырак», «Каеннар көтәләр» дигән җырларын һәм хор өчен язган «Агыла да болыт агыла» әсәрен халкыбыз бик тә үз итте. Марсның якташы Х.Туфан Марстагы истәлек китабына: *«Марс энем, «Киек казлар» кебек күркәм җырларың тагын да өстәлеп торсын»,* – дип язып калдырган булган.

Алтмышынчы, җитмешенче елларда М.Макаров бик күп популяр музыка әсәрләре иҗат итә. Шул чорда 1968 елда ул, Хельсинки университетының төрки телләр галиме Гомәр Таһир чакыруы буенча, фин татарлары белән очрашуда катнаша. Әлеге төркемдә Р.Яхин, И.Шакиров, В.Шәрипова, А.Арсланов, М.Әхмәтов була. Бу вакыйга М.Макаровның ул заманда иң оста виртуоз баянчыларының берсе булуын раслый. Моннан соң Марс тагын да дәртләнебрәк иҗат итә башлый.

Татарстан Республикасының 60 еллык юбилее уңае белән, 1979 елны Татарстанның композиторлар берлеге, Мәдәният министрлыгы Татарстанга багышланган иң яхшы җырга ябык конкурс игълан итә. М.Макаровның хор һәм симфоник оркестр өчен Гамил Афзал сүзләренә язылган «Татарстан таңнары» дигән җыры икенче премиягә лаек була. Аны ТАССРның халык артисты мәшһүр җырчыбыз Фәхри Насретдинов белән Наҗия Теркулова башкарды. М.Макаров, аннан соң да шундый бәйгеләрдә катнашып, призлы урыннар алуга ирешә.

Канатланып иҗат иткән 60 нчы һәм 70 нче еллардан соң да аның берсеннән-берсе матур аһәңлерәк музыкаль әсәрләре туып тора. Шулардан Н.Нәҗми сүзләренә язган «Көзге романс» әсәре, З.Насыйбуллин сүзләренә иҗат ителеп, З.Нурмөхәммәтов башкарган «Кара шәлең килә сөйрәлеп» җыры аналарга багышланган күпсанлы лирик җырлардан яңача ачылышы белән аерылып тора. С.Хәким сүзләренә иҗат ителгән «Ни сөйли урман» әсәре, Тукай поэмасы буенча симфоник оркестр өчен «Су анасы» дигән фантазиясе (аны А.Шутиков оркестры башкарган) һәм ике өлештән торган «Шүрәле» композициясе – милли музыкаль сәнгатебезне баета торган гүзәл әсәрләр. М.Макаров башкорт халык көе «Аксак кола»ны һәм тагын берничә башкорт халык көен баян өчен эшкәртә. Шулай ук «Кәвәл авылы көе», «Минзәлә көе»н – баян өчен, ә концертино һәм фортепиано өчен татар халык көе «Зиләйлүк»не эшкәртә. Тальян өчен «Болгар биюе», «Тальян ритмнары» да тыңлап туймаслык гүзәл әсәрләреннән санала. Шулай ук Ифрат Хисамовның «Бәрәңге», Васил Хәбисламовның «Җиз кыңгырау моңнары», Заһид Хәбибуллинның «Себер татарлары биюе», Исмай Шәмсетдиновның «Биләр яшьләре» һ.б. композиторларның җырларына эшкәртмәләре дә шактый.

Хәзер Марс Макаровның Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә эшләгән елларын искә төшерик: 1960 нчы еллар башында татар баянчылары исемлегенә Марс Макаров дигән исем дә өстәлә. Ул елларда Татарстан радиосы яшь баянчының чыгышларын еш тапшыргалап тора. 1962 елны Казан музыка училищесын тәмамлагач та, шул вакытта Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленә яңа сәнгать җитәкчесе булып килгән Җәүдәт Караматуллович Айдаровның махсус чакыруы буенча, Марс Макаров баянчы булып эшкә кабул ителә. Шулай итеп, ике генә баянчыдан торган ансамбльнең музыкаль төркеме тулылана – баянчылар квартеты

барлыкка килә: Петр Васильев, Илдар Җаббаров, Марс Макаров һәм шулай ук яңа гына Казан музыка училищесын тәмамлаган Нәсих Вильданов.

Композитор Марс Макаров

Югары белемле, тәҗрибәле хор һәм оркестр дирижеры булган ансамбльнең сәнгать җитәкчесе бар көчен ансамбльне талантлы музыкантлар белән тулыландыруга юнәлтә. Аның Мәскәүдә югары белем алган, халык кыллы музыка уен коралларында уйнаучы профессиональ музыкантларны эшкә алуы шуны күрсәтә. 1964 елны 8 кешедән торган музыкаль төркем барлыкка килә. Төркемнең музыка җитәкчесе итеп Марс Макаров билгеләнә.

Марс Макаров ансамбльдә эшләгән елларында, баянчы булып хезмәт кылудан тыш, ансамбльнең хор төркеме өчен халык җырларын эшкәртеп, коллективта мәртәбә һәм хөрмәт казана. Ансамбль концертларын караган тамашачылар да Марс Макаровның хор өчен аранжировкаларын җылы кабул итәләр. М.Макаровның хор өчен эшләнгән «Кәрия-Зәкәрия» дигән «бизәкләве», берничә ел буена ансамбль программасыннан төшмичә башкарылып, зур уңышка ирешә.

Тора-бара аның хор әсәрләре ансамбль тарафыннан башкарылып, радио фондына яздырыла һәм ансамбль программаларына кертелә. Шундыйлардан: «Киек казлар» (Х.Туфан сүз.), «Агыла да болыт агыла» (Х.Туфан сүз.), «Уралым» (Г.Игебаев сүз.), «Туган ил» (Фин татарлары җыры, Н.Исәнбәт сүз.). Соңгы еллардагы хор әсәрләреннән – «Бәхетле булыгыз!» (Р.Миңнуллин сүз.), «Тормыштан суынма син» (Ф.Яруллин сүз.), М.Макаров музыкасына Гай Таһиров куйган «Хәдичә» дигән хореографик күренеш тә игътибарга лаек. Борис Ляпаевның Казан тарихын чагылдырган «Казан турында хикәят» дип исемләнгән зур күләмле музыкаль-хореографик композициясенә кергән «Казанны саклаучы кызлар» биюе (М.Макаров әсәре) һәм шулай ук «Хуҗалар тавы» дигән хор әсәре Җыр һәм бию ансамбленең яңа программасында аеруча уңыш казанды дияргә кирәк.

Монголиядә ансамбль белән гастрольләр вакытында Марс русның мәшһүр артисты Николай Крючков белән дуслаша. Һәм ул аңа баянда Хачатурянның «Кылычлар белән бию»ен уйный. Ә Н.Крючков: «Бу бит баян түгел, тулы оркестр», – дип, соклануын белдерә. Хушлашканда ул, мине туеңа чакыр, дип әйтә. Шуннан соң алар хат язышып торалар. Марс аны туена чакырган, ләкин Н.Крючков, гастрольдә булып, килә алмый кала.

Композиторның халык сүзләренә язылган «Тулпар атым», «Мәк чәчәге», К.Булатова шигыренә иҗат ителгән «Кыңгыраулар»ы, Г.Афзал сүзләренә язылган «Дөнья матур, дөнья киң», Ф.Яруллин шигыренә иҗат ителгән «Тормыштан суынма син», Р.Закиров сүзләренә язылган «Сахраларга ялгыз чык кына», Г.Зәйнәшева шигыренә иҗат ителгән «Минем иркәм биюче» һәм «Ак самавыр», М.Хөсәен

сүзләренә язылган «Иң кадерлем син генә» җырлары да халыкчан булулары белән аерылып тора. Нәфисә Василова (Анастасия Васильева) башкаруындагы «Киек казлар»ы дөньяның теләсә-кайсы кыйтгасында яңгыратырлык. М.Макаровның Р.Гаташ шигыренә иҗат ителгән «Язгы ташу» җырында әлегәчә ишетелмәгән ярсулы дәрт, бәргәләнү сиземләнә, халкыбыздагы басынкылыкны Сәйдәш яңгырашы, заман рухындагы нота күтәреп җибәрә.

Соңгы вакытларда туй мәҗлесләре М.Макаров иҗат иткән темпераментлы бию көйләреннән, тальян өчен «Авыл көе» һәм «Каз канаты» (А.Ключарев аны баян өчен симфония дип йөрткән) җырына фантазиясеннән башка үтми диярлек. Харис Нигъмәтҗанов җитәкчелегендәге халык уен кораллары ансамбле башкаруында М.Макаровның «Туй биюе» әсәрен тыныч кына тыңлап булмый. Х.Нигъмәтҗанов М.Макаров иҗат иткән «Туй биюе»нең музыкаль тәлинкә (пластинка) язмасын да чыгарды. Бу әсәрне мәктәп укучылары музыка дәресләрендә кулланалар. Әлеге көй кешене, нинди милләттән булуына карамастан, битараф калдырмый, ул аны үз милләтенең рухи байлыгы кебек аңлап кабул итә. Бу әсәргә күп кенә коллективлар бию куйды, шулай ук әсәр инструменталь музыка буларак та файдаланыла.

Баян өчен язылган әсәрләренә килгәндә, «Каз канаты» белән беррәттән, «Якташлар биюе», «Вальс-экспромт», «Юмореска» кебек пьесаларын; «Кичке авыл», «Аулак өйдә» әсәрләре эшкәртмәләрен атап китәргә кирәк. ТНВда да аның үз башкаруындагы әсәрләренең видеоязмалары саклана.

Марс Макаровның иҗат уңышлары белән тормыш давыллары чиратлашып бара. Республиканың зур бер җәмгыяте аны Тукай бүләгенә ике тапкыр тәкъдим итте. Тик Композиторлар берлеге әгъзасы булмаганга, теркәп тә тормыйча, аны кире бордылар. Бернишләп тә булмый, чынлыкта тормыш шундый. Халыкка музыкаль әсәрләр тудыра ала торган иҗатчылар кирәк үзе. Әмма яше 70кә җиткән аксакал композиторны, ул консерватория бетермәгән, дип, Композиторлар берлегенә кабул итмәгәннәр. Үз вакытында М.Макаров консерваториянең композиция классына имтиханнар тапшырган. «Синең язган сонатаң юк», – дип, ректор аны кабул иттермәгән. Мин Марсны бөек композиторга тиңләмим, шулай да элеккеге хаталарыбыз бүген Марс Макаров язмышында кабатлана бит, дип яза журналист Рәис Идрисов. Сәйдәшевне да бит: «Ул композитор түгел», – дип әйткәннәр. Бу хәл мәдәниятебездә сальеризм чиренең дәвам итүе турында сөйли.

Шунысын да әйтү урынлы булыр: М.Макаров җырларын М.Булатова, Ф.Насретдинов, И.Шакиров, Г.Ильясов, Х.Бигичев, Н.Теркулова, З.Сәхәбиева, Р.Ибраһимова, Регина Сәйфи һ.б. зур талант ияләре башкарып, үз иҗатларын тагын да баеттылар. Марс Макаров соңгы елларында, композитор һәм шагыйрь буларак, халык арасында иде, музыка мәктәпләрендә очрашуларда еш катнашты. Аерым җырларына сүзләрне үзе язды. «Сахраларга ялгыз чык кына», «Бердәм булыйк» һ.б. җырлары шул нигездә туган.

Әйе, авыр вакытлары күп булды аның. Шул чакларда сеңлесе Роза ханым һәрвакыт рухи яктан да, матди яктан да ярдәм итеп торды. Аның шаһиты буларак, Роза Андреевнага чиксез рәхмәтлемен. М.Макаровта иҗат ялкыны сүнмәгән иде әле, зур планнар белән яши иде. Ул бу дөньядан көтмәгәндә китеп барды. Әгәр аны халыкка якынрак иткән булсалар, илһам килми калмас һәм ул яңа симфоник әсәрләр дә иҗат итә алган булыр иде әле…

2016 елда Татарстан китап нәшриятында М.Макаровның «Кайтаваз» исемле соңгы елларда иҗат иткән шигырьләре, истәлек-хатирәләре һәм җырлары тупланган җыентыгы дөнья күрде. «Шигырьләрне композитор, моң иясе язганлыгы

күренеп тора – алар төзек ритмлы, үз аһәңнәре бар. Теле саф, чишмә кебек челтерәп тора. Иң мөһиме – шигырьләр ясалма түгел, көчәнеп язылмаган. Алар самими, ихлас», – дип бәя бирә шагыйрь Ркаил Зәйдулла. Шигырьләрендә исә берничә тема үзәккә алына: Җир-анага, табигатькә мөнәсәбәт һ.б. Иҗтимагый тормышны, яшәешебезне дә читләтеп үтми Марс Андреевич. Тормыштагы, иҗаттагы каршылыклар да лирик-фәлсәфи шигырьләр тәлгәше буларак бөреләнә.

«Һичбер кем дә мәңге тормый җирдә,
Бар да бетә, бар да югала...
Мин җыр язам сезгә, сүзләр язам –
Кешеләрдән бары җыр кала».

Монысы исә «Нигә моңлы татар?» шигыреннән:

«Тарихчылар җавап эзли:
Каян килгән татарга моң?
Килгәндер гасырлар буе
Милләт кыйналганнан соң...»

Марс Макаровның тагын бер китабы «Сәнгатебез йолдызлары» дип атала. Китап 2011 елда Татарстан китап нәшриятында басылган. Анда әдәбият-сәнгать өлкәсендә дан казанган чын йолдызларыбыз турындагы мәкаләләр, музыка белгечләре, артистлар, баянчылар һ.б. хакында әдәби портретлар, истәлекләр туплап бирелгән. Хәсән Туфан, Александр Ключарев, Хәйдәр Бигичев, Мәсгут Имашев, Гали Ильясов, Ильяс Шәрипов, Ифрат Хисамов, Рәис Сафиуллин, Зиннур Нурмөхәммәтов, Зөһрә Сәхәбиева, Зәки Мәхмүтов, Наҗия Теркулова, Кирам Сатиев, Айрат Арсланов, Раил Сәйфуллин, Ринат Вәлиев, Георгий Ибушев, Айдар Фәйзрахманов, Марат Сираҗетдинов, Харис Нигъмәтҗанов, Шамил Әхмәтҗанов, Рәгъде Халитовлар белән аралашып, дус, иҗатташлар булып яшәгән ул. Бу йолдызларның кайсын гына алсаң да, алар – татар мәдәниятенә зур өлеш керткән шәхесләр. Һәркайсы хакында аерым роман язарлык.

Композиторның сеңлесе Роза Андреевна Макарова, Марс Макаровның вафатыннан соң, радиокомитетка барып, аның 40лап язмасын сорап яздырып (дөресрәге – сатып) алган. Ә күп әйберләре югалган булган, чөнки болганчык үзгәреш чорында радионың да астын-өскә китерделәр. Күлбай Морасадагы Г.Кариев музеенда Марс Макаровка зур урын бирелгән. Шул музейга Роза Марсның ике китабын тапшыра, билгесез рәссам ясаган портретын, икесе дә уйнаган балалайкасын, яздырып алган дискларны да сакларга калдыра. Шулай ук язучылар, шагыйрьләр һ.б. зыялыларның имза белән бүләк итеп биргән китаплары да музейда урын алды.

Марс Макаровның мәгълүм әсәрләре: «Биергә өйрән» (1984, балетмейстер Г.Таһиров белән бергә), «Йөз татар биюе» (1989, балетмейстер Г.Таһиров белән бергә), «Баян өчен пьесалар» (1966, халык көйләре эшкәртмәләре) һ.б.

Әйе, күңелнең иң нечкә кылларын тибрәтерлек аһәңгә ия иде аның әсәрләре. Марс Макаровның иҗат мирасы киләсе буыннарда да яшәр һәм төрле яктан өйрәнелер дигән өметтә калыйк. ■

ТАТАР ҖЫРЧЫЛАРЫ. КАДЕРЛЕ МИЗГЕЛЛӘР



Классик җырчы, Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Эмиль ага Җәләлетдинов – зыялылык, затлылык, югары профессиональ вокал эталоны. Аның репертуары кебек зур репертуар белән кайсы гына җырчы мактана алыр икән. 26 (!) тематик программа ясаган артист ул. Арада Габдулла Тукай, Муса Җәлил һәм башка бик күп әдипләргә багышланган, Татарстан турындагы программалар да бар... Тукай шигырьләрен тулаем – барысын да яттан белә. Концерт залларында, төрле мәдәни «учак»ларда, китапханәләрдә бихисап чыгышлары әле дә дәвам итә. Ул аларга сәхнәгә яңа гына аяк баскан чагындагыча җентекләп әзерләнә, дулкынлана.

Урта Азиядә тәрбияләнгән милләттәшләребездә үзгә бер ягымлылык, киң күңеллелек, кешеләргә карата йомшак мөгамәлә бар. Эмиль ага җәйнең иң җимешле ае – июль башында матур табигатьле Сәмәркандта туган һәм шунда үскән. Казанда пылауны аның кебек тәмле пешерүче татарлар, булса да, бармак белән генә санарлыктыр.

Пылау пешергән мәл. 1980 ел

«Концерт алдыннан костюмын кигәннән соң, Эмиль абый беркайчан да утырмый, гел басып тора», – ди Татарстанның халык артисты Фердинанд Сәлахов. «Чыгышына кадәр бер сәгать булса дамы?» – дип сорыйм. «Ун сәгать булса да – утырмый. Сәхнәгә ул беркайчан да, хәтта аз гына бөгәрләнгән кием белән дә чыкмый. Ул аның тәрбиясе!» – ди Фердинанд.

Эмиль абый җырчы Венера Шәрипова белән Татарстан симфоник оркестры концертында. 1968 ел

Композитор Рөстәм Яхинның 60 яшьлек юбилей кичәсеннән соң. 1981 ел

Эмиль ага Җәләлетдиновның архивында Рөстәм Яхин белән бергә төшкән фотолар бихисап. Композитор романсларын еш кына иң беренче Эмиль агага күрсәтә торган булган. Р.Яхинның репертуарында хисләр патшалык иткән әсәрләр күп булуы табигый.

Эмиль Җәләлетдинов һәм Марс Макаров

Соклангыч вокал осталыгы, тавышы белән могҗизаи аһәңнәр тудыру сәләте, ниндидер үзгә, башка беркемдә дә очрамаган мөлаемлек – болар барысы да Эмиль аганың сыйфатлары. Сәхнәдәшләре аны уникаль – халык җырларын да, классик әсәрләрне, шәһәр романсларын да бердәй камил башкара алучы оста итеп тасвирлыйлар. Ә үзе сайлаганы – классик юнәлеш.

Рөстәм Үтәй җитәкчелегендәге оркестр белән телевидение студиясендә

Алдагы елларда «Безнең мирас» журналы өчен язган Эмиль ага хакындагы бер мәкаләмдә аның чордаш иҗатчылары телевидение тапшыруларын яздырыр өчен костюмнарны махсус тектерүләре турында мәгълүмат биргән идем инде. Ул чор фотоларын җентекләп караганда, киемнәрдә бер генә хилафлык та табармын димә. Телевидение тапшыруына төшәргә генә түгел, хәтта озын гастроль юлына да энәдән-җептән киенеп чыккан алар. Ат җигеп йөргән, авылдан-авылга мең бәла белән күченгән чакта да эталон икәнлекләрен онытмаганнар.

Казанның Актерлар йортында. 1976 ел

Эмиль аганың хатын-кызларга мөнәсәбәте гаҗәеп: ул аларны алиһә итеп күтәрә, алиһә итеп хөрмәтли. Аның белән чыгыш ясаган җырчы, музыкант, җырчыдан интервью алган журналист кызлар һәм ханымнар моны үзләрендә тойганнар инде. Бевакыт Филармониядә Эмиль агадан интервью алган журналист ханым: «Көне буе кәефем юк иде, бөтенләй икенче төрле кешегә әверелдерде мине бу сөйләшү», – диде.

Эмиль ага кебек затлы кешеләр белән күбрәк аралашып яшик! Ялгышмабыз!

Журналга ***Зимфира Гыйльметдинова*** *әзерләде.* ■

Җуелмас хәзинә

«Ком бураны» җыры

«Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятымызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр».

Габдулла Тукай

Ком бураны

(Татар халык җыры)

Ком бураны, ком бураны –
Оренбурның урамы;
Илдә көрәш барган чакта
Өйдә торып буламы?

Ком буранын туздырабыз,
Урамнардан узабыз;
Ай узабыз, ел узабыз,
Якты юллар сызабыз.

Ком бураны басыладыр
Давыл тынгач, кич булгач;
Без давылдан курыкмыйбыз,
Үзебез давылдай булгач.

Ком бураны каты була,
Каты булса җил көче;
Без бураннар туздырабыз
Көрәшкәндә ил өчен.

Күренекле композитор Җәүдәт Фәйзи «Халык җәүһәрләре» дигән китапта «Ком бураны» җыры турында: *«1919-1920 нче елларда бу җырны Оренбургта татар-башкорт солдатлары стройда барганда җырлап уза иде»,* – дип искә ала. Шушы уңайдан ул атаклы музыкант Исмәгыйль Һилаловның истәлегеннән мондый бер өзек китерә: «Без балачакта Уралда, Троицк шәһәрендә, Яушев дигән байларда хезмәт итүче Закирҗан исемле приказчикны үтерделәр. Шул уңай белән чыкты бу көй. Аны «Закирҗан бәете» дип атыйлар иде. Ул бәетнең бер генә строфасы хәтердә калган. Менә ул:

«Ком бураны уйныйдыр ла,
Фатыйма чәчен тарыйдыр.
Закирҗаным кайтмый, диеп,
Чыгып-чыгып карыйдыр...»

Композитор Җ.Фәйзи, «Ком бураны»ның көй мотивларыннан чыгып, бу көйнең чынлап та бәет булганлыгын искәртә һәм: *«...тик Гражданнар сугышы чорында гына үзенең марш характерындагы метроритмик төзелешен тапты һәм революцион җырга әйләнде»,* – ди.

Бүгенге көннәргә кадәр популярлыгын югалтмаган бу иске көй (XIX гасыр ахыры) күбрәк инструменталь башкаруда яңгырый.

Мәшһүр композиторыбыз А.Ключаревның 1986 елда дөнья күргән «Татар халык җырлары» китабында (музыка редакторы – Луиза Батыр-Болгари, әдәби редакторы – Харрас Әюпов) әлеге җырның Г.Сөләйманова тарафыннан башкарылуы турында искәрмә рәвешендә әйтелә.

Танылган җырчы Вафирә Гыйззәтуллина (1946-2001) узган гасыр ахырында – Татарстаныбыз өчен үтә хәлиткеч булган туксанынчы елларда «Ком бураны» җыры белән мәйдан тотты.

Вафирә Гыйззәтуллина



«Ком бураны» җыры нотасы белән

(Сәхифә «Тәртип» радиосында яңгыраган «Саф вә раушан көзге» тапшыруы материаллары нигезендә әзерләнде. Тапшыруның авторы һәм алып баручысы – Гөлфия Мөхәммәтгәрәева.) ■

Тәртип радиосы

Көлке куа килә...

Афзал Шамов (1901-1990)

Юмаган алма ашасаң...

Язучы Ибраһим Гази яшь чакта иптәшләре арасында яхшы, матур киенеп йөрүче булып кына түгел, ә бөтен нәрсәдә пакьлекне, пөхтәлекне таләп итүче булып та танылган иде.

Аның бу гадәтеннннән кайбер иптәшләре көлә, хәтта урыны туры килгәндә, шаяртып, аны бераз «чеметкәләп» тә алгалый иде.

Берзаман, утызынчы еллар урталарында, яшь тәнкыйтьче Исхуҗин тифтан вафат булды. Моның өчен язучыларның яше-карты бик кайгырды.

Шул уңайдан Мирсәй Әмир Ибраһим Гази турында мәзәк чыгарып өлгерде. Имеш, Мирсәй аңа Исхуҗинның үлгәнен хәбәр иткән икән.

Ибраһим Гази, бу көтелмәгән хәбәрне ишеткәч, бик кайгырып, башын чайкап торган да әйткән:

– Менә шулай була ул, юмаган алма ашагач, – дигән. – Ничә әйттем мин аңа. Тыңламады. Исегездә тотыгыз: беркайчан да юмаган алма ашамагыз! – дигән, имеш.

Туфан Миңнуллин (1935-2012)

Туфан Миңнуллин.
Н.Хаҗиәхмәт шаржы

Милли хикәя

Тугыз катлы йорт каршындагы бәләкәй генә бакчада дүрт татар карчыгы сөйләшеп утыра. Шәмсениса исемлесе сөйли:

– Күрше Ычтапанны мыскыл иттем әле.

– Ничек иттереп мыскыл иттең? – дип сорыйлар аңардан.

– Син, Ычтапан, урыс булуың белән мактанма. Мин дә урысчаны синнән ким белмим, дидем. Я ведь совсем русский, только морда у меня такой, дип тә өстәдем әле. Ычтапан, мескен, ни әйткәнне аңламады, аңласа, егылып үлгән булыр иде.

Татар әбиләренә Шәмсенисаның урысны мыскыл итүе бик ошады, алар егыла-егыла көлделәр.

Илдус Гыйләҗев (1946-2018)

Ә үзебез?

Киребеткән кешеләргә:
«Сарык», – диләр, ни гаҗәп!
Ник малларны кимсетәбез?
Ялгышабыз, җәмәгать!

Алар бездән тәртиплерәк,
Эндәшсәң җаен табып.
«Тәч-тәч!» – дисәң, килеп җитә,
«Һәс!» – дисәң, китә чабып...

Гамил Афзал.
Н.Хаҗиәхмәт шаржы

Гамил Афзал (1921-2003)

Шәһәр кешесе мин...

Шәһәр кешесе мин,
Хисләрем тирән.
Каты сөял тулы сизгер учларым.
Асфальтта йөрим мин,
Тәрәзәдән күрәм
Теге йорт балконын, бу йорт почмагын.

Стенага затлы келәмнәр эләм,
Тәкъдир язган, диеп шомланып йөрмим.
Йөз ел элек үлгән шагыйрьне беләм,
Ун ел бергә торган күршене белмим.

Тәлгат Нәҗмиев (1950-2014)

Барасың... барасың...

Район газетасы редакторы булып эшли башлагач, озак та үтмәде, күрше Балык Бистәсеннән шул чордагы коллегам Харис әфәнде Әшрәфҗанов кереп чыкты. Аның Лесхоздагы баҗаларына барышы икән.

Бүлмәнең зурлыгына исе китте моның. Дөрестән дә, ул кабинетта 1930-1963 нче елларда КПСС райкомының беренче секретарьлары утырган. Коточкыч репрессия елларында бик күп коммунистларның язмышлары шушы бүлмәдә хәл ителгән. Аннан соң 1981 елга кадәр, ягъни 18 ел буе Район Советы башкарма комитеты рәисләре кабинеты булган.

Хәл-әхвәлне белешеп, иҗади уңышлар теләп китеп барды Харис Әшрәфҗанович. Әмма соңыннан болайрак сөйләгән:

– Сабага яңа редактор куйганнар икән. Бүлмәсе... дала кадәр! Ике катлы ишекне ачып карыйсың: бер кеше күренми. Аннан барасың... барасың... Менә берзаман иң түрдәге өстәл артында бер кечкенә генә кеше пәйда була башлый. Шул яңа редактор – Тәлгат Нәҗмиев дигән кеше була икән...

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №5 май 2021

Без барыбыз да – балачактан

Илдар Юзеев
(1933-2004)

Китмәгез сез балачактан!

Бик бәхетле булсагыз да,
Тәхетләргә кунсагыз да,
Сарайларда торсагыз да, –
Китмәгез сез балачактан,
Өмет, хыял янар чактан.

Кайгы-хәсрәт бәйләнсә дә,
Хыял көлгә әйләнсә дә,
Көнең төнгә әйләнсә дә, –
Китмәгез сез балачактан,
Өмет, хыял янар чактан.

Бәхет кулын сузганда да,
Кырын карап узганда да,
Сәлам бирми сызганда да, –
Китмәгез сез балачактан,
Өмет, хыял янар чактан.

Әҗәл килеп җиткәндә дә,
Тәрәзәне чирткәндә дә,
Алмый кире киткәндә дә, –
Китмәгез сез балачактан,
Өмет, хыял янар чактан.

Хәкимҗан Халиков
(1933-2002)

Каламы соң?

(Тизәйткеч)

«Карр! Карр!» – диеп,
Кара карга
Карны күпме
Каргамасын,
Карыбызны
Каргый-каргый,
Күпме китеп карамасын –
Карсыз җирдә
Каламы соң?
Кар беткәнче
Кайтып, әнә,
Карап йөри
Карамасын.

Мөхәммәт Мәһдиев (1930-1995)

Теккән бармак белән шешкән бармак

Дүрт яшьлек Надирның бармагы шеште. Әнисе аны ак бинт белән бәйләп куйды. Бинт гел шуып чыгып җәфалагач, шешкән бармакка бинттан бармакча тегеп киерттеләр. Надир бакчада мавыгып уйнаган чакта, анысы да төшеп калды. Малай өйгә йөгереп кайтты да болай диде:

– Әни, теккән бармак шешкән бармактан төшеп калды, нишлибез?

Кем көчле?

(Татар халык әкияте)

Борын-борын заманда булган икән, ди, бер кеше. Бу кешенең исеме Нарый булган, ди, кесә төбе тар булган, ди, тар булса да, бер пот тары сыя торган булган, ди.

Көннәрдән беркөнне Нарый чыгып киткән юлга. Барган да барган, ди, бу. Бара торгач, барып кергән, ди, ялтырап торган боз өстенә. Боз өстенә барып та кергән, аягы таеп, әйләнеп тә төшкән. Шул чакны бөтен тарысы чәчелеп тә киткән моның. Ачуланып сикереп торган да Нарый бозга әйткән:

– Боз, син нидән көчле болай? – дигән.

– Көчле булсам, – дигән боз, – мине кояш эретә алмас иде.

– Кояш, син нидән көчле? – дигән Нарый.

– Көчле булсам, мине болыт капламас иде.

– Болыт, син нидән көчле?

– Көчле булсам, мине яңгыр тишеп чыкмас иде.

– Яңгыр, син нидән көчле?

– Көчле булсам, – дигән яңгыр, – мине җир сеңдермәс иде.

– Җир, син нидән көчле?

– Көчле булсам, миннән үлән тишелеп чыкмас иде.

– Үлән, син нидән көчле?

– Көчле булсам, мине сыер ашамас иде.

– Сыер, син нидән көчле?

– Көчле булсам, мине пычак кисмәс иде.

Хәзер пычактан сорый инде Нарый:

– Пычак, син нидән көчле?

– Көчле булсам, мине ут эретмәс иде.

– Ут, син нидән көчле?

– Көчле булсам, мине су сүндермәс иде.

– Су, ә син нидән көчле?

– Көчле булсам, мине кеше җиңмәс иде, ә ул мине җиңә, тегермәннәр әйләндерергә җигә! – ди су.

Шуннан соң Нарый, кешедән дә көчлесе юк икән, дип, үз юлына китә, шуның белән әкият тә бетә.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

АПРЕЛЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● 1 апрельдә Казандагы 162 нче балалар бакчасында балалар шагыйре, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон белән очрашу булып узды. Әлеге очрашуда А.Алиш исемендәге 20 нче гимназия директоры, балалар шагыйрәсе Рәхимә Арсланова да катнашты һәм чыгыш ясады.

● 2 апрельдә Казанның «Корстон» сәүдә-күңел ачу үзәгендә Бөтенроссия татар эшмәкәрләре җыены үтте. ТР Президенты Р.Миңнеханов катнашында узган әлеге чараны Татарстан премьер-министрының урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессы Милли шурасының рәисе В.Шәйхразыев алып барды.



● 6 мартта Уфаның «Ихлас» мәчетендә Мөхәммәт хәзрәт Галләмгә 70 яшь тулу уңаеннан тантаналы чара булып узды. Мөхтәрәм юбилярны Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров, «Ислам динен кабул итүгә 1000 ел» исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон, Бөтендөнья татар конгрессының Аксакаллар шурасы рәисе Рәүф Хәсәнов, «Россиянең татар авыллары ассоциациясе» Бөтенроссия иҗтимагый оешмасы рәисе Фәнир Галимов, Татарстанның һәм Башкортстанның халык артисты Фән Вәлиәхмәтов һәм башкалар котлады.

● 7 апрельдә Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, танылган музыкант, виртуоз пианист Илдар Нури улы Арсланов (могтәбәр шагыйрьләребез Нури Арслан (1912-1991) һәм Әминә Бикчәнтәеваның (1913-1986) уллары) вафат булды.

● 9 апрельдә «Иң яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы-2021» Бөтенроссия бәйгесенең җиңүчеләре ачыкланды. Менә алар: Башкортстанның Нефтекама шәһәрендәге 10 нчы мәктәптән Галия Корбанова һәм Актаныш районының сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернаты укытучысы Чулпан Шәрипова.

● 10 апрельдә күренекле галимә, тарихчы, ТР Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге премиясе лауреаты Альта Хаҗи кызы Мәхмүтова вафат булды.

Мәрхүмәнең җәсәде 11 апрельдә туганягында – Менделеевск районының Бәзәкә авылында җирләнде.

● 15 апрельдә татар зыялылары мәшһүребез Габдулла Тукай һәм аның сөйгәне Зәйтүнә Мәүлүдова каберләренә чәчәкләр салды.

● 16 апрельдә Кырлайда (Арча) XX Республикакүләм Г.Тукай укуларының йомгаклау чарасы үтте. Анда катнашучы укучыларның һәм укытучыларның эшләренә бәя бирүчеләр арасында язучылар В.Нуриев («Казан утлары»), Л.Лерон («Безнең мирас»), журналистлар Р.Исмәгыйлева («Мәгариф»), З.Хөснетдинова («Салават күпере», «Сабантуй») һәм галимә А.Ганиева (Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) бар иде.

● 17 апрельдә танылган журналист Габдерәхим (Рөстәм Мөнәвәр улы Юнысов) вафат булды. Мәрхүмнең җәсәде Самосырово мөселман зиратында җирләнде.

● 22 апрельдә Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетында, Г.Тукайның 135 еллыгы уңаеннан, язучылар Камил Кәримов, Ләбиб Лерон һәм баянчы Кирам Сатиев белән очрашу булып узды.

● 22 апрельдә Казанның 3 нче гимназиясендә балалар шагыйре Илгизәр Солтанны (1961-2005) искә алу чарасы үтте. Чарада язучы Галимҗан Гыйльманов, балалар шагыйрәсе Йолдыз Шәрәпова һәм «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире, шагыйрь Ләбиб Лерон катнашты һәм чыгыш ясады.

● 28 апрельдә Мөслимдә Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Фоат Садриевка 80 яшь тулу уңаеннан әдәби-музыкаль чара булып узды. Анда юбилярны, якташлары белән бергә, Казаннан, Чаллыдан һәм Әлмәттән килгән каләмдәшләре дә котлады. ■

МИРАСВОРД

Сибгат Хәким поэмасы

Беренче совет автомобиле

Язучы, «Утызынчы ел» романы авторы

Рус теленең аңлатмалы сүзлеген төзегән галим

Чуаш халкының язгы бәйрәме

Шагыйрә ... Йосыпова

Ишарә

Мәхмүд ... (татар язучысы, тәрҗемәче)

Шагыйрь ... Сирай

Гражданнар сугышы герое

VII-XI гасырларда Азиядә яшәгән төрки телле кабилә

Ат җигү дирбиясе

Кармак җебе

Татар халык дастаны

Шаять

«Роллс-...» автомобиле

Мөрәҗәгать, шигарь

... Бәхтияров (журналист, «Әл-ислах» газетасы мөхәррире)

Язучы Газиз ...

Һиндстанда дини, фәлсәфи тәгълимат тарафдары

Атларга хас авыру

Берәр нәрсәнең чите, яны (диал.)

Җырларга кергән елга

Аршын (иск.)

Сөт анасы

Кызыл диңгез култыгы

Оят, намус (иск.)

Европада яшәгән герман кабиләсе вәкиле

Элек Рейн елгасында шәраб ташу өчен кулланылган судно

Мостафа ... (төрек галиме)

... Колый

... гармун

Туку станогы детале

Көртлек (диал.)

Советлар Союзы

Язучы ... Мөхәммәдиев

Язучы, «Ямашев» трилогиясе авторы



Язучы ... Ихсанова

Җәядән атыла

Бездә – авыл, Кавказда – ...

Ут, ялкын (иск.)

... Гамзатов

4 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: Хикмәт, ур, Ләис, шава, Тавлин, шивә, Рамзес, Рид, вәхи, прима, Анак, милади, әпә, Һималай, тиле, улар, Сакаев, би, соса, «Анчар», Амон, Сәлим.
Өстән аска: терпе, тупса, ир, «Ил», ом, Вадим, Лаисов, Хәлил, миһербан, Иргали, Кришна, АМО, Муса, «Млада», Нил, асс, Тумашева, аукан, исәкәй, чүл, Вера, әниләр, Рим.

Рәис Габдулла төзеде.

«Безнең мирас»
елъязмасы / май

«Мелла Насретдин» журналының тәүге санының тышлыгы. 1906 ел

660 ел элек (1361)

Алтын Урда дәүләте тарихында таркаулык чоры башлана. Хан дәвамчылары вә морзалар тәхет өчен көрәшкә ташлана.

115 ел элек (1906)

18 майда башкалабыз Казанда «Таң йолдызы» газетасының беренче саны басылып чыга. Мөхәррире – күренекле шагыйрь Сәгыйть Рәмиев.

115 ел элек (1906)

1906 елның 7 апрелендә Тифлис шәһәрендә «Мелла Насретдин» исемле көлке журналының тәүге саны дөнья күрә. Басманы оештыручы – азәрбайҗан журналисты Җәлил Мәмәдкулизадә (1866-1932).

100 ел элек (1921)

Татнаркомпросның укый-яза белмәүчелекне бетерү бүлеге урыс һәм татар телләрендәге драма әсәрләренә иҗади конкурс игълан итә.

90 ел элек (1931)

6 майда Көнбатыш Себердә күчмә татар театр труппасы эшкә керешә.

20 ел элек (2001)

27 майда Кукмара районының Салтык Ерыклы авылында мәшһүр композитор Фасил Әхмәтовка багышланган музей ачыла.

*Журналга **Марат Закир** әзерләде.* ■

Содержание. Май 2021

И останется в мире слово моё...: Гамиль Афзал.

Историческое наследие: «Рядом с Садри Максуди». Б.Шараф; «Эх, родная деревня, насколько велик твой возраст?..». Р.Марданов, И.Хадиев; «Голод в Черемшанском крае». Ф.Ислаев.

Татарский мир: «Наследство двух народов». Р.Харис.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов.

В глубинах памяти: «Наследники дедушки Муслим». Р.Хабибуллина; «Преемственность». Р.Батулла; «Блокнот Фаиля, письмо Ишмурата...». Э.Шарифуллина; «В памяти, до сих пор в памяти!».

Слово – украшение языка: «Пресса и родной язык». Р.Юсупов.

Художественное наследие: «Путешествие в Германию». К.Саттаров; «Татарские певцы. Дорогие мгновения». З.Гильмутдинова.

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

Алхәбәр:

Сәмигулла Хәйретдинов (сулда), Эльмира Шәрифуллина һәм Зәки Хәнәфиев. 14 сентябрь, 1966 ел («Кара кош». *Э.Шәрифуллина*)

- **XX гасыр башында Казан Сабантуйлары. Ленар Гобәйдуллин**
- **Кара кош. Эльмира Шәрифуллина**
- **Онытылмасын Гай бабай. Әхтәм Зарипов**
- **Ярмәк «вагы». Индус Диндаров**
- **«Кайсыгызның кулы жылы?» Рухия Ахунжанова**

Гамил Афзал — фотоларда



Афзаловлар гаиләсе (сулдан уңга): Нәфисә, Рауза, Раушания, Гамил. Әлмәт, 1966 ел

Шигърият дип йөрәк янган мәл... Магнитогорск. 1950 нче еллар

Гамил Афзал гаиләсе, туганнары һәм дуслары белән. Башкортстанның Калтасы районындагы Яңа Шәрип авылы. 1960 ел

Нәфисә һәм Гамил Афзаловлар, Әдип Маликов, ?. 1990 нчы еллар

Габдрахман Теләш янында шигърият дәресләре. Магнитогорск. 1948 ел

«Гомер кичүләре» китабын тәкъдим итү кичәсендә. Нәфисә һәм Гамил Афзаловлар. Әлмәт, 2000 ел

*Фотолар **Ленар Шәех** архивыннан алынды.*

ЯРЛАРЫННАН ТАШЫП ЧЫГА ЯЗ КӨНЕНДӘ КАЗАНСУ...



*Казансу елгасының фотолары хаҗи **Абдулла Дубин** тупланмасыннан алынды.*

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»* *журналына башкача язылу:
- *uslugi.tatarstan.ru* сайты ярдәмендә
- редакциядә
- *podpiska.pochta.ru* сайты ярдәмендә электрон версия

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 51), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.